# КЫСКАЧА ГЫЙЛЬМЕ-ХӘЛ

мөселман балаларыһәм яшүсмерләр өчен ДИН дәресләре

## БАШ СҮЗ

Кешелекне һәм бөтен галәмнәрне бөек бер хикмәт һәм максат белән бар кылган Аллаһы Тәгаләгә чиксез мактауларыбыз булсын. Бөтен барлык өчен иң бөек рәхим-шәфкать иясе, иң бөек шәфәгатьче (яклаучы), пәйгамбәрләрнең әфәндесе Мөхәммәд Мостафа салләллаһү галәйһи вә сәлләмгә, аның гаиләсенә, сәхабәләренә һәм барча аңа иярүчеләргә салават һәм сәлам булсын.

Гыйльме-хәл — ул мөселманнарга ышаныч һәм гамәл ягыннан иң кирәкле мәгълүмат бирә торган гыйлем. Пәйгамбәр әфәндебез галәйһис-сәлам: "Гыйлем өйрәнү һәр мөселман ир һәм хатынга фарыз",- дип боерган. Бу мөбарәк сүзләрдән аңлашылганча, бөтен мәселманнарга фарыз булган гыйлем – дөнья һәм ахирәт бәхетенә ирештерә торган "гыйльме-хәл". Шуңа күрә иман китерү һәм гыйбадәттә тиешле гыйлемне өйрәнү һәрбер мөселман ир һәм хатынга фарыз. Өйрәнеп тә ышанмаган кешеләрнең иманнары камил(тулы) була алмас. Бу хакта язылган төрле күләмдәге "Гыйльме-хәл" китаплары булса да, мәселман балаларына иң әһәмиятле дини кануннарны җиңеләйтеп, истә калдырырга ярдәмче булсын өчен шушы "Гыйльме-хәл" китабын әзерләдек. Аллаһы Тәгалә кылган гамәлләребездән разый булсын.

**Мөһим искәрмәләр**

Мөхтәрәм укучыларым!

Кулыгыздагы китапта, кайбер сүрә, аять һәм догалар китерелеп, гарәпчә хәрефләрне белмәүчеләргә җиңел булсын өчен аларның кириллица хәрефләре белән укылышлары да өстәлде. Әмма кириллица хәрефләре белән язып, догаларның төгәл укылшын, мөгаллим ярдәмендә генә үзләштереп була. Калын һәм озын итеп укыла торган авазлар ике хәреф белән бирелә, мәсәлән: аа**,** уу. Алар бер аваз, әмма озынрак әйтелә. Әгәр өч сузык язылса, ул аваз тагын да озынрак әйтелергә тиеш.

Сүрә һәм догаларны татарчадан укыганда шушы хәрефләргә игътибар итегез:

1). з һәм с – бу хәрефләр сакау укыла;

2). д – бу хәреф әйтелгәндә, тел азау тешкә тидереп әйтелә;

3). х, к һәм т хәрефләре - калын укыла;

4). г – бу хәреф гарәп телендәге "ع" (гайн) буларак укыла.

**Аңлатма:** Кулыгыздагы бу китапта Коръән аятьләре һәм сүрәләре булганга, җиргә ташламаска һәм хөрмәтсезлек күрсәтмәскә тиешлеген искәртәбез.

## ДИНЕБЕЗ

# ИСЛАМ

## ДИН

Дин - акыллы кешеләрне үз теләге һәм ихтыяры белән дөнья һәм ахирәт бәхетенә ирештерә торган илаһи бер канун. Аллаһы Тәгалә пәйгамбәрләр аша кешеләргә динне белдергән. Диннәрнең нигезе – Ислам. Бу илаһи диннәр бозылганлыктан Аллаһы Тәгалә Пәйгамбәребез аша хакыйкый диннәрнең иң соңгысы һәм иң камиле итеп Ислам динен җибәрде. Ислам диненә ышанган кешегә мөселман диләр. Без дә, әлхәмдү лилләһ, мөселманбыз.

## ШӘРИГАТЬ

Шәригать - дин мәгънәсендә йөрүе белән бергә диннең гыйбадәт һәм мөгамәләләр хакындагы хөкемнәренә дә шәригать диелә.

## ИМАН

Иман – ул Пәйгамбәребезнең Аллаһ тарафыннан җиткергән нәрсәләрнең барысына чын күңелдән ышану. Иман шул ышанудан тора. Кеше шәһадәт кәлимәсен әйтү белән мөселман була.

Иманның алты шарты бар. Бу шартлар "Әәмәнтү билләәһи" дигән аятьтә түбәндәгечә бәян ителә: «Әәмәнтү билләәһи үә мәләәикәтиһии үә кутүбиһии үә русүлиһии үәл-йәүмил-әәхыйри үә бил-кадәри хайриһии үә шәрриһии минәллааһи тәгаләә үәл-бәгсү бәгдәл мәүти хакк.

Әшһәдү ән ләә иләәһә илләллааһү үә әшһәдү әннә Мүхәммәдән габдүһүү үә расүүлүһ.

Мәгънәсе**:** Мин Аллаһы Тәгаләгә һәм Аның фәрештәләренә, китапларына, пәйгамбәрләренә, ахирәт көненә, кадәргә, ягъни яхшылык белән яманлыкның

Аллаһы Тәгаләдән икәнлегенә инандым, үлгәннән соң терелү дә хак. Мин шәһадәт бирәм, Аллаһы Тәгаләдән башка илаһ юк, хәзрәти Мөхәммәд галәйһиссәләм Аның колы һәм пәйгамбәре.

## ИМАННЫҢ ШАРТЛАРЫ

1. Аллаһы Тәгаләгә инану.
2. Аллаһының фәрештәләренә инану.
3. Аллаһының китапларына инану.
4. Аллаһының пәйгамбәрләренә инану.
5. Ахирәт көненә инану.
6. Тәкъдиргә, ягъни яхшылык һәм яманлык Аллаһы Тәгаләдән икәнлегенә, үлгәннән соң терелү дә хак икәнлегенә инану.

Әгәр берәү иманның бу алты шартыннан берсен генә кабул итмәсә дә, барысын да кабул итмәгән булып санала. Мәсәлән, иманның биш шартын кабул итеп, ахирәткә ышанмаган кеше мөселман булмас.

## 1. АЛЛАҺЫ ТӘГАЛӘГӘ ИНАНУ

Иманның алты шартының беренчесе – Аллаһы Тәгаләгә инану, ягъни Аллаһы Тәгалә бар һәм Аның заты барча камил сыйфатларга ия булып, барча җитешсезлекләрдән азат. Мөбарәк сыйфатлары – сыйфатү-зәтийә һәм сыйфатү-сүбүтийә дип ике өлешкә аерыла.

### СЫЙФАТҮ-ЗӘТИЙӘ

Аллаһы Тәгаләнең сыйфатү-зәтийәсе алты:

**1.** Вүҗүд**:** бар булуы.

**2.** Кыйдәм**:** башлангычы юклыгы.

**3.** Бәка**:** ахыры-азагы юклыгы.

**4.** Вәхдәният**:** бер генә булуы.

**5.** Мүхаләфәтүн лил-хәвәдис**:** Аллаһы Тәгаләнең һичбер мәхлукка да охшамавы.

**6.** Кыям-бинәфсиһи**:** Аллаһы Тәгаләнең беркемгә дә, бернәрсәгә дә мохтаҗ булмавы.

**СЫЙФАТҮ-СҮБҮТИЙӘ**

Аллаһы Тәгаләнең сыйфатү-сүбүтийәсе сигез:

**1.** Хәят**:** тере булуы. (Аллаһы Тәгалә терeдер һәм терелтүче).

**2.** Гыйлем**:** белүче булуы. (Аллаһы Тәгалә һәр нәрсәне хәтта күңелләрдәге яшерен ниятләрне һәм теләкләрне дә белеп тора).

**3.** Сәмиг**:** ишетүче булуы. (Аллаһы Тәгалә һәр нәрсәне ишетә).

**4.** Бәсар**:** күрүче булуы. (Аллаһы Тәгалә караңгы төндә, кара таш өстендә йөргән

кара кырмысканы да күрә һәм аяк тавышын да ишетә).

**5.** Ирадәт**:** Аның теләге булуы. (Теләк иясе, тели һәм теләгән нәрсәсен теләгәнчә булдыра).

**6.** Кодрәт**:** көче һәр нәрсәгә җитәрлек булуы. (Аллаһы Тәгаләнең һәр нәрсәгә көче җитә).

**7.** Кәләм**:** сөйләүче булуы. (Аллаһы Тәгаләнең сөйләве хәреф һәм тавышка мохтаҗ түгел).

**8.** Тәквин**:** Юктан барлыкка китерүче булуы. (Юктан барлыкка китерүче бары тик Аллаһы Тәгалә генә).

## 2. ФӘРЕШТӘЛӘРГӘ ИНАНУ

Иманның икенче шарты – фәрештәләргә инану.

Фәрештәләр - нурдан бар ителгән, теләгән сурәткә керә ала торган җан ияләре.

Фәрештәләрдә ирлек-хатынлык юк. Алар, Аллаһ ни кушса, шуны гына эшлиләр. Аларның ашау-эчүгә ихтыяҗлары юк. Кайсысы күктә, кайсысы җирдә, төрле вазифа үтиләр. Саннарын Аллаһы Тәгалә генә белә. Алардан дүртесе өлкән фәрештәләр.

## ДҮРТ ӨЛКӘН ФӘРЕШТӘ

**1.** ҖӘБРАИЛ галәйһиссәлам. Аллаһы Тәгаләнең китапларын пәйгамбәрләргә китереп тапшыруда, ягъни вәхине китерү өчен җаваплы. Аллаһы Тәгалә белән илчеләр (пәйгамбәрләр) арасында арадашчы.

**2.** МИКАИЛ галәйһиссәлам**.** Табигый хәлләр, мәсәлән: җилләр, яңгырлар, иген-тарулар һәм башкалар өчен җаваплы.

**3.** ИСРАФИЛ галәйһиссәлам**.** Сур исемле коралга өреп Ккыямәт башлануы һәм кешеләрнең Кыяматтә кабат терелүләре өчен җаваплы.

**4.** ГАЗРАИЛ галәйһиссәлам**.** Үлүчеләрнең җаннарын алу өчен җаваплы.

Һәр кешедә вазифалы 384 фәрештә бар. Болардан аермалы рәвештә Кирамән-Кәтибин (гамәлләрне язып баручы) һәм Хафаза (сакчы) фәрештәләр бар.

## 3. КИТАПЛАРГА ИНАНУ

Иманның өченче шарты – (изге) китапларга инану. Аллаһы Тәгалә үзенең теләкләрен, әмер(боерыкларын), тыюларын, хикмәтләрен колларына белдерү өчен пәйгамбәрләренә вакыт-вакыт китаплар индергән. Бу китапларның барчасына "Илаһи китаплар" исеме бирелгән. Җәбраил галәйһиссәлам аша пәйгамбәрләргә иңдерелгән сухуфләр (битләр) һәм китаплар - йөз дә дүрт.

**СУХУФЛӘР (БИТЛӘР)**

10 сухуф – Адәм аләйһиссәләмгә;

50 сухуф – Шис аләйһиссәләмгә;

30 сухуф – Идрис аләйһиссәләмгә;

10 сухуф – Ибраһим аләйһиссәләмгә иңдерелгән.

Барлыгы 100 сухуф җибәрелгән.

**КИТАПЛАР**

1 - Тәүрат**:** Муса галәйһиссәламгә;

2 - Зәбүр**:** Давыд галәйһиссәламгә;

3 - Инҗил**:** Гайсә галәйһиссәламгә;

4 - Коръән**:** Безнең Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһү галәйһи вә сәлләмгә иңдерелгән.

Кешелек дөньясына җибәрелгән йөз сухуф һәм дүрт бөек китап шушылар. Безнең Пәйгамбәребезнең һәм Коръәни Кәримнең җибәрелгәннән соң бүтән китапларның хөкемнәре гамәлдән чыкты.

Коръәни Кәримдә 114 сүрә, 6666 аять бар. Ике тыныш арасы бер аять дип атала. Коръәннең бер хәрефе дә үзгәрмәде. Коръәни Кәрим Кыяматкә кадәр Аллаһының саклавы астында булып, беркайчан да үзгәрмәячәк.

## 4. ПӘЙГАМБӘРЛӘРГӘ ИНАНУ

Иманнның дүртенче шарты – пәйгамбәрләргә инану. Пәйгамбәр — **у**л Аллаһы Тәгаләнең хөкемнәрен, әмерләрен, хәбәрләрен, тыюларын колларына тапшыру өчен, Аллаһы Тәгалә белән коллары арасында арадашчы сыйфатында җибәрелгән һәм әхлакның барлык гүзәллекләренә ия булган зат. Пәйгамбәрләр кешеләрне Аллаһыга ширек кылу, потларга табыну кебек төрле адашулардан коткарып, кешеләрне дөнья һәм ахирәт бәхетенә ирештерү өчен җибәрелгәннәр. Кешеләр үз акыллары белән туры юлны таба алмаганга, Аллаһы Тәгалә аларга пәйгамбәрләр җибәргән. Пәйгамбәрләргә Аллаһ тарафыннан могҗизалар бирелгән. Гади кешеләр булдыра алмаган нәрсәләрне пәйгамбәрләр Аллаһы Тәгаләнең ярдәме белән бик җиңел эшләгәннәр.

Иң беренче кеше һәм тәүге пәйгамбәр – Адәм галәйһиссәләм. Шуңа күрә, тереклек арасында иң күркәм булган кешенең төп чыгышы, кайбер ялгыш фикерләүчеләр раслап маташканча, маймыл түгел, чын кеше. Кешенең асылын маймылга бәйләп аңлатудан оялырга, тартынырга һәм әдәпсезлек дип санарга кирәк.

"Кешенең асылы маймылдан" дигән хаталы фикерне гасырыбызның гыйлеме һәм фәне төптән юкка чыгарды. Шуңа да карамастан, һаман да

"кешенең асылы маймылдан" дигән наданнарга очрау гаҗәп хәл! Кеше айга барып кайткан бу дәвердә "кеше маймылдан килеп чыккан" димәктән дә ят фикер бармы икән?

Һичшиксез мәгълүм, безнең асылыбыз маймыл түгел, хәзрәти Адәм белән хәзрәти Хәва – җәннәттән килгән саф затлар.

## ПӘЙГАМБӘРЛӘРНЕҢ СЫЙФАТЛАРЫ

Пәйгамбәрләрнең түбәндәге сыйфатларын белү лязем. Алар бишәү:

1- Сыйдк**:** **п**әйгамбәрләр тугрылыклы. Алар бер кайчан да ялган сөйләмәсләр.

2- Әманәт**:** Алар һәр нәрсәдә үзләренә ышаныч уяталар.

3- Тәблигъ**:** Алар Аллаһының әмерләрен һәм тыюларын һич кимчелексез һәм курыкмыйча кешеләргә тапшыралар.

4- Фәтәнәт**:** Алар бик зирәк.

5- Гыйсмәт**:** Алар гөнаһ эшләрдән тулысынча сакланганнар.

Безнең Пәйгамбәребезнең биш сыйфаты аны бүтән пәйгамбәрләрдән аерып тора:

1- Бөтен пәйгамбәрләрдән фазыйләтлерәк (өстенрәк).

2- Ул барлык кешелеккә һәм җеннәргә җибәрелгән.

3- "Хатәмүл-әнбия", ягъни пәйгамбәрләрнең иң соңгысы. Аңардан соң бүтән пәйгамбәр килмәячәк.

4- Ул барча галәмнәргә рәхмәт буларак җибәрелгән.

5- Аның шәригате Кыяматкә кадәр дәвам итәчәк.

Коръәндә исемнәре язылган пәйгамбәрләр**.**

Хәзрәти Адәм галәйһиссәламнән Пәйгамбәребез галәйһиссәламгә кадәр, бер риваятьтә 124 мең, икенчесе буенча, 224 мең пәйгамбәр килгән. Болардан егерме сигезенең исеме Коръән Кәримдә китерелә. Коръән Кәримдә булган һәм һәркем белергә тиешле пәйгамбәрләрнең мөбарәк исемнәре:

Адәм, Идрис**,** Нух, Һуд**,** Салих, Ибраһим**,** Лут, Исмәгыйль**,** Исхак, Ягъкуб**,** Йусуф, Әюб**,** Шөгаиб, Муса**,** Һарун, Давыд**,** Сөләйман, Юныс**,** Ильяс, Әльйәса**,** Зөлкәфил, Зәкәрия**,** Яхья, Гайсә, **Го**зәир, Локман**,** Зөлкарнәин һәм хәзрәти Мөхәммәд галәйһимүс-сәлам. Гозәир, Локман һәм Зөлкарнәин галәйһимүс-сәламнәрнең пәйгамбәрме яки әүлияме икәнлекләре бәхәсле.

## ПӘЙГАМБӘРЕБЕЗ

Пәйгамбәребезнең нәсел-нәсәпләре**:** Пәйгамбәребезнең үзеннән алып, хәзрәти Исмәгыйль галәйһиссәлам нәселенә тоташкан Әднәнга кадәр булган нәсел чылбыры: хәзрәти Мөхәммәд галәйһиссәлам**,** Габдулла, Габделмотталиб**,** Һәшим, Габдеманәф**,** Кусай, Киләб**,** Мүррә, Кәгаб**,** Ләәй, Галиб**,** Фихер, Мәлик**,** Нәдер, Кинянә**,** Хөзәймә, Мөдрикә**,** Ильяс, Мөдәр**,** Низар, Мәгад**,** Әднән.

Пәйгамбәребезнең әнисе ягыннан нәсел чылбыры: хәзрәти Мөхәммәд галәйһиссәлам**,** Әминә, Вәһеб**, Га**бдеманәф, Зөһрә**,** Киләб.

Пәйгамбәрләрнең соңгысы буларак җибәрелгән пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһү галәйһи вә сәлләм бер кешелек өчен генә түгел, барча галәмнәргә Аллаһының бер рәхмәте булып килде.

Дөнья һәм ахирәт мәслихәтләрендә һәм котылу юлын күрсәтүдә акылының чиге булмаган зат, кешеләрнең җитешсезлекләрен бетерү өчен мәхлуклар белән Аллаһы Тәгалә арасында арадашчы буларак җибәрелгән пәйгамбәрләрнең иң бөеге, иң югары булганы безнең Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа галәйһис-сәлам. Аңардан әүвәл Аллаһы Тәгалә тарафыннан кешелеккә җибәрелгән пәйгамбәрләрнең кайберләре аерым бер кавемгә (халыкка), кайберләре аерым бер мәмләкәткә (илгә) генә җибәрелгән булса, ул галәйһис-сәлам бөтен кешелеккә, барча яратылган җан ияләренә, шулай ук унсигез мең галәмгә Аллаһының рәхмәте буларак җибәрелгән. Аның кешелеккә килүе нинди зур бәхет икәнлеген аңлау өчен, ул бөек Пәйгамбәрдән алда булган тормышны белергә кирәк.

Билгеле булганча, Пәйгамбәребез галәйһис-сәлам җибәрелгәнче, бөтен дөньяда һәр яклап бозыклык һәм адашу нык таралган иде. Һәр тараф кояш тотылган шикелле, куркыныч бер караңгылыкта калган иде. Җир йөзе күп гасырлардан бирле берәр пәйгамбәрнең юл яктыртуыннан һәм юлбашчылыгыннан мәхрүм иде. Ул чорның кешеләре бозыклык һәм ялгышлык тозагына эләгеп, бөтен җиһан караңгылыкта иде. Кешелек, гаделлектән һәм мәдәнияттән ераклашып, хаклык белән дөреслектән берни дә калмаган иде. Фәхеш һәм тәкәбберлек, һәр төрле золым һәм көчләү гадәт булып киткән иде. Кемнең кемгә көче җиткән булса, шул башкаларның җанын һәм малын кулыннан тартып алыр иде. Кайбер кавемнәр кечкенә кызларын да терелэй җиргә күмәләр иде. Хатын-кызларның һичбер хакы, кадере калмаган иде. Аларны акчага сатып алып, товар шикелле теләсә ничек кулланалар иде. Бер-берсенә теш кайраган кабиләләр (нәселләр) очсыз-кырыйсыз үтерешүләр аркасында бер-берсенә дошман булганнар иде. Менә шундый бер вакытта Рәсүл Әкрам салләллаһү галәйһи вә сәлләм әфәндебез Мәккә Мөкәррәмәдә, милади буенча 571 нче елда, рабигел-әүвәл аеның 12 нче кичәсенең таң вакытында дөньяга килде. Аның бу бәхетле тууы белән бөтен кешелек галәме кояш нуры чәчә башлагандай булды. Кешелек күкләрен каплаган караңгылык һәм афәт болытлары таралып, кешелек сафлана һәм нурлана башлады. Пәйгамбәрләрнең соңгы бөжрасы булган Пәйгамбәребез кырык яшенә җитеп, пәйгамбәрлек һәм Шәригать иңдерелгәнче үк үзендә гадәттән тыш изгелек билгеләрен күрсәтте. **“**Аллаһ ничек кушкан булса**,** шулай тугрылыклы бул**!”**- дигән Аллаһ әмеренә тулысынча ияргәнгә, бөтен тормышында дөреслек һәм тугрылыкның тере мисалы булды. Ул төрле күрсәтүдән һәм ялганнан ерак иде. Кеше кешене хөрмәт итмәгән, кеше кешегә ышанмаган бер дәвердә аңа һәркем ышанды, аны хөрмәт итте. Бәхәсле мәсьәләләрдә аның сүзенә һәм хөкеменә бердәм риза булырлар иде. Хәтта аның пәйгамбәрлегенә ышанмаган дошманнары да, аның

дөреслек һәм тугрылык белән яшәвен, ялган белән килешмәвен кабул итәләр иде. Аңарда булган тиңсез әхлак һәм югары дәрәҗәне раслап, аны "Мөхәммәд-Әмин" – "ышанычлы Мөхәммәд" дип атадылар. Чыннан да дөньяга, дөньяның бозыклык белән тулган бер дәверендә рәхмәт булып килгән Рәсүлебез кешеләр табына торган потларны тар-мар итеп, галәмне иман һәм ислам нуры белән караңгылыктан коткарып, кешелеккә дөнья һәм ахирәт бәхете ачкычларын бүләк итеп, чын мәдәният юлларын күрсәтеп калдырган. Менә бүген тарихны юлсыз рәвештә өйрәтүче кайбер кешеләр төркеме, аның бөек дәрәҗәсен, әхлагын, кешелекне чыннан да коткаручы икәнлеген танырга мәҗбүр булдылар. Аның тарихка тәэсире һәм рухи көче алдында хәйран калуларын яшерә алмадылар. Бөек ислам галиме Мөхәммәд Әсәд тарафыннан тәрҗемә ителгән бер әсәрдә мәшһүр инглиз философы Томас Карлейл: "Хәзрәти Мөхәммәд салләллаһү галәйһи вә сәлләм икейөзлелектән бөтенләй азат булганлыктан, мин аны яратам. Хәзрәти Мөхәммәд салләллаһү галәйһи вә сәлләмне бәяләрлек бер үлчәү дә юк. Ул үлчәнмәслек дәрәҗәдә авыр һәм бөек", - дигән. Мөселман булмаса да инсафлы кешеләр Пәйгамбәребез салләллаһү галәйһи вә сәлләмгә шул кадәр хәйран калып, хөрмәт күрсәткәч, аның өммәтенә аны никадәр яратып, никадәр хөрмәт итәргә тиешле булуын уйларга кирәк.

Пәйгамбәребез дөньяга килгәндә, аңа кадәр килгән пәйгамбәрләр китергән Шәригать хөкемнәреннән берни дә калмаган иде. Хаклык һәм хөкем безнең Пәйгамбәребезгә калды. Шуңа күрә, Пәйгамбәребез бервакыт хәзрәти Гомәр разыяллаһү ганһүнең кулында Тәүрат битләрен күреп, моңа ризасызлыгын белдереп: "Сез дә яһүдиләр һәм насаралар кебек минем пәйгамбәрлегемнән, миңа индерелгән Коръәннән шикләнәсезме? Аллаһ белән ант итәм, үзенә Тәүрат индерелгән Муса пәйгамбәр галәйһис-сәлам хәзер яшәгән булса, Миңа иярүдән башка һичбер юл сайламас иде", - дип аңлатып биргән. Шуның өчен Кыяматкә кадәр Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа галәйһис-сәламнең абруе һәм хөкеме генә өстен булачак.

Пәйгамбәребезне яхшылап белик! Бу галәмдәме, яки моннан соңгы галәмнәрдәме, бөтен мәхлукларга Аллаһының рәхмәте итеп җибәрелгән Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһү галәйһи вә сәлләмне яхшылап белү, аңлау һәм аңа чын өммәт булу белән генә шәрәфле, изгелекле һәм яхшы кеше булырга мөмкин. Пәйгамбәребезне белмәгән, танымаган, сөймәгән кеше дөнья тормышында да, ахирәт тормышында да шәрәфле зат була алмас.

Пәйгамбәребезнең исеме Мөхәммәд галәйһис-сәлам, әтисенең исеме Габдулла, әнисенең исеме Әминә. Ана карынында җиде айлык булганда, әтисе вафат булган. Ул милади буенча 571 нче елда, апрель аеның егерменче (рабигел әүвәлнең уникенче) дүшәмбе көненең таңында Мәккәдә туды. Туганда ул һичбер балага охшамый иде. Рәсүллек нуры күзне камаштырыр иде. Аның тууы белән кешелеккә яңа бер бәхетле дәвер ачылды. Ул дүрт яшенә кадәр сөт әнисе Хәлимәгә тапшырылды. Соңыннан үз гаиләсенә кайтарылды. Алты яшендә

әнисе Әминә вафат булды. Дәү әтисе Габделмотталиб аны үз гаиләсенә алды. Әммә әнисе вафат булып ике ел үткәч, аңа сигез яшь булганда дәү әтисе дә вафат булды. Ул агасы Әбү Талиб янында калды. Пәйгамбәребезнең балалык һәм яшьлек вакытлары, буйдаклык һәм гаиләле чаклары, кыскача бөтен тормышы һичкемгә насыйп булмаган өстенлек һәм камиллек белән үтте. Егерме биш яшендә Хәдичә анабызга өйләнде. Һичбер вакыт потларга табынмады. Балачактан ук аларны яратмый иде. Хәзрәти Ибраһим галәйһис-сәлам дине буенча Аллаһыга гыйбадәт кыла иде. Вакыт-вакыт Мәккә янындагы Хира тавына барып, Аллаһының кодрәте һәм бөеклеге турында уйлап, дога һәм зикердә була иде.

Көннәрдән беркөнне Хира мәгарәсенә кереп, дога һәм зикер кылганда Аллаһының әмере белән Җәбраил галәйһис-сәлам пәйгамбәрлек вазифасын белдерергә килде. Кешелекнең коткаручысы, Аллаһының сөеклесе Хәзрәти Мөхәммәд салләллаһү галәйһи вә сәлләмгә: “Укы!” – диде. Пәйгамбәребез: “Нәрсәне укыйм соң?” – дигәч, Җәбраил галәйһис-сәлам: “Укы!” – дип кабатлады. Хәзрәти Мөхәммәд галәйһис-сәлам дә үз җавабын кабатлады. Аннан соң Җәбраил галәйһис-сәлам Пәйгамбәребезне тотып мөбарәк күкрәген кысты. Шулай Пәйгамбәребезгә мәгънәви эшчәнлек рухы бирелде. Пәйгамбәребез бөек бер могҗиза белән кинәт укый башлады. Җәбраил галәйһис-сәлам өченче тапкыр: “Укы”,- дип әйтте һәм шушы аятьләрне укыды: “Әй Мөхәммәд, һәрнәрсәне бар кылучы Раббың исеме белән Коръәнне укы! Ул кешене оешкан каннан бар кылды. Укы, синең Раббың – Аллаһ бик хөрмәтле вә юмарт. Ул – Аллаһ каләм белән язуны өйрәтте. Кешегә белмәгән нәрсәләрен өйрәтте. (“Галәкъ” сүрәсе, 1-5 аятьләр).

Шулай итеп хәзрәти Мөхәммәд галәйһис-сәламгә пәйгамбәрлек вазифасы бирелде. Коръәни Кәрим егерме өч ел эчендә тулысынча иңдерелде. Пәйгамбәребез унөч ел Мәккә халкын дингә өндәде. Зур мәшәкатьләр һәм газаплар күрде. Һәр нәрсәгә сабыр итеп, Аллаһының барлыгын һәм берлеген белдерергә тырышты. Шуннан соң Мәдинә Мөнәүвәрәгә һиҗрәт кылды (күчеп китте). Ун ел анда рәсүллек (илчелек) вазифасын башкарды. Кешеләрне кешелеккә өйрәтте, мәдәнияткә өндәде. Караңгы күңелләрне Ислам нуры белән нурландырды. Шулай итеп вазифасын тәмамлады. Алтмыш өч яшендә мәңгелек йортка күчте. Кешелек галәменә юл күрсәтүче буларак Коръән Кәримне һәм Үзенең сөннәтен васыять итеп калдырды.

Мактау сиңа, сәлам сиңа, әй Аллаһының илчесе! Сине чыннан да белгән һәм мактаган галәмнәр Раббысы Үзе. Син рахмәтән лил-галәмин (ягъни барча галәмнәргә рәхмәт булып килдең). Син кешеләрнең һәм җеннәрнең пәйгамбәре. Син Аллаһы Тәгаләнең “Ләү ләәкә ләү ләәк, ләмәә халәктүл-әфләәк” (ягъни Син булмасаң, бер нәрсәне дә бар кылмас идем) - дип әйтелгән зат син булдың. Син Мөхәммәд Мостафа салләллаһү галәйһи вә сәлләм.

## СӘХАБӘЛӘР

Сәхабәләр – алар Пәйгамбәр әфәндебезне бер тапкыр гына булса да күреп, аның сөхбәтендә була алган мөселманнар. Сәхабәләр барысы да зур дәрәҗәләргә ирешкән кешеләр. Чөнки алар Пәйгамбәребезне үз күзләре белән күреп, иң авыр вакытларда аның тирәсендә булып, маллары һәм җаннары белән тырышып, җир йөзендә иманның һәм Исламның таралуы өчен көрәш алып барганнар, зур гайрәт (тырышлык) күрсәткәннәр. Шуңа күрә алар Пәйгамбәребезнең олы мактавына лаек булганнар. Һәммәсе дә баш түбәсеннән алып аяк табанына кадәр нурга күмелгәннәр. Динебезнең таралуында алар җитәкчелек иткәннәр. Хәзерге заманда бер кеше бөтен дөньяны яулап алып, дөнья тулы алтынны садака итеп бирсә дә, сәхабәләрнең иң кечесенең дәрәҗәсенә дә ирешә алмас. Без мөселманнар сәхабәләрне яратырга һәм хөрмәт итәргә тиешбез. Аларның араларында килеп чыккан кайбер каршылыклар турында һичкайчан сүз ачып сөйләргә ярамый, чөнки алар иҗтиһадларына(гыйлем нигезләренә) карап гамәл кылганнар. Аларның гаебен сөйләгәннәрнең иманы зәгыйф булыр, диненә зыян килер. Алар турындагы ышанычын төзәтмичә чын иман иясе була алмас.

**Сәхабәләр ике төрле:**

1. Мөһаҗирләр.
2. Әнсарлар.

Мөһаҗирләр – мал-мөлкәтләрен ташлап, Аллаһ ризалыгы өчен Мәккә Мөкәррәмәдән Мәдинә Мөнәүвәрәгә күчкән мөселманнар.

Әнсарлар – Мәдинәдә яшәгән мөселманнар. Мәккә Мөкәррәмәдән килгән мөселманнарга Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен бөтен барлыклары белән ярдәмдә булган, мал-мөлкәтләрен мөселман кардәшләре белән бүлешкәннәр.

Һәр ике төркем дә Аллаһ ризалыгы өчен кылган бу бөек эшләре өчен бөек савап һәм дәрәҗә казанганнар. Пәйгамбәрләрдән соң кешелекнең иң бөек затлары - сәхабәләр. Сәхабәләрнең иң бөекләре, өстенлек дәрәҗәсе буенча шулар: Хәзрәти Әбү Бәкер, хәзрәти Гомәр, хәзрәти Госман, хәзрәти Гали разыйаллаһү гнһүм – Аллаһ аларның барчасыннан да риза булсын.

## 5. АХИРӘТКӘ ИНАНУ

Иманның бишенче шарты – Ахирәт көненә инану. Ул Сурга өрелү һәм барча үлгәннәрнең терелеп, каберләреннән чыгуы, гамәл дәфтәрләренең үзләренә бирелүе һәм мәхшәр мәйданында тупланып, эшләгән эшләреннән сорау һәм җавап алынырга, мизан, шәфәгать, сират, кәүсәр, җәннәт, җәһәннәм кебек ахирәт хәлләренә ышану.

Ахирәт – бу дөньядан соң башланачак мәңгелек гомер. Аллаһы Тәгалә бу дөньяны һәм барлык җан иясен вакытлы гына итеп бар кылды. Исрафил галәйһиссәламнең беренче тапкыр Сур исемле коралга өрүе белән Кыямәт килеп, барлык җан иясе үләчәк, дөньядагы һәм аның тышындагы бөтен нәрсә юк булачак. Икенче өрүе белән җан ияләре яңадан терелеп, хисап бирер өчен мәхшәрдә җыйналачаклар. Анда Аллаһының хозурында эшләгән эшләреннән

хисапка тартылачак, иң вак-төяк эшләреннән хисап биреп, хаклы-хаксыздан хакын алачак.

Хисап эше беткәч, яхшылар җәннәткә, яманнар җәһәннәмгә керәчәкләр. Җәннәткә керүчеләрнең бер төркеме анда Аллаһы Тәгаләне күрәчәкләр. Ахирәткә ышанмаучы кеше Аллаһка һәм Пәйгамбәргә ышанмаучы булыр.

**ӘҖӘЛ**

Әҗәл – бәндә өчен Аллаһ тарафыннан язылып карар кылынган гомеренең бетүе. Әҗәл килгәч, бер минут ашыкмас һәм бер минут кичекмәс. Кеше ни сәбәптән үлсә дә, әҗәле белән үлер.

## 6. ТӘКЪДИР ҺӘМ КАЗАГА ИНАНУ

Иманның алтынчы шарты – тәкъдиргә инану. Тәкъдир һәм казаны яхшырак аңлар өчен иң беренче ирадәи-җүзьийәне белергә кирәк. Ирадәи җүзьийә **(**сайлау ирекe**).** Ирадәи җүзьийә - Аллаһы Тәгаләнең колларына биргән, чикләнгән дәрәҗәдәге юл сайлау хокукы. Бу төшенчәнең әһәмияте бик зур. Чөнки кеше ирадәсен (теләген) яхшылыкка юнәлтсә, Аллаһы Тәгалә яхшылыкны бар итә, начарлыкка юнәлтсә - начарлыкны бар итә. Бу яктан караганда, кеше җәннәтне дә, җәһәннәмне дә үз теләге белән казана. Әлбәттә, барлыкка китерүче бары тик Аллаһы Тәгалә генә. Ул теләмәсә, бар итмәсә, берни дә булмас. Ләкин кол кәсеп итеп (теләп казанучы), Аллаһы Тәгалә - бар итүче (ягъни бәндәнең теләген аның теләге буенча барлыкка китерүче). Кешегә бирелгән “ирадәи җүзьийә” автомобиль руле кебек: кем аны кайсы якка борса, шул тарафка китәр. Шунлыктан гөнаһ эшләүче кеше: “Мин нишлим, Аллаһ шулай боергандыр, шулай теләгәндер”, - дип кенә җаваплылыкны үз өстеннән төшерә алмый. Әйе, Аллаһы Тәгалә теләде, ләкин бәндәнең үз теләге буенча теләде. Әгәр дә бәндәләрнең ирадәи җүзьийәсе (юл сайлау хокукы) булмаса, ул чагында Аллаһ үз колын көчләп яхшы яки яман юлга керткән булып чыгар иде. Аллаһы Тәгалә бәндәсен мәҗбүри гөнаһ эшләтеп җәзалаудан азат. Кайберәүләр: “Әзәлдә (рухлар галәмендә) үк кайберләрнең рухы сәҗдә кылган, кайберәүләрнеке кылмаган, димәк, әзәлдә рухы сәҗдә кылмаган бәндәләр кәфер булып китерләр” – дип әйтерләр. Асылда эш алай түгел. Бу карашлар кешенең иманына зур зыян китерәләр. Әзәл бәхәсләшү урыны түгел. Анда теләпме, теләмичәме һәркем сәҗдә кылган. Аллаһы Тәгалә рухларны имтихан кылып: “Әләстү бираббикүм (Мин сезнең Раббыгыз түгелме?)”, - дип сорагач, барча рухлар беравыздан: “Бәлә (әйе), Син безнең Раббыбыз, йә Рабби!” – дип сүз биргәннәр. Янә кайбер ялгыш уйлаучылар: “Син нигә тырышасың, барыбер Аллаһы Тәгалә теләгәненә уңыш, теләмәгәненә уңышсызлык китерер”, - дип әйтерләр. Болай уйлау бөтенләй дөрес түгел. Бу турыдагы аять кәримәне бик күпләр ялгыш аңлаталар. Сөннәт әһеле галимнәре бу турыдагы аять кәримәне: “Аллаһ, һидаятьне теләүчеләргә һидаятьне, адашуны теләүчеләргә адашуны барлыкка китерер”, - дип аңлаталар. “Әзәлдә Әхмәт җәннәтле, Мәхмәт тәмуглы зат”, - дигән бер хөкем юк, бары тик иман киеме, итәгать киемнәре, нур

киемнәре кигәннәр – җәннәтле диелгән. Көферлек, гөнаһ, золым киемнәре дә тегелгән. Шуларны кигәннәр – тәмуглы диелгән. Һәр бәндә ирадәи җүзьийәсе белән бу киемнәрнең кайсысын теләсә, шунысын сайлар, аның шуңа тулысынча ихтыяры бар. Ягъни кеше үзенең ихтыяры белән боларның кайсысын сайласа, шуңа ия булыр”. Адәм баласы эшләгән эшләреннән үзе җаваплы булганга күрә, ирадәи-җүзьийәсе (үз теләге) белән яхшылыкны сайлап, яхшы юлда йөрергә, начарлыктан тыелып, начар юлда йөрмәскә тиешле. Шуның белән бергә көтелгән һәм көтелмәгән бәлаләрдән безне саклавы һәм гомеребезне сәләмәтлектә үткәрүебез өчен Аллаһы Тәгаләгә ялвару да бәндәләрнең мөһим бер вазифасы.

Пәйгамбәр әфәндебез бер хәдис-шәрифендә: “Сәдака бирү бәланы кайтарыр, гомерне озайтыр”, - дигән.

## ТӘКЪДИР

ТӘКЪДИР - әзәлдән мәңгелеккә кадәр булып үтәчәк вакыйгалар, хәлләр турында Аллаһы Тәгаләнең Үзенең гыйлеме буенча төзегән илаһи программасы.

КАЗА – Аллаһы Тәгаләнең гыйлеме буенча, әзәлдә төзегән илаһи программасының вакыты килгәч, тормышка ашырылуы.

## РИЗЫК

Ризык – Аллаһы Тәгаләнең җан ияләренә яшәеш өчен биргән һәм алар тарафыннан ашалган нәрсә. Ризыкны бирүче Аллаһ, ләкин бәндә үз теләге белән хәләл яки хәрам юлдан ризыгын эзләр. Хәләл юлдан эзләсә, Аллаһы Тәгалә хәләл юлдан бирер, хәрам юлдан эзләсә, хәрам юлдан бирер. Шуңа күрә дә ризыкларын хәләлдән теләмичә, хәрамнан ашаганнар, үз ирадәсе (теләге) белән ризыкны начар юлдан эзләүчеләр өчен җаваплылар. Ризыкка түгел, ризыкландыручыга өмет баглау тиешле. Һәр җанлының ризыгын бирүче Рәззакү-галәм булган зат — Аллаһы Тәгаләгә, Аңа инанырга, Аңа гына өмет бигларга кирәк. Чөнки Аның хәзинәсе мул. Аңа чын күңелдән ышанганнар кыенлык күрмәсләр. Тик бер генә туендыручы булган Аллаһыны онытып, ризыкка өмет баглаганнар кыенлык күрерләр, хәсрәттән котыла алмаслар.

## ТӘВӘККӘЛ

Тәвәккәл – максатыңа ирешү өчен, кулыңнан килгән барлык чараларны күреп, Аллаһы Тәгаләгә мөраҗәгать итеп, эшеңдә Аннан ярдәм сорау һәм көтү. Әгәр көткән өметләрең килеп чыкмаса, борчылмаска, бәлки бу минем өчен тагын да яхшырак дип риза булырга кирәк. Берәр нәрсәне булдыру өчен тырышып та, шуны булдырмасак, артык үкенмәскә һәм гөнаһ күтәрмәскә, тузынмаска кирәк.Чөнки Аллаһы Тәгалә: “Сез бер нәрсәне яратып теләрсез, чынлыкта, ул нәрсә сезнең өчен начарлыктыр һәм сез бер нәрсәне теләмәсез, чынлыкта, ул сезнең өчен яхшылык. Аллаһы Тәгалә бөтен нәрсәне белер, ләкин сез белмәсез”, - дип боерган. (“Бәкара” сүрәсе, 216 аять)

## ИМАННЫҢ ДӘВАМЛЫЛЫК ШАРТЛАРЫ

Дөньяда, кеше өчен, иң беренче чиратта кирәк булган нәрсә - иман. Бөтен кешеләр иман китерергә һәм ул иман белән ахирәткә күчәргә тиеш. Шуңа күрә барлык мөэминнәр түбәндәге шартларга игътибар итәргә тиеш:

1. Гаибкә ышану. Гаиб – биш тойгы белән сизелми торган нәрсәләр: Аллаһ, фәрештә, җәннәт, җәһәннәм, җен кебек.

2. Хәләлне хәләл дип белү, ягъни хәләл нәрсәләрне хәрам димәү.

3. Хәрам нәрсәләрне хәрам дип белү, ягъни хәрам нәрсәләргә хәләл димәү. Мәсәлән, хәмергә, процентлы бурычка һ.б. хәрам булган нәрсәләргә хәләл дип карамау.

4. Һәрвакыт Аллаһыдан курку.

5. Исламда изге дип саналган нәрсәләргә хөрмәт күрсәтеп, җиңеллек белән карамау.

6. Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтеннән өмет өзмәү.

7. Кәферне кәфер дип, мөэминне мөэмин дип белү.

Мәсәлән, бер кеше сөйләү-язу, кул-гамәл белән динне мыскыллаган һәм динне бетерергә теләгән кешеләрне мөэмин дисә, үзе кәфер булыр. Шулай ук дингә хезмәт иткән, динне куәтләгән һәм яклаган иман иясен кәфер дисә, үзе кәфер булачак.

8. Аллаһка урын күрсәтмәү, мәсәлән, Аллаһ күктә, дип урын күрсәтеп әйтү, кешене диннән чыгаруга сәбәп була.

9. Коръәнгә шөбһәсез ышану. Мәсәлән, Коръәннең кимчелеге барлыгын сөйләү, Җәбраил галәйһис-сәлам хата эшләде дип әйтү дә кешене диннән чыгара.

## ИМАННЫ САКЛАУЧЫ КАЛЬГӘЛӘР

Иман - ул мөэминнең күңелендә Аллаһ тарафыннан бирелгән бер нур. Аны саклый торган тирәлек кальгәләре түбәндәге сурәттәгечә: фарыз, ваҗиб, сөннәт, мөстәхәб, мәндүб һәм нәфел. Бу гыйбадәтләр кылынса, иман кальгә эчендә калып сакланыр. Иманны саклаучы шушы кальгәләрне җимергән кешеләр (ягъни фарыздан, ваҗибтән, сөннәттән баш тартучылар иманнарын тиешенчә саклый алмаслар. Фарыз, ваҗиб, сөннәт, мөстәхәб, мәндүб һәм нәфелләр турында алдагы битләрдә тукталачакбыз.

## МӨСЕЛМАН КЕШЕГӘ САКЛАНЫРГА ТИЕШЛЕ БУЛГАН ХӘЛЛӘР

1. Әһле сөннәткә туры килмәгән бозык инанулар.

2. Гамәлне (гыйбадәтне) ташлау.

3. Нияттә һәм гамәлләрдә турылыктан аерылу.

4. Гөнаһ эшләүне дәвам итү.

фарызлар
ваҗибләр
сөннәтләр
мөстәхәбләр
мәндүбләр

нәфелләр

5. Ислам нигмәтенә шөкер итмәү.
6. Имансыз булып китүдән курыкмау.
7. Бүтәннәргә золым кылу.
8. Сөннәт буенча укылган азанга игътибар итмәү.
9. Дингә каршы булмаган урыннарда әти-әнинең сүзләрен тотмау.
10. Күп тапкырлар ант итү.
11. Намазга җиңел карау.
12. Хәрам булган эчемлекләр эчү.
13. Мөселманнарны газаплау.
14. Ялган рәвештә үзеңне әүлия (изге бәндә) итеп күрсәтү.
15. Гөнаһыңны оныту.
16. Үз-үзең белән горурлану (үзеңне зур галим итеп күрсәтү).
17. Сүз йөртү һәм гайбәт сөйләү.
18. Мөэмин кардәшеңә көнчелек итү.
19. Мөселман җитәкчеләргә итәгать итмәү.
20. Кешене яхшы белмичә, мактау яисә хурлау.
21. Ялган сөйләү.
22. Дин галимнәренә дошманлык күрсәтү.
23. Динне өйрәнүдән баш тарту.
24. Ирләрнең хатыннарга, хатын-кызларның ирләргә охшарга теләве.
25. Дин дошманнарына хөрмәт күрсәтү.

## ӘДИЛЛӘИ-ШӘРГЫЯ (ШӘРИГАТЬ ДӘЛИЛЛӘРЕ)

Әдилләи-шәргыя – хөкемнәр чыгарыла торган чыганаклар. Болар дүртәү:

**1.** Китап — Коръән Кәрим.

**2.** Сөннәт **—** Пәйгамбәребезнең мөбәрәк сүзләре, эшләгән эшләре һәм Аның ягыннан хупланган башка кешеләрнең эшләре.

**3.** Иҗмаги-**ө**ммәт — **б**ер гасырда яшәгән Мөхәммәд галәйһис-сәлам өммәтендәге мөҗтәһидләренең бер мәсьәлә турында килешүләре.

**4.** Кыясү-фукаһа — хөкеме билгеле булмаган бер мәсьәлә турында **мө**җтәһид галимнәрнең Китапта, Сөннәттә һәм иҗмагъта хөкеме билгеле булган бер мәсьәләгә охшатып хөкем бирүләре.

Иҗтиһад — **ш**әргый хөкемне, шәргый дәлилләрдән чыгару юлында бөтен гыйльми көчне эшләтү.

Мөҗтәһид — **а**ятьләрдән һәм хәдис шәрифләрдән хөкем чыгара белгән зур галим. Мөҗтәһид булу өчен бөтен ислам гыйлемнәрен бик яхшы белгәннән соң, мәүһибү-илаһи (Аллаһ бүләге) булган гыйлемгә дә ия булу тиешле.

## ГЫЙЛЕМНЕҢ ЮЛЛАРЫ ҺӘМ БЕЛЕМ ЧАРАЛАРЫ

Гыйлемнәрнең юллары өч.

**1 –** Хәвасү-сәлимә — күрү, ишетү, тәм тою, тию һәм иснәү тойгылары.

**2 –** Хәбәри садыйк **— д**өрес хәбәр. Бу ике бүлемнән тора:

а) Пәйгамбәрләрнең китергән хәбәрләре;

б) Ялганга кушылулары мөмкин булмаган бер төркемнең китергән хәбәре.

**3 –** Акыл.

## МӘЗҺӘБЛӘР

Мәзһәб – бөек дин мөҗтәһидләренең шәргый дәлилләрдән чыгарган мәсьәләләрнең һәм хөкемнәрнең җыентыгы. Мәзһәбләр ике өлешкә бүленә**:**

1. Игътикаттагы мәзһәб.
2. Гамәлдәге мәзһәб.

Игътикаттагы хак мәзһәб - әһле сөннәт вә җәмәгать мәзһәбе. Бу Пәйгамбәр әфәндебез галәйһис-сәламнең һәм сәхәбәләрнең инанган һәм эш иткән юлы. Әһле сөннәт вә җәмәгать мәзһәбенең игътикаттагы имамнары:

1 – Имам Әбү Мансур Матуриди;

2 – Имам Әбү Хәсән Әшгари.

Хәнәфи мәзһәбенә караган мөселманнарның игътикаттагы имамы Әбү Мансур Матуриди. Имам Әбү Мансур Мөхәммәд Матуриди хәзрәтләре һиҗри буенча 280 нче (милади буенча 894 нче) елда Төркестанның Сәмәрканд шәһәре тирәсендәге Матурид авылында туып һәм яшәп, һиҗри буенчп 333 нче (милади буенча 945 нче) елда Сәмәркандта вафат булган.

Имам Әшгари хәзрәтләре һиҗри буенча 260 (милади буенча 873 нче) елда Басра шәһәрендә туган, һиҗри буенча 324 нче (милади буенча 936 нче) елда Багдадта вафат булган.

## ГАМӘЛДӘГЕ (ГАМӘЛИ) ХАК МӘЗҺӘБЛӘР

Әһле сөннәт вә җәмәгатьнең гамәлдәге мәзһәбләре дүрт:

**1.** Хәнәфи мәзһәбе**:** имамы – Имам Әгъзам Әбү Хәнифә. Үз исеме Ногман, этисенең исеме Сәбит. Һиҗри буенча 80 нче (милади буенча 699 нчы) елда Күфәдә туган, һиҗри буенча 150 нче (милади буенча 767 нче) елда Багдадта вафат булган.

**2.** Мәлики мәзһәбе**:** имамы – Имам Мәлик бине Әнәс. Һиҗри буенча 93 нче (милади буенча 711 нче) елда Мәдинә-Мөнәүвәрәдә туып, һиҗри буенча 179 нче (милади буенча 795 нче) елда шунда ук вафат булган.

**3.** Шәфигый мәзһәбе**:** имамы – Имам Мөхәммәд бине Идрис Шәфигый. Һиҗри буенча 150 нче (милади буенча 767 нче) елда Газзәдә туып, һиҗри буенча 204 нче (милади буенча 819 нчы) елда Мисырда вафат булган.

**4.** Хәнбәли мәзһәбе**:** имамы – Имам Әхмәд бине Мөхәммәд бине Хәнбәл. Һиҗри буенча 164 нче (милади буенча 780 нче) елда Багдадта туып, һиҗри буенча 240 нче (милади буенча 855 нче) елда шунда ук вафат булган.

Гамәлдәге берәр хак мәзһәб булган һәм югарыда аңлатылган мәзһәбләр Китап, Сөннәт, Иҗмагъ һәм Кыяс нигезендә корылган. Пәйгамбәребез исән вакытта, мөселманнар төрле мәсьәләләрне Пәйгамбәребездән, аннан соң сәхабәләрнең бөекләреннән сорап беләләр иде. Мәзһәб имамнары буларак билгеле булган бу мөбарәк затлар дини мәсьләләрне сәхабәләрдән өйрәнгәннәр

һәм туплаганнар. Аять, хәдис һәм сәхабәләрнең сүзләрендә булмаган очракларда да үзләренең карашларын, тырышлыкларын күрсәткәннәр. Шул рәвешчә мәзһәбләр мәйданга килеп чыккан.

## ИСЛАМНЫҢ ШАРТЛАРЫ

Ислам – ул Рәсүлулла әфәндебезнең безгә тапшырган нәрсәләрне тел белән икърар итеп һәм күңел белән кабул итеп Аллаһы Тәгаләгә итәгать итү. Исламның шатлары биш, ягъни Ислам дине биш нигезгә корылган.

**1.** Кәлимәи-шәһәдәт**.**

**2.** Намаз**.**

**3.** Зәкят**.**

**4.** Ураза**.**

**5.** Хаҗ**.**

Исламның шартларын җиренә җиткерүче кешене мөэмин һәм мөселман дип әйтәләр. Бу шартларның берсен генә булса да кабул итмәүче - динсез дип санала.

## КӘЛИМӘИ-ШӘҺАДӘТ

Исламның беренче шарты булган кәлимәи-шәһадәт түбәндәгедән гыйбарәт: әшһәдү ән ләә иләәһә иллә-ллааһү үә әшһәдү әннә мүхәммәдән габдүһүү үә расүүлүһ.

Мәгънәсе**:** Мин шәһадәт кылам, Аллаһыдан башка илаһ юк. Янә шәһадәт кылам, Мөхәммәд Аның колы һәм илчесе.

## ӘФГАЛИ МҮКӘЛЛӘФИН

Ислам дине камил акыллы, балигълык яшенә җиткән һәр мөселман иргә һәм хатын-кызга кайбер әмерләрне һәм тыюларны билгеләгән. Бу әмерләр һәм тыюлар йөкләнгән затларга мөкәлләф диелә.

Мөкәлләфләрнең кылырга яки кылмаска тиешле булган эшләренә - әфгали-мүкәлләфин диелә.

ӘФГАЛИ МҮКӘЛЛӘФИН СИГЕЗ

**1.** Фарыз — катгый дәлил белән кушылган нәрсәләр. Фарыз ике кисәктән тора:

а) Фарыз гәйн***:*** һәр мөкәлләф мөселманның, үзенең эшләве белән генә үтәлә торган нәрсәләр: биш вакыт намаз, ураза кебек.

б)**.** Фарыз-кифәя***:*** кайбер мөселманнарның үтәве белән башка мөселманнардан җаваплылыкны төшерә торган нәрсәләр: җеназа намазы, сәлам кайтару кебек. Әгәр бу фарызны беркем дә эшләмәсә, мөселманнарның барысы да җаваплы булып калырлар. Фарызның хөкеме**:** фарызны инкарь иткән кеше диннән чыгар, үтәгән кеше савапланыр, үтәмәгән кеше дә газапка лаеклы һәм фасикъ (гөнаһлы) булыр.

**2.** Важиб **—** фарыз дәрәҗәсендә булмаса да, шәригать тарафыннан кушылган нәрсәләр, витыр һәм бәйрәм намазлары кебек. Важибның хөкеме**:**

важибны инкарь иткән кеше диннән чыкмас, үтәгән кеше савапланыр, ә үтәмәгән кеше фарызның газабыннан кимрәк газапка лаеклы булыр.

**3.** Сөннәт **—** Пәйгамбәребезнең сүзе, эшләгән эше һәм башка кешенең эшләгәнен хуплаган, мактаган нәрсәләр. Сөннәт икегә бүленә:

а) Сөннәти-мөәккәдә*:* Пәйгамбәребез даими үтәгән, сирәк очракта гына калдыра торган нәрсәләр, иртәнге һәм өйлә намазларының сөннәтләре кебек. Сөннәти-мөәккәдәнең хөкеме: аны үтәгән кеше савапланыр, үтәмәгән кеше хурланыр.

б) Сөннәти гайри-мөәккәдә*:* Пәйгамбәребез сирәк вакытта үтәгән нәрсәләр, икенде һәм ястү намазларының әүвәлге сөннәтләре кебек. Сөннәти гайри-мөәккәдәнең хөкеме*:* аны үтәгән кеше савапланыр, үтәмәгән кеше исә хурланмас. Сөннәтләргә игътибар бирмәгән кешеләр Пәйгамбәребез галәйһис-сәламнең шәфәгатеннән мәхрүм булырлар.

**4.** Мөстәхәб **—** Пәйгамбәребез кайбер вакыт үтәгән нәрсәләр. Мәсәлән, садака бирү, нәфел ураза тоту кебек.

**5.** Мөбах — бу гамәл кылынса да, кылынмаса да савап та, гөнаһ та булмас, утыру, тору, ашау кебек.

**6.** Мәкруһ — эшләнүе хупланмаган һәм гамәлнең савабын киметкән нәрсәләр. Мәкруһ ике төрле:

а***).*** Тәхрими-мәкруһ*:* хәрам дәрәҗәсендә булмаса да, шәригать тарафыннан тыелган нәрсәләр. Мисал: Рамазан бәйрәме көнендә ураза тоту кебек. Тәхрими-мәкруһның хөкеме*:* аны кылган кеше газапка лаеклы булыр, ләкин кәфер (динсез) дип саналмас.

б***)*** Тәнзиһи-мәкруһ*:* катгый булмаган рәвештә тыелган нәрсәләр. Мисал: намазда як-якка карау кебек. Тәнзиһи-мәкруһның хөкеме*:* гыйбадәтнең савабын киметер.

**8.** Хәрам — катгый рәвештә тыелган нәрсәләр, мәсәлән: исерткеч эчү, әти-әнигә карата явызлык эшләү кебек. Хәрамның хөкеме*:* аны кылган кеше ут газабына лаеклы булыр, кылмаган кеше савапланыр, хәрамны инкарь иткән кеше кәфер (динсез) булыр.

## НАМАЗ

Исламның икенче шарты – намаз. Аллаһы Тәгаләгә иман китерү – иң бөек фарыз. Шуңардан соң фарызларның иң олысы һәм мөһиме – намаз. Чөнки намаз – чын иман галәмәте. Барлык илаһи диннәрдә дә намаз гыйбадәте бар. Намазның фарызлары унике. Аның тышындагы фарызларны шарт дип, эчендәге фарызларны әркән дип атыйлар.

Намазның шартлары:

1. Хәдәстән тәһарәт.
2. Нәҗестән тәһарәт.
3. Сәтри гаурәт.
4. Истикбәли кыйбла.

5. Вакыт.

6. Ният.

Намазның әркәннәре:

1. Ифтитәх тәкбире.
2. Кыям.
3. Кыраәт.
4. Рукүг.
5. Сәҗдә.
6. Кәгъдәи-әхыйра.

**ХӘДӘСТӘН ТӘҺАРӘТ**

Намаз шартларының беренчесе – хадәстән тәһарәт. Хәдәс ике төрле була**:** **к**ече хәдәс — тәһарәте булмау. Олы хәдәс — җенси мөнәсәбәттән соң яки төшләнүдән соң җөнеб хәлендә булу яисә хатын-кызларның нифас һәм ай башы хәлләре.

Хатын-кыз булса да, ир-зат булса да, намаз кылачак кеше тәһарәтсез икән, тәһарәт алу, ә җүнүб икән госел коену шарт.

## ТӘҺАРӘТ

Тәһарәт – билгеле әгъзаларны тәртип буенча юудан һәм мәсех кылудан торган дини бер пакьләнү. Тәһарәтсез кешегә намаз укырга, Кәгъбәне таваф кылырга, футляр эчендә булмаган Коръәнне кулга алырга ярамый. Үзенең тәһарәтсез икәнлеген белгән хәлдә намазга керешкән кеше диннән чыгар.

**ТӘҺАРӘТНЕҢ ФАРЫЗЛАРЫ**

Тәһарәтнең фарызлары дүрт:

1. Йөзне юу.
2. Кулларны терсәкләре белән бергә юу.
3. Башның дүрттән бер өлешенә мәсех кылу (ягъни кулыңны чылатып, башны сыйпап алу).
4. Аякларны тубыклары белән бергә юу.

**ТӘҺАРӘТНЕҢ СӨННӘТЛӘРЕ**

1. Ният кылу.
2. Әгузү-бисмилләһ белән башлау.
3. Элек кулларны беләзекләргә хәтле юу.
4. Мисвәк куллану.
5. Бер әгъза корыганчы икенчесен юу.
6. Авызны һәм борынны өч тапкыр су белән чайкау.
7. Колакларга мәсех кылу.
8. Юганда бер кул бармакларын, икенче кул бармаклары арасына тыгып ышку.
9. Әгъзаларны өчәр тапкыр юу.
10. Башны тулысынча мәсех кылу.
11. Тәһарәтне тәртип белән алу.

12. Кул һәм аякларны юганда бармак очларыннан башлау.

Тәһарәт алганда укыла торган берничә дога булса да, иң яхшысы бөтен әгъзаларны юганда “Бисмилләһ” әйтеп шәһадәт китерү.

**ТӘҺАРӘТНЕҢ МӘКРУҺЛАРЫ**

1. Уң кул белән сеңгерү.
2. Әгъзаны өч тапкырдан артык яисә кимрәк юу.
3. Суны йөзгә каты бәрү.
4. Кояшта җылынган су белән тәһарәт алу.
5. Суны бик аз яки бик күп куллану (ягъни исраф итү).
6. Тәһарәт алганда сөйләшү.
7. Сөннәтләрне калдыру.

**ТӘҺАРӘТНЕ БОЗА ТОРГАН НӘРСӘЛӘР**

1. Алдан һәм арттан чыккан нәрсәләр.
2. Тәннән кан, эрен һәм сары су чыгу.
3. Авыз тутырып косу.
4. Тилерү.
5. Исерек булу.
6. Хушны югалту.
7. Арттан җил чыгару.
8. Ятып, аякларны бер-берсенә чалыштырып яки аякларны як-якка җибәреп утырган хәлдә йоклау. (Арт өлешне тулысынча бер урынга урнаштырган хәлдә йоклау тәһарәтне бозмас).
9. Намаз эчендә башкалар ишетерлек дәрәҗәдә көлү.
10. Тешләр арасыннан чыккан кан төкерек кадәр яисә шуннан артык булу. Кан төкеректән азрак булганда тәһарәтне бозмаган кебек, чәчне кыру һәм тырнак кисү кебек эшләр дә тәһарәтне бозмаслар.

**ТӘҺАРӘТ НИЧЕК АЛЫНА?**

1 - Мөмкин булса, кыйблага юнәлеп, биегрәк урынга утырып, чын күңелдән ниятләп “әгузү-бисмилләһ” әйтелә.

2 – Куллар беләзекләргә кадәр өч тапкыр юыла. Бармаклар арасына бармаклар кертеп ышкыла. Бармакта йөзек булса, аны кузгатып, асты чылатыла (ягъни бармакта юылмаган урын калмаска тиеш) (рәсем 1).

3 – Бисмилләһ әйтеп авызга су алына (рәсем 2). Мисвәк (теш чистарткыч) белән, әгәр дә булмаса, баш бармак һәм шәһадәт бармагы белән тешләр чистартыла. Авыз тагын ике тапкыр чайкала (рәсем 3).

4 – Бисмилләһ әйтеп, борынга су алына (рәсем 4). Уразалы булмаган чакта, су борынның канатларына кадәр җиткерелеп, сул кул белән борын сөртелә. Бу эш тагын ике тапкыр эшләнелә.

5 – Бисмилләһ әйтеп учка су алып, йөз, чәч чигеннән башлап ияк астына, ян тарафлардан да колак йомшакларына кадәр юылыр (кашларның төбе дә

юылыр). Бу эш тагын ике тапкыр эшләнә. Һәр юылуда битләр дә сыпырыла (рәсем 5).

6 – Бисмилләһ әйтеп, башта уң кул терсәкләре белән бергә өч кат ышкылып юыла. Аннары шул рәвешчә сул кул өч тапкыр сөртелеп юыла (рәсем 6, 7).

7 – Бисмилләһ әйтеп, уң кул белән башның дүрттән бере мәсех кылына (рәсем8). Шуннан соң шәһәдәт бармаклары белән уң һәм сул колак эче, баш бармаклар белән колак арты мәсех кылына (рәсем 9).

Кулның баш һәм шәһәдәт бармакларыннан башка калган өч бармакның тышкы ягы белән муен мәсех кылына (рәсем 10).

Башка тулысынча мәсех кылу сөннәт. Аңа каплама мәсех диләр. Каплама мәсех болай эшләнә — **сө**ннәт буенча каплама мәсех алмакчы булсаң, ике кулны чылатып, баш һәм шәһадәт бармакларны аерып, калган өч бармаклар бер-берсенә тоташтырылыр. Аннан соң куллар эчке яклары белән чәч башланган (ягъни маңгайдан өстәрәк) урынга китерелер. Баш һәм шәһадәт бармаклары белән уч эчен югарырак тотып, ике кулны артка таба тартып мәсех кылына. Башның ян-яклары уч белән арттан алга таба мәсех кылына. Шуннан соң баш бармаклар белән колак арты мәсех кылына. Муен арты калган өч бармакның тышкы ягы белән мәсех кылына. Бугаз мәсех кылынмый.

8 – Бисмилләһ әйтеп, аякларның очыннан башлап, сул кулның чәнти бармагы белән бармак аралары сөртелә (рәсем 11). Сөртү уң аякның чәнти бармагыннан, сул аякның баш бармагыннан башлана һәм астан өскә таба юнәлтелә. Аяклар тубыклары белән юыла һәм һәр аякны юа башлаганда Бисмилләһ әйтелә (рәсем 12).

Тәһарәттән соң артып калган судан кыйблага карап берничә йотым эчелә. Ике-өч тапкыр “Кадер” сүрәсен уку мәндүб.

### КАДЕР СҮРӘСЕ

Иннәә әнзәлнәәһү фии ләйләтил-кадр. Үә мәә әдраакә мәә ләйләтүл-кадр. Ләйләтүл-кадри хайрум мин әлфи шәһр. Тәнәззәлүл-мәләәикәтү үәр-рууху фииһәә би изни раббиһим мин күлли әмр. Сәләәмүн һиә хаттәә мәтләгыйл фәҗр.

Мәгънәсе**:** Хак сүз ки, без моны (Коръәнне) Кадер кичәсендә иңдердек. Кадер кичәсенең (шул бөек фазыйләтен) сиңа белдергән нәрсә ни? Кадер кичәсе мең айдан да хәерлерәк. Шул кичәдә фәрештәләр һәм Рух (Җәбраил) Раббыларының рөхсәте белән бер эш өчен җиргә иңәр. Ул кичә таң атканчыга кадәр бер сәләм (тынычлык).

## ГОСЕЛ

Госел – авызны һәм борынны чайкау белән бергә бөтен тәнне юу. Шул хәлләрдә юыну тиешле:

1 – Якынлык кылганнан соң.

2 – Йокыда төшләнүдән соң (ихтиләм-поллюция).

3 – Хатын-кызларның ай һәм нифас хәлләре беткәннән соң.

**ГОСЕЛНЕҢ ФАРЫЗЛАРЫ**

Госелнең фарызлары өч:

1 – Авызны чайкау.

2 – Борынны чайкау.

3 – Бөтен тәнне юу.

**ГОСЕЛНЕҢ СӨННӘТЛӘРЕ**

1 – Ният итү.

2 – Бисмилләһ әйтү.

3 – Әүвәл гаурәт төшләрне юу.

4 – Әүвәл башка, аннары уң һәм сул кулбашларына өчәр тапкыр су коеп, һәр коюда тәнне ышку.

5 – Гаурәт төшләрне ябык тоту.

**ГОСЕЛ ТӘҺАРӘТЕ НИЧЕК АЛЫНА?**

Сөннәт буенча госел тәһарәте түбәндәгечә башкарыла:

1 – Госелгә ният ителә. Чиста булса да куллар, алгы һәм арткы гаурәт төшләре юыла.

2 – Бисмилләһ әйтеп, тулы бер намаз тәһарәте алына. Аяк астына су җыела торган булса, аяклар иң соңыннан юыла.

3 – Госел тәһарәтендә авыз-борын бик мул су белән чайкала, чөнки бу чайкау госелдәге фарыз булган авыз һәм борын эчен юу урынына килә.

4 – Башка өч тапкыр су коела һәм һәр койганда чәчләр ышкыла. Сакал-мыек һәм чәчләр төбенә дә суны ирештерү тиешле.

5 – Уң һәм сул кулбашларга өчәр тапкыр су коела һәм һәр коюда тән ышкылып юыла.

6 – Кендек чокыры да юыла, (ягъни бер җир дә коры калмаска тиешле).

**ГОСЕЛ ТӘҺАРӘТЕ ҺӘМ ЯСАЛМА ТЕШ МӘСЬӘЛӘСЕ**

Вакыт-вакыт кайберәүләрнең: “Каплатылган, ясалма яки пломба куелган теше булган кешеләрнең госелләре дөрес түгел, алар тәһарәтсезлектән котыла алмыйлар”, - дип сөйләүләрен ишетергә туры килә. Хәнәфи мәзһәбе буенча, госелдә авыз белән борын тәннең тышкы ягыннан саналганга күрә, аларны юу фарыз. Шәфигый мәзһәбе буенча сөннәт. Тешләр каплатылган яисә пломбаланган булса, каплама һәм пломбаның тышын юу белән госел тәмам булыр. Әмма ул теш яисә капламалар алына торган булса, аларны алганнан соң гына авызны чайкарга кирәк. Тик шул чакта гына госел тәмам була. Капланган теш мәсьәләсе бәйләгеч өстенә мәсех кылу кебек, ягъни бәйләгечне чишеп астын юмыйча мәсех кылу җиткән кебек, капланган тешнең һәм пломбаның тышын юу җитә. Шулай ук тәһарәттә йөзне юу фарыз булган хәлдә, сакалы тыгыз булган кешеләргә сакал өстен юу яраган шикелле, ягъни сакал төкләренең төбенә кадәр юу мәҗбүрияте булмаган кебек, капланган һәм пломбаланган тешләрне дә сүтеп юу тиешле түгел.

**ТУТЫРМАЛЫ ТЕШ МӘСЬӘЛӘСЕ**

Тешнең бераз черегән яисә киртелгән урыннары булган кешегә аны бөтенләй суыртмыйча, тешнең чокырлы җирен тутырту һәм каплату ярый. Әмма мондый ихтыяҗ булмаса, матур булсын дип кенә теш куйдыру ярамый. Хәнәфи мәзһәбенең мөҗтәһидләреннән булган Имам Мөхәммәднең әйтүе буенча, какшаган тешләрне алтын җеп белән бәйләү, төшкән яисә алынган теш урынына алтын теш кую да рөхсәт ителә. Имам Әбү Хәнифә буенча, алтын белән ярамый, ләкин көмеш белән ярый. Имам Әбү Йосыф бер риваятьтән чыгып, Имам Мөхәммәд кебек үк фәтва биргән. Галимнәр Имам Әбү Йосыф һәм Имам Мөхәммәд хәзрәтләренең иҗтиһады (фикере) белән фәтва биргәннәр. Каплатмалы теш мәсьәләсендә Имам Әгъзам (рәхимәһүллаһ) бу эш ярамый димәгән. Ислам динендә җиңеллек ясыйбыз дип, Шәригать буенча тыелган нәрсәгә рөхсәт бирергә һәм рөхсәт бирелгән нәрсәне дә тыярга ярамый.

## ТӘЯММУМ

Тәяммум – тәһарәт алу яки госел коену өчен су булмаган яисә суны куллану мөмкин булмаган очракларда, тәяммум алуга ният итеп, кулларны туфрак җенесеннән булган бер нәрсәгә ике тапкыр сугып, беренчесендә йөзне, икенчесендә кулларны (терсәкләргә кадәр) мәсех кылу.

**Тәяммумның фарызлары ике:**

1 – Ният итү;

2 – Ике мәртәбә сугу һәм мәсех кылу.

## ТӘЯММУМ НИЧЕК АЛЫНА?

Әгәр берәр мөселман, госелләнү яисә тәһарәт алу өчен су тапмаса, яки бер авыруы сәбәпле су белән юынырга ярамаса, яки дошманнан курыкса, ягъни җитди сәбәпләр булса, туфрак җенесеннән бер нәрсә белән тәяммум алырга ниятләр. Ул болай башкарыла: нияттән соң, “Әгүзү бисмилләһ” әйтеп кулларны туфракка, яки туфрак җенесеннән булган нәрсәгә сугып, алга-артка йөртелер, аннары шул куллар белән битне мәсех кылыныр. Куллар белән тагын бер тапкыр шулай ук туфракка сугылыр, алга-артка йөрткәч, башта уң, соңыннан сул кул мәсех кылыныр. Тәяммум алганда йөзекне чыгару яисә урыныннан кузгатып йөзек урынының да мәсех кылынуы һәм бармак араларының да уылуы лязем.

## ЧИТЕК ӨСТЕНӘ МӘСЕХ КЫЛУ

Ир-ат һәм хатын-кыз өчен читек өстеннән мәсех кылу рөхсәт ителә.

Моның өчен түбәндәге шартлар үтәлергә тиеш:

1 – Читек тәһарәтле вакытта киелгән булуы;

2 – Читекләр бергә аякларны тубыкларына кадәр ябарга һәм 12 мең адым үтәрлек дәрәҗәдә нык булырга тиеш.

3 – Читекнең берсендә дә, аяк бармакларының иң кечкенәсе белән санаганда өч бармак сыярлык кадәр тишек булмаска тиеш;

4 – Читек эченә су керерлек булмаска һәм бәйләмичә дә аякта торырлык, калын булырга тиеш.

5 – Читек киеләчәк аякның алгы ягыннан кимендә кул бармагы белән өч бармак киңлегендә акның бер өлеше булырга тиеш (бер аягы киселеп тубыгы гына калган кеше икенче аягына да читек киеп мәсех кылмас).

**МӘСЕХНЕҢ МИКЪДАРЫ**

Читекнең алгы ягыннан өч чәнти бармак кадәр бер урынын сөртү белән фарыз мәсех тәмам булыр. Сөннәт буенча кылынган мәсех исә, чылатылган кул бармакларын ачып, аяк очыннан башлап читек кырыена кадәр сөртүдән тора.

**МӘСЕХНЕ БОЗА ТОРГАН НӘРСӘЛӘР**

1 – Читекнең аяктан төшүе, чыгуы;

2 – Читекләр аякта чакта ике аяктан берсенең күбрәк өлешенең юешләнүе;

3 – Мәсех вакытының чыгуы (сәфәрдәге кеше өчен бу вакыт читекне кигән вакыттагы тәһарәтнең бозылуыннан башлап 72 сәгать, сәфәрдә булмаган кеше өчен 24 сәгать);

Тәһарәтне бозган һәр нәрсә мәсехне дә боза. Шуның өчен, мәсех вакыты әле бетмәсә дә яңадан тәһарәт алганда мәсех тә кылына.

**БӘЙЛӘГЕЧ ҺӘМ ЯРА ӨСТЕННӘН МӘСЕХ КЫЛУ**

Әгәр берәр әгъза имгәнсә, яраланса, аның өстеннән бинт, пластырь һ.б. нәрсә белән бәйләп куелса һәм ул әгъзаны юу да читенрәк булса, шул бинт, пластырь өстеннән мәсех кылырга ярый. Әгәр мәсех тә зарар китерсә, ул эшләнмәс. Моның читек өстенә мәсех кылудагы кебек, чыгу вакыты юк. Ялалы-бинтлы хәл күпме дәвам итсә, шулкадәр вакыт мәсех кылырга ярый һәм бинтның тәһарәтле хәлдә бәйләнүе да шарт түгел. Мәсех кылынгач, бинт төшсә яки ачылса, кабат мәсех кылынмый. Шулай ук, бинт өстенә икенче бинт уралса да, мәсех кабатланмый.

Ике аякның берсендә генә бинт булса, шул аяк кына мәсех кылына.

## ХАТЫН-КЫЗНЫҢ МАХСУС ХӘЛЛӘРЕ

Хатын-кыз өчен махсус өч хәл бар:

**1 –** Хәез (менструация, күрем);

**2 –** Нифас**;**

**3 –** Истиһаза**.**

*1* – Хәез – җитлеккән хатын-кызның җенси әгъзасыннан билгеле бер вакытларда кан килүе. Хәез каны 9 яшьләрдә башланып, якынча 55 яшь тирәсендә тәмамланыр. Бу рәвештә килгән канга “хәез каны” һәм бу хәлгә хәез хәле яки ай башы көннәре диелер.

*2* – Нифас – бала туганнан соң аккан кан.

*3* – Истиһаза – Хәез күрә торган хатыннан өч көннән аз яки ун көннән артык җенси әгъзасыннан килгән канга истиһаза каны диелә. Бала тапкан хатыннан исә кырык көннән артык килгән канга да истиһаза каны диелә. Бу хәлдәге хатын-кызга “мөстаһаза” диелә. Бу хәл хатын-кызның намазына да, уразасына да зыян китермәгән кебек, җенси мөнәсәбәткә дә каршы килми. Истиһаза каны килгән хатын-кыз, һәр намаз вакыты башында тәһарәт алып

намаз укый. Ул дәвамлы борыннан аккан кан кебек. Хәезнең иң аз вакыты - өч көн һәм өч төн, иң күп вакыты – ун көн һәм ун төн.

Ике хәез арасындагы пакьлек хәленә “туһур” диелә: моның иң аз вакыты унбиш көн булып, иң күп вакытының билгеле бер чиге юк.

Нифасның да билгеле бер вакыты-чиге юк. Кайбер хатыннарның бала табудан соң кан килүе булмый. Андый хатыннарга шунда ук госел коенып, намаз һәм бүтән гыйбадәтләрне үтәргә кирәк. Нифасның иң озак вакыты бала тапканнан соң кырык көн. Игзәк бала тапкан хатынның нифас вакыты беренче баланы табу вакытыннан исәпләнә. Хатынның давам итеп килгән хәез вакытында була торган туһур, ягъни кан килмәгән вакыт та хәездән саналыр. Мәсәлән, иң аз хәез вакыты саналган өч көндә, беренче һәм өченче көннәрдә кан килеп, икенче көн килмәсә дә, икенче көндә дә хәезле саналыр. Хәезнең беткәнен аңлау өчен аккан канның төсенең тулысынча ак төскә әйләнүе лязем. Аккан кан кызыл төстә генә булмый, туфрак төсендә дә, тонык, яшел, сары яки кара төстә дә булырга мөмкин. Кайбер хатыннарның гадәти көннәре үзгәрә торган була. Мәсәлән, бер айда гадәти көннәре алты көн, икенчесендә биш көн булырга мөмкин. Хәезе бишенче көнне тәмамланган хатын госел коенып намазларын һәм башка гыйбадәтләрен үтәргә тиеш, ләкин алтынчы көнне дә ире белән якынлык кылмаска тиеш.

Кайбер хатынның хәез көннәре билгеле булып үтәр, мәсәлән: һәр ай 6,7 яки 9 көн хәез күрерләр. Бер хәез гадәте бер тапкыр булу белән билгеләнгән булып санар. Мәсәлән, беренче тапкыр хәез күрә башлый. Бер кыз 7 көн кан күреп, моннан соң пакьләнсә, аның гадәте 7 көн буларак билгеләнгән булыр.

## ХӘЕЗ ҺӘМ НИФАС ХӘЛЛӘРЕНДӘ ХӘРАМ БУЛГАН НӘРСӘЛӘР

*1.* Намаз уку. Хәез һәм нифас вакытында намаз укылмый һәм бу хәлдә укылмый калган намазларны каза кылырга да кирәкми. Тиләвәт һәм шөкер сәҗдәләре дә кылынмый. Әмма ул хатын-кыз теләсә, намаз вакытында тәһарәт алып, (кулына тәсбих алып) “әстәгъфиру-ллаһ”, “сүбхәна-ллаһ”, “әлхәмдү лилләһ” кебек сүзләр әйтеп зекер итеп утырыр.

*2.* Ураза тоту. Хәез һәм нифас вакытында ураза тотылмый. Ләкин Рамазан уразасын соңыннан каза кылырга кирәк.

*3.* Коръән-Кәримне уку. Тик зекер, мактау яки дога мәгънәсендә булган аятьларне шундый максатлар белән укырга мөмкин, ләкин хөкем һәм хәбәр белдергән аятьлар дога, мактау һәм зикер максаты белән булса да укылмас.

*4.* Коръәнгә кул тидерү. Бу хәлдә кәгазь, тукыма яисә дивар (стена) өстенә булса да язылган аятьләргә кул тидерелми. Тик тегелмәгән яки Коръәнгә ябышмаган футляр белән генә тотарга мөмкин. Киемнең җиңе белән тотыну тәхрими-мәкруһ санала.

*5.* Мәчеткә керү (мәдрәсәгә керергә мөмкин).

*6.* Кәгъбәне таваф кылу (Кәгъбә тирәли йөрү).

*7.* Ире белән якынлык кылу.

*8.* Ире хатынының кендек белән тез капкачлары арасыннан ялангач буларак файдалану.

Әмма ире белән бер урында киенгән килеш ятып торудан гөнаһ юк. Шулай ук ул әзерләгән ашамлык һәм эчеп калдырган сулар беркемгә дә мәкруһ түгел.

## НӘҖЕСТӘН ТӘҺАРӘТ

Намаз шартларының икенчесе – нәҗестән пакьләнү, ягъни намаз укыйсы урында, тәнендә һәм киемендә намазны боза торган пычрак булса, шуларны чистарту.

**Нәҗес ике төрле:**

1 – Зур нәҗес: кешенең артыннан яки алдыннан чыккан нәрсә, ите ашалмаган хайваннарның бәвеле, селәгәе, тизәге һәм тавыкның, казның тизәге, кан, мәни, эрен, мәзи, вәди (җенси әгъзадан чыккан төссез су), авыз тутырып косу, хәрам эчемлекләр. Каты нәрсәләрнең 3,2 граммнан артыгы, сыекларының уч төбеннән артык булуы намазны боза.

2 – Кече нәҗес: ите ашала торган хайваннарның һәм ите ашалмаган кошларның тизәге. Бу нәҗесләр тәннең яки киемнең дүрттән береннән артык өлешендә булса, намазы бозыла.

ИСТИНҖӘ, ИСТИНКА, ИСТИБРА.

Истинҗә*:* хаҗәтне үтәгәннән соң нәҗес чыккан урынны чистарту.

Истинка*:* хаҗәттән соң коры нәрсә белән сөртеп, аннары су белән юып корыту.

Истибра*:* ирләрнең бәвел кылгач, җенси әгъзасын ютәлү яки төрле хәрәкәтләр белән калган бәвелдән арыну.

## СӘТРИ ГАУРӘТ

Ир затларның гаурәт өлеше кендегеннән тез капкачының аскы өлешенә кадәр, хатыннарның беләзеккә кадәр куллары, тубыкларга кадәр аяклары һәм йөзләреннән тыш калган өлешләре гаурәт дип санала.

## ИСТИКЪБӘЛИ КЫЙБЛА

Намаз шартларының дүртенчесе – истикъбәли-кыйбла, Мәккәдә Кәгъбәне күрүчеләр өчен Кәгъбәнең үзенә юнәлүе, еракта булып, Кәгъбәне күрмәүчеләр өчен Кәгъбә ягына юнәлү җитә.

## ВАКЫТ

Намаз шартларының бишенчесе – вакыт, ягъни намазның билгеләнгән сәгатьләре. Вакыты кермичә укылган намаз дөрес дип саналмас. Намаз вакытлары һәр өлкәнең үзенә махсус календарьлары белән билгеләнә.

### КӘРАҺӘТ ВАКЫТЛАРЫ

Өч вакыт эчендә намаз укырга ярамый:

1 – Кояш чыкканда: Имам Әгъзам буенча – 48 минут, Имамәйни буенча – 32 минутлык вакыт аралыгы;

2 – Кояш зенитта булганда: өйлә намазыннан чама белән беренче 15-20 минут вакыт эчендә;

3 – Икенде вакытыннан соң: кояш батканда, ягъни ахшам намазыннан әүвәл 45 минут булган вакыт. Бу вакытта бары ул көннең икенде намазы гына укылыр. Бу өч вакытта казага калган фарыз намазлар, ваҗиб намазлар, җеназа намазы укылмас. Кәраһәт вакыты алдыннан укылган сәҗдә аяте өчен бу вакытта тиләвәт сәҗдәсе  дә кылынмас. Бу кәраһәт вакытларында кылынган намазлар һәм тиләвәт сәҗдәләре яңадан кылыныр. Бу өч вакытта нәфел намазлар да укылмас, ләкин укылган булса яңадан укырга кирәкми. Бу вакытларда фәкать Коръән укырга, зикер итәргә генә мөмкин. Иртәнге намаз вакыты башланып, кояш чыкканга кадәр һәм икенде намазыннан соң кояш батканчы нәфел намазы уку мәкруһ санала.

## НИЯТ

Намаз шартларының алтынчысы – ният, ягъни Аллаһ ризалыгы өчен намаз укыячагыңны һәм нинди намаз укыячагыңны күңелдән белү. Ният күңел белән булыр. Тел белән әйтеп тә, күңелдән ниятең булмаса, намаз дөрес булмас. Имам Раббани хәзрәтләренең “Мәктүбәт шәриф” (“Изге хатлар”), 1 нче том, 186 нчы хатында: “Бары тик тел белән генә ниятләү җитәрлек булса, күп кенә бәндәләр тел белән ният итеп, күңелләре белән ният итүне читтә калдыралар. Шунлыктан намаз фарызларыннан саналган күңелдән ният итү таләбе юкка чыга. Димәк ки, намаз кабул булмый”, - диелә. Шуңа күрә ният тел белән түгел, күңел белән башкарылырга тиеш.  Фарыз намазларда, бәйрәм һәм витыр намазларында ниятне белдерергә кирәк. Мәсәлән: “Бүгенге иртәнге намазга, җомга, витыр яки бәйрәм намазларына”, дип ният итү. Нәфел намазларында: “Намазны үтәргә ният иттем ”, - дип әйтү дә җитә.

## АЗАН ҺӘМ КАМӘТ

Намаз өчен азан әйтү ваҗиб дәрәҗәсендә сөннәти-мөәккәдә булып санала. Намаз вакытының башлануы азан әйтү белән белдерелә. Тәүлегенә биш вакыт намаз укылып, биш тапкыр азан әйтелә. Азан түбәндәге сүзләрдән тора:

Әллааһү әкбәр. Әллааһү әкбәр.
Әллааһү әкбәр. Әллааһү әкбәр.
Әшһәдүән ләә иләәһә илләллааһ.
Әшһәдүән ләә иләәһә илләллааһ.
Әшһәдү әннә Мүхәммәдәр-расүүлүллааһ.
Әшһәдү әннә Мүхәммәдәр-расүүлүллааһ.
Хәййә галәс-саләәһ. Хәййә галәс-саләәһ.
Хәййә галәл-фәләәх. Хәййә галәл-фәләәх.
Әллааһү әкбәр. Әллааһү әкбәр.
Ләә иләәһә илләллааһ.

Азан сүзләре шулардан гыйбрәт. Тик иртәнге намазның азанында, “Хәййә галәл-фәләәх” сүзләреннән соң ике тапкыр “ассаләәтү хайрум-минән-нәүүм” дип кабатланыр.

Камәт тә азан кебек. Тик камәттә “хәййә галәл-фәләх” сүзеннән соң 2 тапкыр “кад кааматис-саләәһ” диелә. Өйдә дә, кырда да азан белән камәт уку фазыйләтле. Вакыт кермичә азан укылмый. Азан вакытның түгел, намазның сөннәте. Шуның өчен каза намазларга да азан һәм камәт уку сөннәт. Надан һәм бозык кешеләрнең азан укулары мәкруһ. Яхшы-яманны, ялгыш-дөресне аера белгән сабыйның азан укуы - рөхсәт ителә. Хатыннар азан һәм камәт укымаслар. Азан һәм камәттә сүзләрнең соңгы хәрефләре җәзем (сүкүн) белән укылыр. Азан укылганда тәкбирләр һәм шәһадәтләр кабатланып, хөрмәт белән тыңлана, ахырында шундый дога укылыр:

Әллааһүммә раббә һәәзиһид-дәгвәтит-тәәммәһ. Вәс-саләәтил-кааимәһ. Әәти Мүхаммәдәнил-вәсииләтә вәл-фазыыйләһ. Вәбгасһү мәкаамәм-мәхмүүдән-илләзии вәгәддәһ. Иннәкә ләә түхлифүл-миигаад.

Мәгнәсе**:** “Аллаһым! Әй бу чакыруның, ягъни мөбарәк азанның һәм кылынуда булган намазның мөкаддәс Раббысы! Пәйгамбәребез хәзрәти Мөхәммәд галәйһис-сәләмгә дуслыгыңны һәм бөек дәрәҗәне бүләк ит һәм аны Син Үзең вәгъдә иткән “мәками-мәхмүдкә” ирештер! Һичшиксез, Син Үз вәгъдәңнән кире кайтмассың!”

## НАМАЗНЫҢ ӘРКӘННӘРЕ

Намазның әркәннәре алты:

1 – Ифтитәх тәкбире;

2 – Кыям;

3 – Кыйраәт;

4 – Рөкугъ;

5 – Сәҗдә;

6 – Кәгъдәи-әхыра.

### ИФТИТӘХ ТӘКБИРЕ

Намаз әркәннәренең беренчесе – ифтитәх тәкбире, (ягъни намазны “Әллааһү әкбәр” сүзе белән башлау). Тәкбир әйтүдә беренче иҗекне “әәәл” дип сузып әйтү дөрес түгел. Шул рәвешчә әйткән кеше намазга кермәгән була. Намаз эчендә шулай сузылса, намазы бозылыр.

### КЫЯМ

Намаз әркәннәренең икенчесе – кыям, ягъни басып тору. Кыям фарыз һәм ваҗиб намазларының шарты. Басып тора алганнарга утырып укырга ярамый. Иртәнге намазның сөннәтеннән тыш сөннәт һәм мөстәхәб намазлар бер гозер булмаса да укырга ярый, ләкин өстен булганы – басып уку.

### КЫЙРАӘТ

Намаз әркәннәренең өченчесе – кыйраәт, ягъни намаз укучының үзе ишетерлек тавыш белән Коръән Кәрим аятьләрен бераз укудан тора.

Витыр белән нәфелләрнең һәм ике рәкәгатьле намазларның һәр рәкәгатендә, дүрт рәкәгатьле фарыз намазларның баштагы ике рәкәгатендә кыйраәт уку фарыз. Соңгы ике рәкәгатендә кыйраәт уку сөннәт. Фарыз булган кыйраәтнең күләме өч кыска аять, яки шул өчесе кадәр булган бер озын аять.

## НАМАЗДА УКЫЛА ТОРГАН КАЙБЕР СҮРӘ ҺӘМ АЯТЬЛӘР

### ФАТИХАИ-ШӘРИФӘ (ӘЛХӘМ)

Әгүүзү билләәһи минәш-шәйтаанир-ражиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдү лилләәһи раббил-гааләмиин. Әр-рахмәәнир-рахиим. Мәәлики йәүмид-диин. Иййәәкә нәгбүдү үә иййәәкә нәстәгыйн. Иһдинәс-сыйраатал-мүстәкыыйм. Сыйраатал-ләзиинә әнгамтә галәйһим, гайрил-мәгдууби галәйһим үә ләд-дааалллиин. Әәмиин.

Мәгънәсе**:** Рахмән һәм Рәхим булган Аллаһ исеме белән. Мактау һәм дан галәмнәр Раббысы, Рахман, Рәхим һәм Кыямәт көненең Хуҗасы булган Аллаһыга хас. Тик Сиңа гына гыйбәдәт кылабыз, тик Синнән генә ярдәм көтәбез. Безне туры юлга, Үзең нигъмәтләндергән бәндәләреңнең юлына күндер, газапка лаеклы булганнар һәм адашканнарның юлыннан тыш”.

### АЯТЕЛ-КӨРСИ

Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әллааһү ләә иләәһә илләәһүвәл-хаййүл-каййүүм. Ләә тәәхузүһүү синәтү-үә ләә нәүүм. Ләһүү мәә фис-сәмәәүәәти үә мәә фил-әрд, мәң зәлләзии йәшфәгу гыйндәһүү илләә би-изниһ. Йәгләмү мәә бәйнә әйдииһим үә мәә халфәһүм, үә ләә йүхыйтуунә бишәй им-мин гыйльмиһии илләә бимәә шәә, үәсига күрсийүһүс-сәмәәвәәти үәл-әрд. үә ләә йәүүдүһүү хыфзуһүмәә үә һүвәл-галийүл-газыыйм.

Мәгънәсе**:** Гыйбадәт кылырга яраклы һич бер зат юк, мәгәр Аллаһ үзе генә, Ул һәрвакыт тере, бөтен нәрсәгә хуҗа булганы хәлдә һәрвакыт бар. Аны ару-талу һәм йокы тотмас, җирдә һәм күкләрдә булган нәрсәләр аныкы. Ахирәттә Аллаһ хозурында кем кемгә шәфәгать кылыр? Юк, шәфәгать кылучы булмас, һичкем үз теләге белән һичкемгә шәфәгать кыла алмас, мәгәр Аллаһ рөхсәте белән генә шәфәгать кылучы булыр. Аллаһ кешеләрнең үткәндәге барча эшләрен һәм алдагы барча эшләрен белер, кешеләр Аллаһ белеменнән һичнәрсәне чолгап ала алмаслар, мәгәр Аллаһ белдергәнне генә белерләр. Аллаһының бушлык урыны җирне һәм күкләрне сыйдырды, Аллаһыга җирне һәм күкләрне саклау авыр түгел, ул Аллаһ дәрәҗәдә бик бөек һәм бик олуг.

### “ФИЛ” СҮРӘСЕ

Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әләм тәра кәйфә фәгалә раббүкә биәсхәәбил-фиил. Әләм йәҗгал кәйдәһүм фии тәдлиил. Үә әрсәлә галәйһим тайран әбәәбиил. Тәрмииһим би хиҗәәратим-мин сиҗҗиил. Фәҗәгаләһүм кәгасфим-мәәкүүл.

Мәгънәсе**:** Күрдеңме, Аллаһ фил хуҗаларын нишләтте? Корган тозакларын юкка чыгармадымы? Аларның өстенә көтү-көтү кошлар җибәрде.

Ул кошлар алар өстенә кыздырылган кирпечтән ясалган ташлар яудырдылар. Шул заман Аллаһ аларны урылган иген кыры кебек итте".

**"КОРӘЕШ" СҮРӘСЕ**

Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Ли ииләәфи кураииш. Ииләәфиһим рихләтәш-шитәәәи үәс-саииф. Фәл-йәгбүдүү раббә һәәзәл-бәиит. Әлләзии әтгамәһүм мин җүүгыйү–үә әәмәнәһүм мин хавуф.

Мәгънәсе**:** Корәеш кабиләсенең өлфәтләнүенә гаҗәпләнегез. Аларның җәй һәм кыш көннәрендә сәүдә белән сәфәрдә йөрүләрендә өлфәтләнүләренә гаҗәпләнегез! Алар иман китереп ошбу Кәгъбәнең Раббысы булган Аллаһыга гыйбадәт кылсыннар һәм Аның биргән нигмәтләренә шөкер итсеннәр. Ул – Аллаһ аларны ачлыктан коткарып тук кылды, һәм аларны һәртөрле куркынычлардан имин кылды.

**"МӘГУН" СҮРӘСЕ**

Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әраәйтәлләзии йүкәззибү бид-диин. Фәзәәликәл-ләзии йәдүггул йәтиим. Үә ләә йәхудду галәә тәгаамил-мискиин. Фәвәйлүллил-мүсаллиин. Әлләзиинә һүм ган саләәтиһим сәәһүүн. Әлләзиинә һүм юраауүн. Үә йәмнәгуунәл-мәәгуун.

Мәгънәсе**:** Әйә син хисап вә җәза көнен, Кыямәтне ялганга тоткан кешене күрдеңме? Ул ялганчы ятимне кагар, аңа золым итәр. Үзен һәм башкаларны кызыктырмас фәкыйрьләргә аш вә садака бирергә. и үкенеч вә һәлакәтлек ихлассыз намаз укучыларга. Алар намазларыннан гафилләр, вакытында укымаслар һәм намазның әркәннәрен хөрмәт кылмаслар, намазларының вакытыннан кичегүенә кайгырмаслар. Әле алар укыган намазларын да рия белән укырлар. Ул риячы тиешле садакаларны бирмәс һәм тормыш әйберләрен вакытлыча биреп тормас.

**"КӘҮСӘР" СҮРӘСЕ**

Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Иннәә әгтайнәәкәл-кәүсәр. Фәсалли лираббикә үәнхәр. Иннә шәәни-әкә һүвәл-әбтәр.

Мәгънәсе**:** **Ә**й Мөхәммәд, тәхкыйк, Без сиңа күп хәерле нәрсәләр бирдек. Раббың ризалыгы өчен намаз укы һәм ятимнәрне вә фәкыйрьләрне ашатыр өчен корбан чал! Тәхкыйк, сине әбетәр дип кимсетүче дошманың үзе әбетәр – нәселе бетүче.

**"КӘФИРУН" СҮРӘСЕ**

Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Куль йәә әййүһәл-кәәфируун. Ләә әгбүдү мәә тәгбүдүүн. Үә ләә әнтүм гаабидүүнә мәә әгбүд. Үә ләә әнә гаабидүм-мәә габәттүм. Үә ләә әнтүм гаабидүүнә мәә әгбүд. Ләкүм диинүкүм үә лиә диин.

Мәгънәсе**:** Әй Мөхәммәд әйт: "Әй сез кәферләр, иман китермәгән кешеләр! Сез гыйбадәт кыла торган сынымнарга мин гыйбадәт кылмыймын. Һәм сез дә мин гыйбадәт кыла торган Аллаһыга гыйбадәт кылмыйсыз. Вә мин сезнең гыйбадәт кыла торган сынымнарыгызга гыйбадәт кылучы түгелмен. Вә

сез мин гыйбадәт кыла торган Аллаһыга гыйбадәт кылучы түгелсез. Сезнең батыл ялган динегез үзегезгә булсын, вә минем хак динем үзебезгә булсын!

**“НӘСЫР” СҮРӘСЕ**

Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Изәә җәә ә нәсруллааһи үәл-фәтх. Үә раәйтән-нәәсә йәдхулүүнә фии диинилләәһи әфүәәҗәә. Фәсәббих бихәмди раббикә үәстәгфирһ. Иннәһүү кәәнә тәүүәәбәә.

Мәгънәсе**:** Әгәр Ислам диненә вә мөселманнарга Аллаһыдан ярдәм килсә вә шәһәрләр хосусан Мәккә шәһәре кебек мөселманнар кулына үтсә, шул вакытта күрерсең кешеләрне, төркем-төркем булып Аллаһ дине Исламга кererләр. Раббың булган Аллаһыны һәр кимчелектән пакь дип белеп һәм мактап тәсбих әйт, намаз укы һәм Аңардан ярлыкауны телә, сора! Дөреслектә Ул тәүбәне кабул итеп гөнаһларны гафу кылучыдыр.

**“ЛӘҺӘБ” (ТӘББӘТ) СҮРӘСЕ**

Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Тәббәт йәдәә әбии ләһәбиү-үәтәбб. Мәә әгнәә ганһү мәәлүһүү үә мәә кәсәб. Сәясләә нәәран зәәтә ләһәб. Үәмраәтүһүү хәммәәләтәл-хәтаб. Фии җиидиһәә хаблүм мим мәсәд.

Мәгънәсе**:** Әбү Ләһәбнең ике кулы корысын һәм һәлак булсын! Аңа газаптан котылырга малы һәм кәсеп иткән нәрсәләре һич файда бирмәде. Тиздән ул Әбү Ләһәб ялкынлы утка кереп янар. Дәхи хатыны да утка керер утын күтәргән хәлдә. Ул хатынның муенында хөрмә мунчаласыннан булган бау бар.

**“ИХЛАС”СҮРӘСЕ**

Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Куль һүә-ллааһү әхәд. Әллааһүс-самәд. Ләм йәлид үә ләм йүүләд. Үә ләм йәкүлләһүү күфүән әхәд.

Мәгънәсе**:** Әйт, әй Мөхәммәд: "Ул – Аллаһ һич, тиңдәше вә охшашы булмаган ялгыз бер генә Аллаһ. Һичнәрсәгә, һичбер мәхлукка ихтыяҗы юк, бәлки һәр мәхлукның хаҗәтен үтәүче Аллаһ. Ул һичкемне тудырмады һәм һичкемнән тудырылмады. Вә һичкем Аңа тиң булмады.

**“ФӘЛӘКЪ” СҮРӘСЕ**

Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Куль әгуузү бираббиль-фәләкъ. Мин шәрри мәә халәк. Үә мин шәрри гаасикыйн изәә үәкаб. Үә мин шәррин-нәффәәсәәти филь-гукад. Үә мин шәрри хаасидин изәә хасәд.

Мәгънәсе**:** Әйт, әй Мухәммәд, "Мин сыенамын таңның Раббысы Аллаһы Тәгаләгә күренеп вә күренмичә килә торган һәртөрле зарарлардан. Бар кылынган, яратылган һәр мәхлукның нинди булса да зарарыннан. Вә караңгы төннең зарарыннан сыгынамын, һәркайчан караңгылыгы белән җир өстен капласа. Дәхи сихер–ырым төеннәренә төкерүче өрүче сихерче хатыннар явызлыгыннан, зарарыннан сыгынамын. Һәм көнче дошманның авызлыкларыннан, зарарларыннан сыенамын, һәркайчан ул көнчелек ачуы белән зарар тидерергә теләсә.

**“НӘС” СҮРӘСЕ**

Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Куль әгуузү бираббин-нәәс. Мәликин-нәәс. Иләәһин-нәәс. Мин шәрриль-үәсүәәсил ханнәәс. Әлләзии йүәсүисү фии судүүрин-нәәс. Минәл җиннәти үән-нәәс.

Мәгънәсе: Әйт: "Кешеләрнең Раббысы булган Аллаһыга сыгынамын. Кешеләрнең патшасы булган Аллаһыга сыгынамын. Кешеләрнең гыйбадәт кыла торган Илаһы булган Аллаһыга сыгынамын. Чигенә-чигенә саваплы эштән тыеп, гөнаһлы эшкә өндәп вәсвәсә кылучы ханнәснең зарарыннан. Ул ханнәс кешеләрнең күңеленә явызлыкны сала. Ул ханнәс җеннәрдән дә һәм кешеләрдән дә бар.

## НАМАЗДА УКЫЛА ТОРГАН КАЙБЕР ДОГАЛАР

### ТӘКБИР ҺӘМ "СҮБХӘНӘКӘ"

Әллааһү әкбәр. Сүбхәнәкә-ллааһүммә үә бихәмдик. Үә тәбәәракә-смүк. Үә тәгааләә җәддүк. (Үә җәллә сәнәәүк). Үә ләә иләәһә гайрук. "Вә җәллә сәнәәүк" сүзе җеназа намазында гына укылыр.

Мәгънәсе: "Аллаһым, Сиңа дан һәм Сиңа мактау. Синең исемең мөбарәк. Синең олылыгың югары. Һәм Синнән башка һичбер илаһ юк".

### "ӘТТӘХИЯТ"

Әттәхийәәтү лилләһи үәс-саләүәәтү үәт-таййибәәт. Әссәләәмү галәйкә әййүһән-нәбиййү үә рахмәтүллааһи үә бәракәәтүһ. Әссәләәмү галәйнәә үә галәә гыйбәәди-лләһис-саалихыыйн. Әшһәдүән ләә иләәһә илләллааһү үә әшһәдү әннә мүхәммәдән габдүһүү үә расүүлүһ.

Мәгънәсе: Һәртөрле тел, тән һәм мал белән кылган гыйбадәтләр Аллаһыга хас. Әй даны югары булган Пәйгамбәр! Сәлам һәм Аллаһының рәхмәте һәм бәракәте сиңа булсын! Һәм сәлам барыбызга да һәм Аллаһының изге колларына булсын. Мин шәһадәт кыламын ки, Аллаһыдан башка илаһ юк! Һәм шәһадәт кыламын ки, хәзрәти Мөхәммәд Аллаһының колы һәм илчесе".

### САЛАВАТ-ШӘРИФЛӘР

Әллааһүммә салли галәә Мүхәммәдин үә галәә әәли Мүхаммәд. Кәмәә салләйтә галәә Ибрааһиимә үә галәә әәли Ибрааһиимә иннәкә хәмиидүм-мәҗиид. Әллааһүммә бәәрик галәә Мүхәммәдин үә галәә әәли Мүхаммәд. Кәмәә бәәрактә галәә Ибрааһиимә үә галәә әәли Ибрааһиимә иннәкә хәмиидүм-мәҗиид.

Мәгънәсе: Аллаһым! Мөхәммәд галәйһис-сәламгә һәм аның гаиләсенә, Ибраһим галәйһис-сәламгә һәм аның гаиләсенә рәхмәт иткәнең кебек рәхмәт әйлә. Тәхкыйк, син мактаулы һәм олы. Аллаһым! Мөхәммәд галәйһис-сәламгә һәм аның гаиләсенә, Ибраһим галәйһис-сәламгә һәм аның гаиләсенә бәракәт иткәнең кебек бәрәкәт әйлә. Һичшиксез, Син мактаулы һәм олы.

### САЛАВАТ ШӘРИФӘДӘН СОҢ УКЫЛАЧАК ДОГА

Раббәнәә әәтинәә фид-дүнийә хәсәнәтән үә фил-әәхирати хәсәнәтән үә кыйнәә газәәбән-нәәр. Раббәнә-гъфир лии үәли үәәлидәййә үә лил-мүэмининә йәүмә йәкуумүл-хисәәб.

Мәгънәсе**:** Әй Раббыбыз! Безгә дөньяда һәм ахирәттә яхшылыкны бир, һәм безне ут (җәһәннәм) газабыннан сакла! Әй, Раббыбыз! Һәркем хисап бирәчәк ул көндә мине, әти-әниемне һәм барча мөэминнәрне гафу ит! "Раббәнә-этинә"дән соң, сәламнән элек укыла торган дога:

Әллааһүммә инниı әгуузү бикә мин газәәби җәһәннәм, үә әгуузү бикә мин газәәбил-кабри, үә әгуузү бикә мин фитнәтил-мәсиихид-дәҗҗәәл үә әгуузү бикә мин фитнәтил-мәхйәә үәл-мәмәәт.

Мәгънәсе**:** Аллаһым, җәһәннәм газабыннан, кабер газабыннан, дәҗҗәлнең фетнәсеннән, тормышта вакыттагы һәм үлем вакытындагы фетнәләрдән Сиңа сыгынамын!

Габдулла бине Габбас (разыйаллаһү ганһ) Пәйгамбәр әфәндебезнең Коръән Кәримнән бер сүрәне өйрәткәне кебек, бу доганы да өйрәткәнен риваять итә. Моннан башка да Рәсүлулла әфәндебезнең укуы турында риваять ителгән башка догалар да бар.

## КӨНҮТ ДОГАСЫ

Әллааһүммә иннәә нәстәгыыйнүкә үә нәстәгъфирукә үә нәстәһдиик. Үә нүэминү бикә үә нәтүүбү иләйкә үә нәтәүәккәлү галәйкә үә нүснии галәйкәл-хайра күлләһүү нәшкүрукә үә ләә нәкфүрук. Үә нәхләгу үә нәтрукү мәй-йәфҗүрук. Әллааһүммә ийййәәкә нәгбүдү үә ләкә нүсаллии үә нәсҗүдү үә иләйкә нәсгаа үә нәхфид. Нәрҗүү рахмәтәкә үә нәхшәә газәәбәкә иннә газәәбәкә бил-күффәәри мүлхыйк.

Мәгънәсе**:** Аллаһым, Синнән ярдәм, гафу итүеңне, тугры юл күрсәтүеңне телибез. Сиңа иман китерәбез, Сиңа тәүбә итәбез. Эшләребездә Сиңа таянабыз, Сине бөтен изгелекләр белән олуглап биргән нигмәтләреңә шөкер итәбез. Сине беркайчан да инкарь итмибез. Сиңа каршы торучылардан ерак торырбыз, алардан аерылырбыз. Аллаһым! Бары тик Сиңа гына гыйбадәт кылабыз һәм коллык итәбез. Синең өчен генә намаз укыйбыз һәм сәҗдә кылабыз. Сиңа гына кол булыр өчен эшләрбез һәм йөгерербез. Рәхмәтеңне өмет итәбез, газабыңнан куркабыз. Һичшиксез синең газабың кяферләргә төшәр".

## РӨКУГ

Намаз әркәннәренең дүртенчесе – рөкуг. Рөкуг – кыямда кыйраәтне тәмамлагач, башны һәм арканы тигез тоту (иелү). Рөкугны кылганда хатын-кызлар, бармакларын ябып, тез капкачы өстенә куялар. Ирләр, кул бармакларын ачып, тез капкачларын тоталар. Утырып намаз укыганнар рөкуг өчен башларын тезләре турысына кадәр бөгәргә тиешләр.

## СӘҖДӘ

Намаз әркәннәренең бишенчесе – сәҗдә. Сәҗдә рөкугдан соң маңгайны, борынны, аякларның бармак очларын һәм ике кул белән ике тезне, ягъни барлыгы җиде әгъзаны җиргә кую. Сәҗдәдә күзләр борынның ике ягына карый.

Куллар битнең ике ягында булып, бармаклар ябык булган хәлдә кыйбла тарафына юнәлә.

## КӘГЪДӘИ-АХИРӘ

**(**соңгы утырыш**)**

Намаз әркәннәренең алтынчысы кәгъдәи-ахирә. Кәгъдәи-ахирә — ул намазның соңгы утырышында “Әттәхият” укырлык кадәр утырып тору. Соңгы утырышта ирләр уң аякларының бармакларын кыйблага каратып, сул аягын яткызып сул аягы өстенә утырыр. Хатын-кызлар исә, ике аякларын да уңга чыгарып җибәргән хәлдә утырырлар. Аларның бу утыруы “тәвәррук” дип атала. Кәгъдәдә куллар тезләрнең өстендә, кыйблага карап иркен яталар.

## НАМАЗНЫҢ ВАҖИБЛАРЫ

1. Намазны “Әллааһү әкбәр” дип башлау.
2. “Фатихаи-шәрифә”не уку.
3. “Фатиха”дан соң бер сүрә яисә кыска бер сүрәгә тиң аять уку.
4. Кыйраәтне беренче һәм икенче рәкәгатьтә үтәү.
5. Ике сәҗдәне бер-бер артлы кылу.
6. Тәгдили-әркәнне үтәү, ягъни рөкуг һәм сәҗдәдән соң һәм башка әркәннәр арасында әгъзаларның үз урыннарында тынычлануын көтү.
7. Утырышларда “Әттәхият”не уку.
8. Намаз соңында сәлам бирү.
9. Өйлә һәм икенде намазларының фарызларында “Фатиха”ны һәм сүрәләрне тавышсыз уку.
10. Имам булган кешенең иртәнге, ахшам һәм ястүнең фарызларында, җомга һәм бәйрәм намазларында “Фатиха”ны һәм сүрәләрне кычкырып уку.
11. Өч һәм дүрт рәкәгатьле намазларда икенче рәкәгатьтән соң утыру.
12. “Фатиха”ны сүрәдән яисә аятьтән алда уку.
13. Намазда хаталанып ваҗибны калдыру сәбәпле сәһү сәҗдәсе кылу.
14. Витыр намазында көнүт догасын уку.
15. Сәҗдәдә маңгай белән бергә борынны да җиргә тидерү.

## НАМАЗНЫҢ СӨННӘТЛӘРЕ

1. Азан уку.
2. Намазны башлаганда, беренче тәкбирдә ирләрнең кулларын колак турысына, хатын-кызларның җилкә турысына күтәрүе.
3. Тәкбирдән соң кулларны бәйләү. Ирләр уң кулының баш һәм чәнти бармаклар белән сул кулның беләзегенә боҗра ясап, кендек астына куялар. Хатын-кызлар исә күкрәк өстендә, уң кулны сул кул өстенә куялар.
4. “Сөбханәкә”не уку.
5. Әгузү һәм бисмилләһ әйтү.
6. Һәр рәкәгатьтә “Фатиха”дан әүвәл бисмилләһ әйтү.
7. “Фатиха”дан соң тавышсыз “әмин” дию.
8. Рөкугка һәм сәҗдәгә барганда, торганда тәкбир әйтү.
9. Рөкугта өч тапкыр “сүбхәнә раббиәл-газыйм” дип әйтү.

10. Рөкугта ирләрнең бармакларын ачык хәлдә тезләре өстенә куеп, башлары белән аркаларын бер турылыкта тотулары. (Хатыннар башлары белән аркаларын туры тотмаслар) Хатыннар бармакларын бер-берсеннән аермыйча кулларын тез өстенә куеп торырлар.

11. Имамның рөкугтан торганда “Сәмига-ллааһү лимән хәмидәһ” дип әйтүе.

12. Җәмәгатьнең рөкугтан торганда “Раббәнәә ләкәл-хәмд” дип әйтүе.

13. Ялгыз намаз укучыларның шул ике сүзне дә әйтүләре.

14. Сәҗдәдә өч тапкыр “сүбхәнә раббиәл-әгъләә” дип әйтү.

15. Сәҗдәдә кулның бармакларын бер-берсенә тоташтырып тоту.

16. Ирләрнең сәҗдәдә ботларын корсакларыннан ераграк тотып, кул терсәкләрен җирдән күтәрүләре.

17. Хатын-кызларның сәҗдәдә корсакларын ботларына ябыштырып, кулларын ботлары яннарына кысулары.

18. Утырышта (кәгъдәдә) кулларны тезләр өстенә куеп, бармакларны иркен хәлдә тоту.

19. Ирләр утырышта сул аякка утырып, уң аякны бастырып бармакларын кыйблага каратып тоталар.

20. Хатын-кызлар утырышта ике аякны да уң яккарак җибәреп утыралар.

21. Сәламне уң яктан башлау.

22. Соңгы утырышта Пәйгамбәр әфәндебезгә салават уку.

**НАМАЗНЫҢ МӨСТӘХӘБЛӘРЕ**

1. Мөәззин камәт төшергәндә “Хәййә галәс-саләһ” дигәч, соңга калдырмыйча басу.

2. Ифтитәх тәкбирендә баш бармакларны колак йомшагына тидерү.

3. Кыямда сәҗдә урынына карау.

4. Рөкугта аяк очларына карау.

5. Рөкуг һәм сәҗдә тәсбихләрен биш яисә җиде тапкыр уку.

6. Сәҗдәгә барганда маңгайдан әүвәл борынны җиргә кую.

7. Сәҗдәдә борынның ике ягына карау.

8. Сәлам биргәндә кул башына карау.

9. Тыелып булмаслык хәлдә иснисе килсә, уң кулның тышкы ягы белән авызны каплау.

10. Мөмкин кадәр яхшы һәм пакь кием белән намаз уку.

11. Уң якка сәлам биргәндә “уң яктагы җәмәгатькә һәм фәрештәләргә” дип ният итү.

12. Сул якка сәлам биргәндә “сул яктагы җәмәгатькә һәм фәрештәләргә” дип ният итү.

13. Ялгыз укучы сәлам биргәндә кирамән-кәтибин һәм хафаза фәрештәләренә сәлам бирергә ният итү.

14. Мөмкин булган кадәр ютәлне басу.

## НАМАЗНЫҢ МӘКРУҺЛАРЫ

1. Намаз эчендә як-якка карау.

2. Кием яисә тән белән уйнау. Тәнгә ябышкан киемне җиңелчә кузгалтуда бер нинди гөнаһ юк.

3. Сәбәпсез бармак шартлату.

4. Сәҗдә урынындагы ташларны чистарту.

5. Бөергә таяну.

6. Бер урынны бер яки ике тапкыр кашу.

7. Сәбәпсез аякларны баглап утыру.

8. Кеше йөзенә карап намаз уку.

9. Утлы күмергә каршы намаз уку.

10. Намаз укучының алдында, өстендә, ян-якларында, артында яисә киемендә сурәт булу.

11. Киерелү (сузылу).

12. Иснәү.

13. Утырышта ике аягының тубыкларына утыру.

14. Аякларын алга алып тезләрен күкрәгенә кочаклап яки кулларын җиргә куеп утыру.

15. Яңа һәм матур киеме була торып, иске яки начар кием белән намаз уку.

16. Яланбаш намаз уку.

17. Сәҗдәдә һәм башка урыннарда кул һәм аяк бармакларын кыйбладан башка якка карату.

18. Җәмәгать намазында алгы рәттә урын була торып, артка басу.

19. Кабергә карап намаз уку.

20. Капланмаган нәҗескә карап намаз уку.

21. Хатын-кыз белән пәрдәсез бер рәттә торып, аерым-аерым намаз уку.

22. Кысталган хәлдә намаз уку.

23. Сәҗдәдән торганда тезләрне куллардан элек күтәрү.

24. Сәҗдәдә сыңар аякны күтәрү.

25. Имамнан алда рөкугка китү.

26. Имамнан әүвәл рөкугтан тору.

27. Имамнан алда сәҗдәгә бару.

28. Имамнан әүвәл сәҗдәдән тору.

29.Сәҗдәгә киткәндә (гозерсез рәвештә) кулларны тезләрдән әүвәл җиргә кую.

30. Җиргә яисә диварга гозерсез таянып тору.

31. Намазда маңгайдагы туфракны сөртү.

32. Беренче рәкәгатьтә укыган сүрә белән икенче рәкәгатьтәге сүрә арасында бер сүрә генә калдыру.

33. Икенче рәкәгатьтә беренче рәкәгатьтә укылган өстәмә сүрәнең (Коръәндәге тәртибе буенча) алдынан сүрә яисә аятьне өстәмә сүрә итеп уку.

34. Фарыз намазында беренче рәкәгатьтә укылган бер сүрәне икенче рәкәгатьтә кабатлау яисә бер сүрәне бер рәкәгатьтә ике тапкыр уку.

35. Фарыз намазның икенче рәкәгатендә, беренче рәкәгатькә караганда өч яисә күбрәк аять арттырып уку.

36. Имамга ияручененң Коръән укыганда имамга кушулуы.

37. Сәҗдә кылганда гозерсез башындагы чалма өстенә сәҗдә кылу.

38. Кыямда булганда гозерсез диварга таяну.

39. Кыямда торганда уңга яки сулга янтаеп тору, кыйшаю.

40. Гозерсез (сәбәпсез) сыңар аякта тору.

41. Намаз эчендә аять һәм тәсбихләрне бармак белән санау.

42. Җәмәгать намазы укылганда ялгыз намаз укый башлау.

43.Имамның михрабтан башка җирдә торуы.

44. Имамның җәмәгатьтән бер зирәдән (50 сантиметрдан) түбән торуы.

45. Имамның җәмәгатьтән бер зирәдән (50 сантиметрдан) биегрәк җирдә торуы (ләкин, әгәр имам белән тагын бер кеше торса, бу тыелмый).

46. “Бисмилләһ” һәм “әмин”не кычкырып әйтү.

47. Кыйраәтне рөкугка барганда тәмамлау.

48. Тәкбирләрне үз урыннарында әйтмәү, тәсбих һәм кыйраәтләрне урынсыз (үзләре билгеләнмәгән урында) уку.

49. Рөкуг һәм сәҗдә тәсбихләрен башны күтәргәч әйтү.

50. Иңнәр ачык һәм кулларны сызганган килеш намаз уку.

51. Намаз укыган урында алдыңнан берәр җан иясе үтеп йөрү ихтималы булганда, алга бер пәрдә кормыйча намаз уку.

52. Нәрсәне булса да иснәү.

53. Ишетелмәслек булса да өрү (әгәр инде ишетелсә, намаз бөтенләй бозыла).

54. Башка нәрсә булса да урап, баш түбәсен ачык калдыру.

55. Авызны һәм борынны каплап намаз уку.

56. Әгәр икенче җәмәгать җыелса, икенче җәмәгатькә имам булучының беренче имам басып укыган җирдә басып укуы.

**НАМАЗНЫ БӨТЕНЛӘЙ БОЗА ТОРГАН НӘРСӘЛӘР**

1. Сөйләшү, сөйләнү һәм үзеңә ишетерлек итеп көлү. (Яныңдагы кеше ишетерлек итеп көлсә, намазы да, тәһарәте дә бозылыр).

2. “Ах, их, эх” кебек ымлыклар әйтү.

3. Елау (әмма ул елау, Аллаһыдан курку белән бәйле булса, намаз бозылмас).

4. Гозерсез тамак кыру, какыру, ютәлләү.

5. Сагыз чәйнәү.

6. Бер әркәндә өч тапкыр һәм артык чәч йолку.

7. Бер әркәндә өч тапкыр һәм артыграк бер урынны кашу.

8. Бер рәкәгатьтә ике адым һәм күбрәк хәрәкәтләнү.

9. Чәч һәм сакалны тарау.

10. Хатын-кыз белән арада бер кеше сыярлык урын калдырмыйча рәттән торып, бер үк намазны бер имамга ияреп намаз уку.

11. Гәүдәне сәбәпсез кыйбладан читкә юнәлтү.

12. Намаз эчендә имамнан башка укучыларның намаз ялгышларын әйтү.

13. Коръәнне мәгънәсе бозылырлык дәрәҗәдә ялгыш уку.

14. Сәлам биреп, сәлам кайтару (намаз бетте дип уйлап, ялгышып сәлам бирсә, намаз бозылмый, тик сәһү сәҗдәсен кылырга кирәк булыр).

15. Гаурәтнең дүрттән бер өлеше өч тәсбих әйтерлек кадәр ачык калуы, әгәр белеп ачса, шунда ук намаз бозылыр.

16. Сәҗдәдә чакта ике аяк белән тибенү (әгәр бер аяк белән өч тапкыр тибелсә дә, намаз бозылыр).

17. Сәҗдәдә ике аякны бергә җирдән аеру.

**НАМАЗ НИЧЕК УКЫЛА?**

Намаз укый торган кеше иң беренче үзенең тәнендә, киемендә һәм дә намаз укыйсы урынында нәҗеснең (пычракның) булмавына игътибар итәргә тиеш. Шуннан соң, намаз укыр өчен тәһарәт алына.Тәһарәтләнгәч, намаз уку теләге белән кыйблага таба юнәлә. Күңелен дөньяви уйлардан арындыра. Аллаһының мәгънәви хозурында торуын күз алдына китерә. Укыячак намазына ният итә.

Мәсәлән, укыячак намазы иртәнге намазның сөннәте булса: “Аллаһ ризалыгы өчен бүгенге иртә намазының сөннәтен үтәргә ният иттем” дип ниятләр. Әгәр фарызын укыячак булса: “Аллаһ ризалыгы өчен бүгенге иртә намазының фарызын үтәргә ният иттем” дип ниятләр. Намаз җәмәгать белән кылынса, нияттә “тарафына” сүзеннән соң “оедым ошбу имамга” – дип ниятли. Әгәр нәфел намазын укымакчы булса, гади генә: “Аллаһ ризалыгы өчен намаз үтәргә ният иттем” дип ниятли. Ният иткәндә “иттем” сүзе урынына “кылдым”, “үтәргә” урынына “кылырга” яки “укырга” дип әйтсә дә ярый. Шуннан соң кыйблага юнәлеп, бармаклары ачык хәлдә ике кулны колак йомшагына тидерерлек күтәреп ифтитәх тәкбирен әйтер, ягъни “Әллааһү әкбәр”, дип әйтер (рәсем 13). Хатын-кызлар исә кулларын, бармак очлары иңнәре белән тигезләнгәнче күтәрәләр (рәсем 14). Шуннан соң ир-атлар уң кулның эчен сул кулның сыртына һәм чәнти бармак белән баш бармакны сул кулның беләзегенә куеп, аны боҗралап алган хәлдә бу тоташкан кулларны кендек астына төшереп тоталар (рәсем 15). Хатын-кызлар исә уң кул сул кулның өстендә булган хәлдә кулларын күкрәкләренә куялар (рәсем 16). Кул багланганнан соң “Сүбхәнәкә” укыла. Соңыннан “Әгузү-бисмилләһ” дип әйткәч, “Фатиха” укыла. Аннары “Әмин” диелә. Соңра бер сүрә яки кыска бер сүрә озынлыгында бер аять укыла. Һәм кулларны төшереп, “Әллааһү әкбәр” дип рөкугка барыла. Рөкугта ирләр

бармакларын ачып куллары белән тезләрен учлыйлар, ә тез буыннарын катырып, башны һәм арканы төп-төз тоталар. (рәсем 17). Хатын-кызлар ирләр

кадәр бөгелмәсләр (рәсем 18). Рөкугта өч тапкыр “Сүбхәнә раббийәл-газыйм” диелә. Рөкугта һәрвакыт аяк бармакларына карыйлар. Әммә баш иелми, төп-төз тотыла. Соңыннан, “Сәмига-ллаһү лимән хәмидәһ” дип тураеп басалар һәм “Раббәнә ләкәл-хәмд” диелә. Соңра “Әллааһү әкбәр” дип тагын сәҗдәгә китәләр. Сәҗдәгә төшкәндә иң элек тезләр, соңыннан куллар, аннары баш җиргә куела. (Сәҗдәдә маңгайның һәм борынның җир катылыгын тоюы шарт). Кул һәм аяк бармаклары кыйбла юнәлешенә куела. Ир-атлар терсәкләрен як-якка ачып, корсакларын ботларыннан ераграк тоталар һәм аяк бармакларын да туп-туры кыйбла юнәлешенә куялар (рәсем 19). Хатын-кызлар, киресенчә, терсәкләрен як-якка ачмыйлар һәм корсакларын да ботларыннан аермыйлар, аяк

бармакларының да кыйбла юнәлешендә торуы шарт түгел. Аякларын яткызып, җиргә куялар (рәсем 20). Сәҗдәдә өч тапкыр “Сүбхәнә раббийәл-әгъләә” диелә.

Соңыннан, “Әллааһү әкбәр” дип сәҗдәдән торалар, тезләнеп утыралар. Бер тапкыр “Сүбхәна-ллааһ” диярлек кадәр көтеп торып, “Әллааһү әкбәр” дип, икенче сәҗдәгә китәләр. Бу сәҗдәдә янә өч тапкыр “Сүбхәнә раббийәл-әгъләә” диелә. Соңыннан, “Әллааһү әкбәр” дип, икенче рәкәгатькә торалар. Әүвәлгечә кул баглану торышы кабатлана. Тик бер “Бисмилләһи-шәрифә” белән “Фәтиха” һәм бер сүрә яисә озын аять укыла. Аннары, нәкъ беренче рәкәгатьтәге шикелле, рөкуг һәм сәҗдә кабатлана. Икенче рәкәгатьнең икенче сәҗдәсеннән соң, сул аякны җиргә куеп, уң аякны тик тотып, аяк бармаклары кыйблага юнәлгән хәлдә утырыла (рәсем 21). Хатын-кыз ике аякны да уңга җибәреп, сул ботына утыра (рәсем 22). Шул хәлдә “Әттәхият”, “Әллаһүммә салли”, “Әллаһүммә бәәрик” укыла. Соңра “Раббәнәә әәтинәә...” кебек догалар укылыр. Аннары йөз белән уң тарафка борылып, “Әссәләәмү галәйкүм вә рахмәтүллааһ” диелә (рәсем 23, 24). Соңыннан йөз белән сул тарафка борылып, янә “Әссәләәмү галәйкүм вә рахмәтүллааһ” диелер. Шулай итеп намазны тәмамлыйлар (рәсем 25, 26).

Иртәнге намазның фарызы да нәкъ шулай (сөннәте шикелле) укыла. Әмма ир-атлар фарыздан әүвәл камәт укыйлар. Укылган һәр намазда сәлам бирүдән соң “Әллааһүммә әнтәс-сәләәмү үә минкәс-сәләәм. Тәбарәктә йәә зәл-җәләәли үәл-икраам” дип, шуннан соң тәсбих укыла: Сүбхәна-ллааһи үәл-хәмдү лилләәһи үә ләә иләәһә илләллааһү үәллааһү әкбәр. Үә ләә хәүлә үә ләә куввәтә илләә билләәһил-галийил-газыйм.

Мәгънәсе**:** “Аллаһыны олылап тәсбих итәмен. Мактау тик Аңа гына махсус. Аллаһыдан башка илаһ юк. Гөнаһтан тыелу һәм итәгать итүгә көч бирү бары тик бер олы, бөек Аллаһ ярдәмендә генә була ала”.

Моннан соң бер “Аятел-көрси” укылгач, 33 тапкыр “Сүбхәна-ллаһ”, 33 тапкыр **“**Әлхәмдү лилләәһ**”**, 33 тапкыр **“**Әллааһү әкбәр**”** диелер. Шуннан соң ошбу дога укыла:

Әллааһү әкбәр. Ләә иләәһә илләллааһү үәхдәһүү ләә шәриикә ләһ. Ләһүлмүлкү үә ләһүл-хәмдү йүхъйи үә йүмиит. Үә һүә хаййүл ләә йәмүүт. Бийәдиһил хайиир. Үә һүә галәә күлли шәй ин кадиир.

Мәгънәсе**:** Аллаһы Тәгаләдән башка илаһ юк. Ул бер. Аның уртагы юк. Бөтен барлык – Аныкы. Мактау Аңа махсус. Терелтүче дә, үтерүче дә - Ул. Үзе исә тере һәм үлмәс. Бөтен изгелек Аның кулында (кодрәтендә) һәм Ул һәрнәрсәне булдыра ала!” Бу догадан соң, кул күтәреп дога укыйлар (рәсем 27, 28).

Барча намазлар шул рәвешле укыла. Әммә 3 яки 4 рәкәгатьле фарызлар белән 4 рәкәгатьле сөннәти-мөәккәдәләрнең һәм витыр намазының беренче утырышында бары тик “Әттәхият” кенә укыла. “Әллаһүммә салли” һәм “Әллаһүммә бәәрик” укылмый.

Икенде намазының сөннәте һәм ястү намазының беренче дүрт рәкәгать сөннәте кебек, гайрү-мөәккәдә булган сөннәтләрдә икенче рәкәгатьтән соңгы утырышларында “Әттәхият” укылганнан соң “Әллаһүммә салли” һәм “Әллаһүммә бәәрик” тә укылыр. Өченче рәкәгатьнең башында, бүтән дүрт рәкәгатьле намазлардан аермалы буларак, “Сүбхәнәкә” укыла. Соңыннан “Әгузү-бисмилләһ”не әйтеп, “Фатиха” укыла.

Өйлә намазының сөннәтендә: “Аллаһ ризалыгы өчен бүгенге өйлә намазының сөннәтен укырга ният иттем”, - дип күңелдән ният итәләр. Фарызында исә: “Аллаһ ризалыгы өчен бүгенге өйлә намазының фарызын үтәргә ният итем”, —дип ният ителә. Соңгы сөннәтенә: “Ният иттем Аллаһ ризалыгы өчен бүгенге өйлә намазының соңгы сөннәтен үтәргә”, дип күңелдән ният итәләр.

Икенде намазының сөннәтендә: “Аллаһ ризалыгы өчен бүгенге икенде намазының сөннәтен үтәргә ният иттем ” дип, фарызында исә: “Аллаһ ризалыгы өчен бүгенге икенде намазының фарызын үтәргә ният иттем” дип күңелдән ният итәләр.

Ахшам намазының фарызында: “Аллаһ ризалыгы өчен бүгенге ахшам намазының фарызын үтәргә ният иттем”, сөннәтендә: “Аллаһ ризалыгы өчен бүгенге ахшам намазының сөннәтен үтәргә ният иттем” дип ният ителер.

Ястү намазының баштагы сөннәтенә: “Аллаһ ризалыгы өчен бүгенге ястү намазының әүвәлге сөннәтен үтәргә ният иттем” дип, фарызына: “Аллаһ ризалыгы өчен бүгенге ястү намазының фарызын үтәргә ният иттем” дип, ястүнең соңгы сөннәтенә: “Аллаһ ризалыгы өчен бүгенге ястү намазының соңгы сөннәтен үтәргә ният иттем ” дип һәм иң соңыннан укылган өч рәкәгать витыр намазына исә: “Аллаһ ризалыгы өчен бүгенге витыр намазын үтәргә ният иттем” дип күңелдән ният ителер.

## БИШ ВАКЫТ НАМАЗ

### 1. ИРТӘНГЕ НАМАЗ

Иртәнге намаз 4 рәкәгатьтән тора: шуның икесе сөннәт, икесе фарыз. Иң беренче итеп сөннәте. Соңыннан фарызы укыла. Намаз укырга теләгән кеше, тәһарәт алып, кыйблага юнәлеп, аягүрә хәлдә, иртәнге намазның сөннәтен укырга ниятләдем дигәч, "Әллааһү әкбәр" дип, тәкбир әйтә, нәкъ югарыда күрсәтелгәнчә, ике рәкәгать намаз укыла. Шул рәвешчә, иртәнге намазның сөннәте үтәлә. Бу намазның фарызы да нәкъ шул рәвешчә укыла, тик кабат: " Аллаһ ризалыгы өчен бүгенге иртә намазының фарызын үтәргә ният иттем" дип ният ителә. Нияттән элек камәт төшерелсә, бик әйбәт. Иртәнге намазның фарызында озын сүрә уку сөннәт санала. Фарызны тәмамлап сәлам биргәннән соң, югарыда күрсәтелгәнчә, тәсбих әйтеп, дога кылалар.

## 2. ӨЙЛӘ НАМАЗЫ

Өйлә намазын укырга теләгән кеше беренче өйлә намазының сөннәтен үтәргә ният итеп, нәкъ иртәнге намазның сөннәте кебек, ике рәкәгать укып, шуннан соң утырып "Әттәхият"не укый һәм сәлам бирмичә "Әллааһү әкбәр" дип өченче рәкәгатькә торып, "Фатиха" сүрәсен укый башлый. Өченче һәм дүртенче рәкәгатьләрне беренче ике рәкәгать шикелле укыганнан соң утыра һәм "Әттәхият", "Әллаһүммә салли", "әллаһүммә бәәрик", "Раббәнәә әәтинәә" догаларын укып сәлам бирә. Өйлә намазының фарызы да сөннәте кебек укыла. Тик ирләр беренче камәтне укыйлар. "Аллаһ ризалыгы өчен бүгенге өйлә намазының фарызын үтәргә ният иттем" дип ният ителә, өченче һәм дүртенче рәкәгатьләрдә бары тик "Фатиха" гына укыла. Башка бер сүрә яисә аять укылмый. Гомумән, өйләнең генә түгел, бүтән фарыз намазларның да өченче һәм дүртенче рәкәгатьләрендә бары тик "Фатиха" гына укылып, башка берни дә укылмый.

Өйләнең соңгы сөннәте дә нәкъ иртәнге намазның сөннәте шикелле укыла. Тик башлаганда: "Аллаһ ризалыгы өчен бүгенге өйлә намазының соңгы сөннәтен үтәргә ният иттем" дип ният ителә.

## 3. ИКЕНДЕ НАМАЗЫ

Икенде намазын укырга теләгәннәр беренче дүрт рәкәгать сөннәтен үтәрләр. "Аллаһ ризалыгы өчен бүгенге икенде намазының сөннәтен үтәргә ният иттем" дип ният иткәч, беренче ике рәкәгатьне иртәнге намазның ике рәкәгате кебек укып һәм утырып "Әттәхият"не укыганнан соң, "Әллаһүммә салли", "Әллаһүммә бәәрик" тә укыла. Сәлам бирмичә "Әллааһү әкбәр" дип өченче рәкәгатькә тора, "Әгузү-бисмилләһ" әйтеп, тагын ике рәкәгать укый. Икенденең фарызы өйләнең фарызы шикелле үк укылыр. Әмма ният бүтәнчәрәк: "Икенденең фарызын..." дип әйтеләчәк. Әлбәттә, фарызны башлаганчы ирләр камәт төшерә.

## 4. АХШАМ НАМАЗЫ

Ахшам намазында беренче фарыз, аннары сөннәт башкарыла. Ахшам намазын укырга теләгән кеше камәт әйтеп, "Аллаһ ризалыгы өчен бүгенге ахшам намазының фарызын үтәргә ният иттем" дип ният итә һәм өч рәкәгать

фарызын укый. Беренче һәм икенче рәкәгатьләрне иртәнге намазның фарызы шикелле укыганнан соң, утырып “Әттәхият”не укый һәм “Әллааһү әкбәр” дип өченче рәкәгатькә тора. Өченче рәкәгатьтә “Фатиха”ны гына укып, рөкуг, сәҗдә кыла, аннары “Әттәхият”, “Әллаһүммә салли”, “Әллаһүммә бәәрик”, “Раббәнәә әәтинәә” кебек салават һәм догаларны укый һәм сәлам бирә.

**5. ЯСТҮ НАМАЗЫ**

Ястү намазында беренче нәкъ икенденең сөннәте шикелле дүрт рәкәгать сөннәт, аннан соң камәт төшереп, өйләнең фарызы шикелле дүрт рәкәгать фарыз, аннан соң иртәнге намазның сөннәте шикелле ике рәкәгать ахыргы сөннәт башкарыла. Боларның аермалыгы бары тик ният итүдә генә, бүтән аермалар, үзенчәлекләр юк.

**ВИТЫР НАМАЗЫ**

Витыр намазы өч рәкәгать. Моның вакыты ястүнеке белән бер үк. Шунлыктан важиб намаз буларак витыр намазы ястү намазыннан соң укыла. Аның һәр рәкәгатендә “Фатиха” һәм сүрә укыла. Витыр намазы түбәндәгечә үтәлә: иң беренче: “Аллаһ ризалыгы өчен бүгенге витыр намазын үтәргә ният иттем” дип ният ителә һәм “Әллааһү әкбәр” дип тәкбир әйтеп намазга басалар. Иртәнге намазның сөннәте шикелле ике рәкәгать укылгач, утырып “Әттәхият” укыйлар. “Әллааһү әкбәр” дип өченче рәкәгатькә торалар. “Фатиха” һәм бер сүрә укыйлар. Аннары рөкугка китмичә, куллар ике якка салына һәм “Әллааһү әкбәр” дип колакларга кадәр күтәрелеп тәкбир әйтелә. Соңыннан куллар багланып “Көнүт” догасы укыла. Шуннан соң куллар тагын төшерелеп, бүтән намазлардагыча “Әллааһү әкбәр” дип рөкугка китәләр. Сәҗдә кылына һәм сәҗдәдән соң утырып “Әттәхият”, салават, догалар укыйлар һәм сәлам бирәләр. Шулай итеп, бер көн тәүлегендә кылына торган биш вакыт намазның фарыз, важиб һәм сөннәт рәкәгатьләренең тулы санын түбәндәге исәптән белеп була: а**)** **ф**арызлар**:** иртән 2, өйләдә 4, икендедә 4, ахшамда 3, ястүдә 4. Барлыгы: 17 рәкәгать; б**)** **в**аҗиблар**:** витыр намазының 3 рәкәгате. Барлыгы: 3 рәкәгать; в**)** **с**өннәти-мөәккәдәләр**:** иртән 2, өйләдә 4 һәм 2, ахшамда 2, ястүдә 2. Барлыгы: 12 рәкәгать; г**)** **с**өннәти гайре-мөәккәдәләр**:** икендедә 4, ястүдә 4. Барлыгы: 8 рәкәгать.

## СӘҺҮ СӘҖДӘСЕ

Сәһү сәҗдәсе — ул намазда онытылып яисә бүтән сәбәп белән кылынмый калган берәр кимчелек яисә артыклык нәтиҗәсендә барлыкка килгән җитешсезлекне төзәтү өчен важиб булган сәҗдә.

**СӘҺҮ СӘҖДӘСЕН ВАҖИБ КЫЛГАН СӘБӘПЛӘР**

Сәһү сәҗдәсе намаз эчендәге берәр важибны калдыру яки кичектерү сәбәпле кылына. Фарызны бары тик кичектерү очракларында гына сәһү сәҗдәсе кылына. Фарыз өлеше онытылса, сәһү сәҗдәсе генә җитми, намазны яңадан укырга кирәк. Намазның сөннәтләреннән берсе калдырылса сәһү сәҗдәсе кирәкмәс. Кем дә булса намазда тавышсыз укыла торган сүрәләрне тавыш

белән, тавыш белән укыла торганнарны да яшерен укыса, витыр намазында көнүтне төшереп калдырса, яисә дүрт рәкәгатьле намазда беренче кәгъдәне онытса, сәһү сәҗдәсен кылырга тиеш. Шул рәвешчә хатасын төзәтә.

### СӘҺҮ СӘҖДӘСЕНЕҢ ҮТӘЛҮЕ

Сәһү сәҗдәсен үтәгәндә, намазның ахырында "Әттәхият"не укып, ике якка сәлам биргәннән соң "Әллааһү әкбәр" дип тәкбир әйтеп, бер-бер артлы ике тапкыр сәҗдә кылыр. Икенче сәҗдәдән соң "Әттәхият", "Әллаһүммә салли", "Әллаһүммә бәәрик", "Раббәнәә әәтинәә..." догаларын укып сәлам бирер. Имам булган кеше ялгышса, уң тарафка гына сәлам биреп сәһү сәҗдәсен кылыр.

## ҖОМГА НАМАЗЫ

Җомга намазы – ул җомга көнне, өйлә вакытында җәмәгать белән уку фарыз булган намаз. Биш вакыт намаз шартларыннан башка җомга намазының өстәмә ике шарты да бар:

1- вөҗүб, ягъни мөселманга фарыз булуы;

2 – сиххәт, ягъни җомга намазының дөрес булу шартлары.

**Җомга намазының вөҗүб шартлары җидәү:**

1 – Ир-ат булу (ягъни хатын яки хөнсә булмау).

2 – Азат буллу (төрмәдә һәм тоткын булмау).

3 – Җирле кеше булу (сәфәрдә булмау).

4 – Сәламәт булу (намазга бара алмаслык дәрәҗәдә чирләмәү).

5 – Күзләре сәламәт булу (сукыр булмау).

6 – Аяклары сәламәт буллу.

7 – Намазга бармаска бер сәбәп булу (дошманнан курку, бик каты яңгыр явып пычрак булган кебек нәрсәләр җомга намазына бармаска сәбәп була ала).

**Җомга намазының дөрес булу шартлары алты:**

1 – Җомга намазы укылачак җирнең шәһәр булуы (рөхсәт бирелсә авылларда да укылыр).

2 – Падишаһ яки мөфти тарафыннан рөхсәтле кешенең имам булуы.

3 - Өйлә намазының вакытында укылуы.

4 – Җәмәгать алдында хөтбә укылуы.

5– Имамнан башка кимендә өч кеше булуы.

6 – Җомга намазы укылган җир һәркемгә билгеле һәм ачык булуы.

**Җомга намазына ниятләнү**

Иң беренче укылган дүрт рәкәгатькә: "Җомга намазының әүвәлге сөннәтенә" дип ният ителә. Шуннан соң имам белән бергә укылган ике рәкәгать – җомга намазының фарызы була. Моннан соң үтәлгән дүрт рәкәгать җомга намазының ахыргы сөннәте була.

Тагын соңыннан үтәлгән дүрт рәкәгать "зөһрә-ахир" дип атала. Моңа түбәндәгечә ният ителә: "Башкарылуы миңа фарыз булып та әле дә өстемнән төшмәгән соңгы өйлә намазының фарызын үтәргә ният иттем". Шул рәвешчә ният ителсә, әгәр ул көннең җомга намазы шартларында берәр кимчелек булып

кабул ителмәсә, өйлә намазы укылган булыр, җомга намазы кабул ителсә казага калган өйлә намазы булып саналыр. Зөһрә-ахирдән соң кылынган ике рәкәгать намазга исә “вакыт сөннәтенә” дип ният ителер. Әгәр җомга намазының фарызыннан соң бу ун рәкәгать укылмаганда, шартларында кимчелек булу сәбәпле җомга намазы кабул булмаса, өйлә намазы бурыч булып калыр. Шуңа күрә җомга намазының фарызыннан соң укылган бу ун рәкәгатьне төшереп калдырырга һич кенә дә ярамый.

## БӘЙРӘМ НАМАЗЛАРЫ

Җомга намазы фарыз булган кешеләргә бәйрәм намазлары важиб. Ике бәйрәм намазы бар: Рамазан бәйрәме намазы һәм Корбан бәйрәме намазы. Бәйрәм намазларының вакыты, кояш чыккач 45 минуттан башланып, өйләгә кадәр дәвам итә. Бәйрәм намазлары җәмәгать белән ике рәкәгать укыла. Нәкъ иртәнге намазның фарызы шикелле башкарылып, артыклыгы тик шунда – һәр рәкәгатьтә өчәр тапкыр тәкбир әйтелә. Өчесе әүвәлге рәкәгатьнең “Сүбхәнәкә”сеннән соң һәм кыйраәттән элек, өчесе икенче рәкәгатьнең кыйраәтеннән соң әйтелә. Бу алты тәкбирне әйтү важиб. Рөкуг тәкбирләре дә бу важиб тәкбирләргә якын булган өчен важиб. Һәр намаздагыча ифтитәх тәкбире бәйрәм намазларында да фарыз. Калган тәкбирләр сөннәт булып санала. Бәйрәм намазларында хөтбә намаздан соң укыла. Рамазан бәйрәмендә фитыр садакасы, Корбан бәйрәмендә корбан хакында сөйләнә. Корбан бәйрәме Гарәфә көненнән соң, иртәнге намаздан башлап дүртенче көннең икенде намазына кадәр намазда фарыздан соң тәшрик тәкбирләрен уку важиб.

**Тәшрик тәкбире:** Әллааһү әкбәр. Әллааһү әкбәр. Ләә иләәһә илля-ллааһү үәллааһү әкбәр. Әллааһү әкбәр үә лилләәһил-хәмд.

Хатын-кызмы, ир-атмы, бер ялгызы яки җәмәгать белән булса да, мосафир яисә мокыйм булса да, һәр фарыз намаздан соң тәшрик тәкбирләрен әйтү важиб.

## КАЗА НАМАЗЛАРЫ

Һәр акыллы, мөселман ир һәм хатын-кыз балигъ булганнан соң, бөтен дини вазифалар белән бергә, биш вакыт намазны үтәргә тиеш. Шунлыктан намаз калдыру катгый тыела. Корьән Кәримдә Аллаһы Тәгалә 55 урында һәр мөселманга намаз укуны әмер иткән, 33 урында намазның зәкят белән бергә фарыз икәнлеген әйткән. Корьән Кәримдә намаз турында барлыгы йөздән артык урында искә алына. Намаз хакындагы әмернең шулкадәр кат-кат әйтелүе бер яктан намазның фазыйләтенә һәм савабына ишарәләсә, икенче яктан намаздан баш тарткан өчен җавап бирүнең бик авыр булачагына дәлил булып тора. Пәйгамбәр әфәндебез бер хәдис-шәрифендә: “Аллаһы Тәаләнең Кыямәт көнендә колларын җавапка тартканда иң беренче сорау намаз турында булачак” дип, намаз хисабын төгәл бирүчеләрнең бүтән җаваплары да җиңел биреләчәген, бу хисапны төгәл бирә алмаганнрның башка мәсъәләләрдә дә кыенлыкта калачагын аңлаткан. Бер кеше бер намаз урынына миллионнарча сум акчаны садака итеп бирсә яисә берсенең ике рәкәгать намазы урынына йөз рәкәгать

намаз укыса, намаз бурычы һәм җаваплылыгы шулар белән бетми, алынмый, түләнми. Намаз кемгә фарыз булса, шул бәндәнең үзе тарафыннан укылуы белән үтәлер. Һәм шунлыктан бер кешенең гафләт, гамьсезлек яки ялкаулык нәтиҗәсендә, үз вакытында укымаган намазы булса, ул кичекмәстән казасын укырга һәм бу намазны казага калдырганы өчен тәүбә һәм истигъфар кылырга тиеш.

Намазда бурычы булган кеше бурычларын санап чыгар, аннары калдырылган иң соңгы намазыннан башлап каза кылырга тотыныр. Иң әүвәлгесеннән башларга яраса да, иң камил яшьтә калдырылган намазлар өчен җаваплылык иң авыры булуын искә алып, шуларны гафу иттерүдән башларга кирәк дигән фикер туа. Казаны үтәгәндә, фарыз һәм витыр намазлар гына каза кылына. Сөннәтләр каза кылынмый.

Каза намазы тыелган вакытлардан тыш, тәүлекнең теләсә нинди вакытында укыла ала. Казаларын укыган кеше тәһәҗҗүд, әүвәбин, духа, тәсбих намазларын һәм мөбарәк кичәләрдә укыла торган хаҗәт намазларын, башка нәфелләрне дә укый ала – монда һичбер тыюлар, чикләүләр юк. (Ибне Габидин, 1 том, 688 бит)

## КАЙБЕР НӘФЕЛ НАМАЗЛАР

Фарыз намазларын җиренә җиткереп башкарудан тыш тагын нәфел намазларын, ягъни әүвәбин, духа, тәсбих һәм тәһәҗҗүд намазларын да укыса яхшы була. Чөнки бу намазларда сансыз-санаусыз күп савап, дәрәҗә һәм матурлык бар. Бер көдси хәдистә Аллаһы Тәгалә: “Колым фарызлар ярдәмендә Минем газабымнан котылыр, нәфелләр белән миңа якынаер” диде.

### ӘҮВӘБИН НАМАЗЫ

Әүвәбин намазында йөз савап бар. Аллаһы Тәгалә шуларның җитмеш бишен ахирәттә, егерме бишен дөньялыкта бирә. Әүвәбин намазын дәвамлы рәвештә укучылар, Кыямәт көнендә бернинди читенлек-кыенлык күрмәячәкләр. Әүвәбин намазы ахшам намазыннан соң 6 рәкәгать итеп укыла.

### ДУХА НАМАЗЫ

Духа намазында йөз савап бар. Аллаһы Тәгалә шуларның җитмеш бишен дөньялыкта, егерме бишен ахирәттә бирер. Димәк, духа намазын даими үтәүчеләр дөнья газапларын күрмәячәкләр. Духа намазы кояш тугач, 45 минуттан соң 6 рәкәгать итеп укыла.

### ТӘҺӘҖҖҮД НАМАЗЫ

Тәһәҗҗүд намазындагы саваплар иксез-чиксез. Анны даими укыганнарның һәр догасы кабул була, дәрәҗәләре югары булыр. Чөнки Рәсүлулла салләллаһү галәйһи вә сәлләмнең бер дә калдырмаган намазы. Бу 6 рәкәгать булып, тәһәҗҗүд вакытында, ягъни көндез өйлә вакыты сәгать 12дә булса, төнге 12дә кергән тәһәҗҗүд вакытында укыла һәм имсәк вакытына кадәр дәвам итә.

Бу намазларның ниятләре һәм ничек үтәлеше “Мөбарәк көндә һәм кичәләрдә киңәш ителә торган дога һәм гыйбәдәтләр” дигән әсәребездә бәян ителгән.

**ТӘСБИХ НАМАЗЫ**

Тәсбих намазы — тәүбә һәм истигъфарларның иң олысы һәм бөтен тән белән эшләнә торганы. Хәзрәти Гыйкримәдән, ул исә үз чиратында хәзрәти Ибне Габбастан ишетеп риваять иткән: Хәзрәти Рәсүл Әкрам салләллаһү галәйһи вә сәлләм мөхтәрәм агасы Габбас ибне Габделмотталиб хәзрәтләренә әйткән: “Әй, Агам! Мин сиңа ун махсус киңәш бирүем белән хөрмәт күрсәтим әле, ул киңәшләремне тоткан тәкъдирдә синең гөнаһларыңның әүвәлгесе һәм соңгысы, яңасы һәм искесе, хаталык белән һәм белеп эшләгәне, бәләкәе һәм олысы, яшерене һәм ачыгы – барысы да гафу ителер. Көчең-кодрәтең житсә, шундый намазны һәр көнне укы, һәр көнне укый алмасаң, аена бер тапкыр укы. Аны да булдыра алмасаң, елына бер тапкыр укы, һич булмаса гомереңдә бер тапкыр укы”.

**ТӘСБИХ НАМАЗЫНЫҢ УКЫЛУ ТӘРТИБЕ**

Тәсбих намазы дүрт рәкәгать. Бу намазда 300 тапкыр мондый тәсбих укылыр: “Сүбхәна-ллааһи үәл-хәмдү лилләәһи үә ләә иләәһә илләллааһү үәллааһү әкбәр. Үә ләә хәүлә үә ләә куәтә илләә билләәһил-галийил-газыйм” дип әйтерсең. Бу тәсбих намазда шулай укыла**:** 15 тапкыр “Сүбхәнәкә”дән соң “Фатиха”га кадәр; 10 тапкыр өстәмә сүрәдән соң; 10 тапкыр рөкугта; 10 тапкыр рөкугтан торгач; 10 тапкыр беренче сәждәдә; 10 тапкыр ике сәждә арасында; 10 тапкыр икенче сәждәдә укыла.

Беренче рәкәгатьтә укылган тәсбихләрнең саны 75. Икенче рәкәгатьтә дә шул тәртип белән 75 тапкыр укыла. Өченче һәм дүртенче рәкәгатьләр дә шулай ук укыла. Уку тәртибен белмәгәннәр файдалану максаты белән җәмәгать белән укырлар. Җәмәгать белән укыганда имам булачак кеше беренче бу намазны укырга нәзер итәр һәм намаз укыганда тиешле тәсбихләрне һәр урында кычкырып әйтер. Җәмәгать тавышсыз гына аның әйткәнен кабатлый.

**ҖЕНАЗА ТУРЫНДА**

Үлем хәлендә булган мөселманны уң ягына яткырып, йөзе кыйблага каратылыр. Аның янында шәһадәт кәлимәсе әйтелер һәм “Йәсин” сүрәсе укылыр. Вафат булгач, башы бер бәз белән бәйләнә. Күз кабаклары ябылып, куллары ике якка җибәрелә. Шешенмәс өчен корсагына бер тимер кисәге куела. Юылганчы янында Коръән укылмый. Юылганда аяклары кыйблага каратылып, махсус колашага яткырыла. Гаурәт төшләрен ябып, киемен салдыралар. Мәет җылы су белән юыла.

Әгәр вафат булган кеше намаз укый торган булса, юучы кулына бер тукыма чорнап юа башлагач, каплавычын ачмыйча тәһарәт алдыра, авыз-борынына су салмый. Әгәр җөнеб икәнен белсә, авыз-борынын да юар. Булмаса, авыз-борын эчләрен, тешләрен, танауларын һәм кендек эчен мәсех кылу да

җитә. Башы һәм сакалы сабынлап юыла. Әмма чәчләре таралмый. Шуннан соң юучы мәетне сул ягына яткырып уң ягын, уң ягына яткырып сул ягын юа. Соңра, билдән югары ягын күтәреп, үзенә терәтеп, корсагын мәсех кыла. Мәеттән нәҗес чыкса, су белән юыла, әмма мәетне яңадан юмый. Шуннан соң пакь бәз белән киптерелеп, кәфенләнә.

## КӘФЕН

Кәфен – вафат булган мөселманны төреп кабергә куела торган бәз. Кәфен ирләр өчен камис (озын күлмәк), изар (киң тасма) һәм лифәфәдән (тулы конверттан), хатын-кыз өчен камис, изар, лифәфә, баш яулыгы һәм күкрәкләре өстеннән бәйләнгән бәздән – ак тукымадан гыйбарәт. Әгәр бәз аз булса, ирләр өчен изар һәм лифәфә, хатын-кыз өчен изар, лифәфә һәм баш капламасы да җитә. Алай да эшләп булмаса, мәет бер бәзгә төрелеп күмелә. Кәфеннең ак мамык тукымадан булуы хәерлерәк.

## МӘЕТ НИЧЕК КӘФЕНЛӘНӘ?

Мәет камис белән муеныннан аягына кадәр, изар белән башыннан аягынача төрелә һәм лифәфә белән бөтен тәне каплана һәм очлары бәйләнә. Төрелгәндә сулдан уңга таба төрелә. Кәфендә кесә һәм якалар булмый, кырыйлары кайтарылып тегелми. Хатын-кызда баш капламасы камис өстеннән һәм лифәфә астына куеп калдырыла.

## ҖЕНАЗА НАМАЗЫ

Җеназа намазы вафат булган дин кардәшләребезнең рухына дога кылу белән бәйле бер фарыз кифәя.

Җеназа намазының шартлары түбәндәгеләр:

1. Вафат булган кешенең мөселман булуы. Мөселман булуы билгеле булмаса, яисә бу хосуста мөселманмы, түгелме икәнлеге беленмәгән кешегә җеназа укылмый, аның мөселманлыгына дәлил һәм шаһитлар кирәк була. Дәлилләр һәм шаһитлар, могътәбәр кешеләр тарафыннан аеруча билгеләнә.

2. Мәет юылгач, пакь кәфенгә төрелүе.

3. Мәетнең имам һәм җәмәгать алдында булуы.

4. Мәетнең тулысынча яисә, һич булмаса, тәненең зуррак өлеше булуы, әгәр тәненең зур өлеше яисә башы булмаса, җеназа намазы укылмый һәм мәет юылмый. Бер бәзгә төрелеп күмелә.

## ҖЕНАЗА НАМАЗЫНЫҢ УКЫЛУ ТӘРТИБЕ

Җеназа намазы дүрт тәкбир һәм кыям белән үтәлә. Бу намаз сәҗдәсез һәм рөкугсыз башкарыла.

Имам мәетнең күкрәге турысында баса, ә җәмәгать аның артында саф-саф булып тезелә. Җыелучыларга мәрхүмнең ир-атмы, хатын-кызмы икәнлеге игълан ителә һәм аңа карата ният ителә. Ягъни: “Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен намазга, мәет өчен догага, ир кеше (яки хатын кеше) ниятенә оедым ошбу имамга” — дип күңелдән ният ителә һәм имам артыннан тәкбир әйтелә. Әүвәлге тәкбирдә куллар колак тәңгәленә күтәрелеп, көндек астына багланып

“Сүбхәнәкә...” догасы “үәҗәллә сәнәәүк” белән бергә укылыр. Кулларны кабат күтәрмичә генә икенче тәкбир әйтелә, бу тәкбирләрне имам кычкырып, җәмәгать эчтән генә әйтә. “Әллаһүммә салли” һәм “Әллааһүммә бәәрик” укыла. Моннан соң өченче тәкбир әйтелә. Җеназа догасы укыла. Җеназа догасын белмәгәннәр бу очракта “Әллааһүммә иннәә нәстәгыйнүкә...”, ягъни көнүт догасын яисә дога нияте белән “Фатиха”ны укырга мөмкин. Аннары тагын дүртенче тәкбир әйтелеп куллар төшерелә һәм сәлам бирелә. Өченче тәкбирдән соң укыла торган җеназа догасы**:** Әллааһүммә-гъфир лихәйинәә үә мәйитинәә үә шәәһидинәә үә гааибинәә үә кәбииринәә үә сагыыйринәә үә зәкәринәә үә үнсәәнәә. Әллааһүммә мән әхйәйтәһүү миннәә фә әхйиһии галәл-исләәми үә мән тәүәффәйтәһүү миннәә фәтәүәффәһүү галәл-иимәәни үә хусса һәәзәл-мәййитә бир-раухи үәр-раахәти үәр-рахмәти үәл-мәгфирати үәр-ридуан. Әллааһүммә (ин кәәнә мүхсинән фәзид фи-ихсәәниһии үә ин кәәнә мүсииән фәтәҗәәүәз ганһү)* үә ләккыйһиләмнә үәл-бүшраа үәл-кәраамәтә үәз-зүлфәә бирахмәтикә йәә әрхәмәр-раахимиин.

Мәгънәсе**:** “Аллаһым! Безнең тереләребезгә, үлгәннәребезгә, мондагыларга һәм күренмәгәннәргә, олыларыбызга һәм кечеләребезгә, ир-атларыбызга һәм хатын-кызларыбызга гафу һәм мәгъфирәт бир! Әй Раббыбыз! Бездән соң яшәүчеләребезне Ислам буенча яшәт, үлүчеләребезне иман белән үтер. Хосусән, бу мәрхүмне уңайлыкка, рәхәтлеккә, гафу ителүгә, ризалыгыңа ирештер. Әй Раббыбыз! Әгәр бу мәрхүм ихсанлы булса, ихсанын (рухи гүзәллеген) арттыр һәм әгәр ярамас эшләр кылган булса, гафу ит. Рәхмәтең белән үзенә иминлек, сөенечлек, юмартлык һәм якынлык насыйп ит, әй мәрхәмәтлеләрнең иң мәрхәмәтлесе!”

Мәрхүм ир бала булса**,** югарыдагы дога “галәл-имән”нән соң түбәндәгечә укыла: “Әллааһүммә-җгальһү ләнәә фәратан үәҗгальһү ләнәә әҗран үә зуһра. Әллааһүммә-җгальһү ләнәә шәфиган үә мүшәффәган”.

Мәрхүм кыз бала булса “галәл-имән” нән соң болай укыла: “Әллааһүммә-җгальһә ләнәә фәратан үәҗгальһә ләнәә әҗран үә зуһра. Әллааһүммә-җгальһә ләнәә шәәфигатән үә мүшәффәгатән”.

* - Хатын-кыз булса, “ин кәәнәт мүхсинәтән фәзид фи ихсәәниһәә үә ин кәәнәт мүсиәтән фәтәҗәәүәз ганһә үә ләккыйһәл-әмнә” дип әйтелә.

## МӨҺИМ ИСКӘРМӘЛӘР

а) Күп кенә кешеләр җеназа намазының дүртенче тәкбирендә яки кулларын һич төшермичә сәлам бирәләр, яки уң тарафка сәлам биргәндә уң кулларын, сул тарафка сәлам биргәндә сул кулларын төшерәләр. Бу хәрәкәтләрнең һәр икесе дә ялгыш. Дөресе — дүртенче тәкбирне алганнан соң кулларны янга төшереп сәлам бирү. (“Дүрәр”, 1/53)

б) Җеназа намазында имам ачык итеп “Әллааһү әкбәр” дип тәкбир әйткәч, кайбер кешеләр башларын югары күтәрәләр. Бу да бик ялгыш хәрәкәт. Иң

дөресе – намаз тәмамланганчы баш белән дә, бүтән әгъза белән дә төрле хәрәкәтләр ясамау.

в) Җеназа укылачак җир яисә аяк киеме чиста булмаса, аяк киемен салып шуның өстенә басалар.

**КАБЕР ҺӘМ ДӘФЕН**

Җеназа намазы укылгач, табутның дүрт почмагыннан тотып күтәреп бару сөннәт. Мөмкин булса кимендә кырык адым күтәреп барырга кирәк. Күтәрүчеләр игътибар белән һәм табутны бик селкетмичә барырга тиешләр. Мәетне ташыганда һәм күмгәндә күтәренке тавыш белән зикер әйтү, мәетне җиргә индерелгәнче җиргә утыру мәкруһ. Кабер кимендә ярты кеше буе тирәнлегендә һәм мәет җиңел керерлек киңлектә булырга тиеш. Тирәнрәк казылса да начар түгел. Кабер казылып беткәч, җир ишелми торган булса, ләхет алына. Ягъни кабернең кыйбла тарафы мәет сыярлык итеп уела һәм мәет шунда кертелә. Мәет кабергә кыйбла тарафыннан төшерелә. Кабергә төшергән кеше мәетне уң ягына яткырып, йөзен кыйблага каратып куйганда: “Бисмилләәһ үә галәә милләти рәсүлилләәһ!” — дип әйтә. Кәфеннең баш һәм аяк очларындагы баулары чишелә. Ләхет эчендәге җеназа өстенә туфрак коелмасын өчен кирпеч яисә такталар куела. Кирпеч җиңел табылып та, аның урынына такталар яки ясалма материаллар кую мәкруһ. Кабер туфрак белән күмелә. Шул ук җирдән алынган туфрак белән күмү шарты белән җирдән кимендә бер карыш (аршын) биегәйтеп, шуннан соң тагын өркәчләндереп өелә. Өем почмаклап куелмый.

Кабер өстенә зиннәт өчен бина ясау мәкруһ. Чиста булсын дип өстенә төзелеш кору да мәкруһ. Өй эченә күмү пәйгамбәрләргә хас. Гүр иясенең хәтирәсе югалмасын өчен язулы таш куюда гөнаһ юк. Мәетне бина эченә күмү дә мәкруһ, ярамас эш. Талашып һәм басып алынган урынга да күмәргә ярамый. Мәет хуҗаларының кайгысын уртаклашу 3 көн. Моннан артыгы мәкруһ санала. Мәетне сәбәпсез бер шәһәрдән икенче шәһәргә күчерү файдасыз һәм мәкруһ. Үлгән кешеләрнең рухы өчен тәүхид кәлимәсен (тәһлил) әйтергә һәм Коръән Кәрим хәтемнәрен укырга ярый. Мондый хәтемнәрдә мәрхүм өчен бик зур әҗер, савап һәм файда бар. Аннары мәетнең рухын шат итү өчен садака һәм хәерләр бирү, фәкыйрьләргә ярдәм итү - рухи матурлыкның билгесе.

**КАБЕР СОРАВЫ**

Мәет кабергә куелганнан соң, аның янына ике фәрештә килеп Раббысы, дине, пәйгамбәре, китабы хакында сорау бирерләр. Иман, итәгать һәм изге гамәл иясенә Аллаһы Тәгалә фәрештәләрнең сорауларына җавап бирерлек көч бирер. Ләкин кәферләр һәм гөнаһлылар, баш күтәрүчеләр Мөнкир һәм Нәкир исемендәге бу сорау бирүче фәрештәләрен күргәч, аларның күренешеннән һәм олылыгыннан куркып телләре тотылыр һәм җавап бирә алмаслар.

Фәрештәләрнең сорауларына җавап бирә алган мөэминнәрне җәннәт хәбәре белән сөендерерләр һәм моннан соң бу мөэминнәргә илаһи ихсан һәм әҗер кылә башлар. Җавап бирә алмаган кәферләргә һәм гөнаһлыларга исә “Вай,

синең хәлең начар!”, - диярләр. Аларның тәннәренә җәһәннәмнән мәгънәви бау бәйләнер һәм алар кабердә газап чигә башларлар.

**КАБЕР СОРАУЛАРЫ ҺӘМ ҖАВАПЛАРЫ**

- Раббың кем?
- Раббым – Аллаһы Тәгалә.
- Динең ни?
- Динем – Ислам дине.
- Пәйгамбәрең кем?
- Пәйгамбәрем – Мөхәммәд галәйһис-сәлам.
- Китабың нинди?
- Коръән Кәрим.
- Кыйблаң кайда?
- Кыйблам – Кәгъбәи-Мөгаззәмә.
- Син кемнең токымыннан?
- Мин хәзрәти Адәм галәйһис-сәләм токымыннан һәм үзем хак мөселман, әлхәмдү лилләәһ.

**КАБЕРЛӘРНЕ ЗИЯРАТ ИТҮ**

Ирләр һәм хатыннар өчен каберләрне зиярат итү матур эш. Анда “Йәсин-шәриф”. “Әлһәәкүмүт-тәкәәсүр” сүрәсе, бер “Фатиха” белән 11 “Ихлас” сүрәсе укылыр, үлгәннәрнең рухына багышланыр. Кабер өстенә утырып уку катгый тыелмаса да, дога укымыйча кабергә менү, шунда йоклау һәм пычрату мәкруһ. Әгәр кабер аркылы үтәргә туры килсә, бер “Фатиха”, унбер тапкыр “Ихлас” укылып, кабердә яткан мөселман рухынабагышлана һәм шуннан соң гына үтеп кителә. Кабер өстендәге агачларны кисү һәм үләннәрне йолку да мәкруһ. Чөнки агач һәм үләннәр үскән дәверләрендә кабердә ятканнарның гөнаһларын җиңеләйтәләр. Корыган агач һәм үләннәрне кисү, йолку тыелмый. Әммә бу да урынына карап эшләнә. Инде аларны утын итеп файдалану әйбәт түгел.

**СӘФӘР ТУРЫНДА**

Коры җирдә дөя яки җәяү унсигез сәгатьлек (бүгенге исәп белән 90 километрлык), диңгездә алтмыш миллек бер ераклыкка китү сәфәр хөкеменә керә. Шул араны үткән юлчыга шәригать буенча мосафир диләр. Нинди нәрсә белән һәм күпме вакыт эчендә үтсә дә, торган җиренең соңгы өйләрен үтү белән мосафир хөкеменә керә. Юлга чыгып, авылның яки шәһәрнең соңгы өйләрен узган кеше юлчы, ягъни үзен мосафир дип исәпли. Сәфәре Рамазан аенда булса, мосафир уразасын казага калдырырга хаклы. Әмма сәламәтлегенә зыян китермәсә, ураза тоту хәерлерәк. Дүрт рәкәгатьле фарыз намазларны ике итеп укый. Әмма ахшам намазының фарызы, витыр намазы һәм дүрт рәкәгатьле сөннәтләр тулысынча укыла. Бер кеше 4 рәкәгатьле фарызларны мосафир булганда 4 итеп укыса, хата эшләгән булыр. Бу хата өчен гафу сорау һәм сәламне соңга калдырганга күрә сәһү сәҗдәсе тиешле була. Сәфәрдә булган мосафир җирле имамга ияреә, җәмәгать белән бергә тулысынча укыр. Аның

үзенә имам вазифасын башкарырга туры килсә, ике рәкәгать кенә укыр һәм сәлам бирер. Әгәр аңа ияргән җәмәгать мосафирлардан булса, сәләм биреп, намазны имам белән бергә тәмамларлар. Әгәр ул җәмәгать мосафирлардан булмаса, намазның калган рәкәгатьләрен үзләре укып бетерерләр. Кыямда яки “Фатиха” укырлар, яки укымаслар.Укымаган очракта “Фатиха” укыячак кадәр көтеп, аннан соң рөкугка барырлар. Әгәр мосафир кеше барган җирләрендә (шәһәрдә яки авылда) унбиш көн һәм күбрәк торырга исәпләсә, ул мосафир хөкеменнән чыга һәм намазларын тулысынча укый. Унбиш көн торырга ниятләмичә, эшләренең бетмәве сәбәпле бүген яки иртәгә чыгармын дип айлар буена, хәтта еллар буена көтсә, барыбер сәфәр хөкемендә була. Мосафир кеше үз ватанына кайтуга мокыйм хөкеменә керә, ягъни мосафирлыктан чыга. Асыл ватанында никадәр калса да барыбер мокыйм булып, намазларын тулысынча укыр.

Сәфәрдә казага калган дүрт рәкәгатьле намазларын мосафир кеше тукталышта яисә иленә кайткач ике рәкәгатьле итеп үтәр. Әмма мокыйм булганда казага калдырылган дүрт рәкәгатьле намазларны дүрт рәкәгать итеп тулысынча укырга тиеш.

**Яшәгән җир (ватан) өч төргә бүленә:**

**1 –** Ватани-асыл**;**

**2 –** Ватани-икамәт**;**

**3 –** Ватани-сөкнә**.**

Ватани-асыл**:** кешенең туып-үскән һәм өйләнгән җире. Туып-үсмәгән һәм өйләнмәгән җир булса да, шунда яшәргә ниятләп шул урында калырга теләгән җиргә дә ватани-асыл диләр. Ватани-асыл үзе кебек бер ватани-асыл белән бозыла. Мәсәлән: кешенең туып-үскән җире бер ара аның ватани-асылы булып, ул башка шәһәрдән хатын алса, хатынының туып-үскән җире ватани-асыл хөкеменнән чыга. Ул элеккеге ватани-асылына кайтып унбиш көннән азрак вакыт торса, дүрт рәкәгатьле намазларын кыскартып, ике рәкәгать итеп үтәр. Мәсәлән, Казанда туып-үскән кеше Уфада туып-үскән кызга өйләнсә һәм хатыны белән Оренбургка барып урнашса, боларның ватани-асылы Оренбург булып санала һәм җефетләрнең берсе Казанга яки Уфага килеп, шунда унбиш көннән азрак вакытта калмакчы булса, мосафир булып санала һәм дүрт рәкәгатьле намазларны ике рәкәгатьле итеп укый. Кемнең дә булса бердән артык хәләл хатыны булып, боларның һәркайсысы аерым-аерым шәһәрдә торсалар, ул кеше хатыны яшәгән һәр шәһәрдә мокыйм булып хисаплана һәм намазларын тулы килеш үтәргә тиеш була. Димәк, кешенең гаиләсе белән урнашкан, җирләшкән җире аның ватани-асылы була. Ватани-асыл ватани-икамәт белән бозылмаган кебек сәфәргә чыгу белән дә үзгәрми.

Ватани-икамәт – мосафирның ватани-асылыннан кимендә 90км. ераклыкта булып, мосафир шунда 15 көн һәм күбрәк торырга исәпләгән җир. Бу урында намаз кыскартылмый. Ватани-икамәт икенче бер ватани-икамәт белән

һәм әлбәттә, ватани-асыл белән бозыла. Ватани-икамәт ватани-сөкнә белән бозылмый.

Ватани-сөкнә дигәне югарыда әйткәнчә, мосафирның ватани-асылыннан кимендә 90км. юл үтеп урнашкан һәм шунда унбиш көннән азрак торырга исәпләгән җир. Ватани-сөкнәдә дүрт рәкәгатьле намазлар ике рәкәгатьле итеп укыла.

## КОРЪӘНДӘГЕ ТИЛӘВӘТ СӘҖДӘЛӘРЕ

Коръән Кәримдә тиләвәт сәҗдәсе булган аятьләргә "сәҗдә" дип язылa. Коръән укыган кеше бу аятьне укыганнан соң сәҗдә кыла, ягъни кыйблага юнәлеп кулларын күтәрмичә "Әллааһү әкбәр" дип сәҗдәгә бара. Сәҗдәдә өч тапкыр "Сүбхәнә раббийәл-әгъләә" дип әйтә. Соңра кабаттан "Әллааһү әкбәр" дип тәкбир әйтеп аякка баса һәм "Сәмигнәә үә әтагнәә гуфраанәкә раббәнәә үә иләйкәл-мәсыйр" дип әйтә. Сәҗдә аятен ишеткән кеше дә, тиләвәт сәҗдәсен кылырга тиеш.

Коръән Кәримдәге сәҗдә аятьләре: "Әгъраф" сүрәсе, 206 нчы аять; "Рәгыд" сүрәсе, 15 нче аять; "Нәхел" сүрәсе, 49 нчы аять; "Исра" сүрәсе, 107 нче аять; "Мәрьям" сүрәсе, 58 нче аять; "Хаҗ" сүрәсе, 18 нче аять; "Фуркан" сүрәсе, 60 нчы аять; "Нәмел" сүрәсе, 25 нче аять; "Сәҗдә" сүрәсе, 15 нче аять; "Сад" сүрәсе, 24 нче аять; "Фуссыләт" сүрәсе, 37 нче аять; "Нәҗем" сүрәсе, 62 нче аять; "Иншикак" сүрәсе, 21 нче аять; "Галәкъ" сүрәсе, 19 нчы аять.

# МӨБӘРӘК КИЧӘЛӘРДӘ КЫЛЫНА ТОРГАН ГЫЙБАДӘТЛӘР

## МӘҮЛЕД КИЧӘСЕ

Рабигел әүвәл аеның уникенче, ягъни унбереннән уникесенә каршы кичәсе - Пәйгамбәр әфәндебез туып дөньяны шәрәфләндергән кичә. Бу кичәдә бер тәсбих намазы укыла. Бу намазга түбәндәгечә ният ителә: "Әй, Раббым! Бу кичә хөрмәтенә, дөньяны нурга күмгән сөекле Пәйгамбәребез хөрмәтенә, мине дә шундый илаһи изгелеккә катнашучы ит. Әллааһү әкбәр".

## РӘГАИБ КИЧӘСЕ

Өч изге айның беренчесе булган Рәҗәб аеның тәүге җомга кичәсе, ягъни пәнҗешәмбедән җомгага каршы кичә Рәгаиб кичәсе дип атала. Бу кичәдә ахшам

белән ястү арасында унике рәкәгать хаҗәт намазы укыла, һәр ике рәкәгатьтә сәлам бирелә. Һәр рәкәгатьтә бер тапкыр "Фатиха", өч тапкыр "Иннәә әнзәлнәәһү", унике тапкыр "Ихлас" сүрәсе укылыр. Унике рәкәгать тәмамлангач, җиде яисә җитмеш тапкыр Саләти-өммия укылыр. Ул түбәндәгечә: Әллааһүммә салли галәә сәйидинәә мүхәммәдинин-нәбийил-үммийи үә галәә әәлиһии үә сахбиһии үә сәллим.

Хаҗәт намазына ният болай кылына: "Әй, Раббым! Мине Пәйгамбәр әфәндебез хөрмәтенә илаһи фәезеңә, илаһи гафуыңа, илаһи ризалыгыңа ирештер. Изге колларың арасына билгелә. Дөнья һәм ахирәт авырлыкларыннан азат ит".

Шуннан соң, сәҗдәгә барып, җитмеш тапкыр ошбу тәсбих укыла: “Сүббүүхүн куддүүсүн раббүнәә үә раббүл-мәләәикәти үәр-руух”. Сәҗдәдән торып утыргач, бер мәртәбә шушы дога әйтелә: “Рабби-гъфир үәрхәм үә тәҗәәүәз гаммәә тәгләм. Иннәкә әнтәл-әгаззүл-әкрам”. Кабат сәҗдәгә барып, беренче сәҗдәдә укылган “сүббүүхүн куддүүсүн...” янә җитмеш тапкыр укыла.

## МИГЪРАҖ КИЧӘСЕ

Рәҗәб аеның 27 нче кичәсе, ягъни 26сыннан 27сенә каршы кичә Мигъраҗ кичәсе була. Бу кичәдә ястү намазыннан соң унике рәкәгать хаҗәт намазы укыла. Һәр рәкәгатьтә “Фатиха”дан соң ун тапкыр “Ихлас” сүрәсе укыла һәм һәр ике рәкәгатьтән соң сәләм бирелә. Намаздан соң дүрт тапкыр “Фатиха” һәм йөз тапкыр: Сүбхәна-ллааһи үәлхәмдү лилләәһи үә ләә иләәһә илләә-ллааһү үәллааһү әкбәр. Үә ләә хәүлә үә ләә кувәтә илләә билләәһил-галийил-газыыйм. Йөз тапкыр: “Әстәгъфиру-ллааһәл-газыыйм үә әтүүбү иләйик” дип һәм 100 тапкыр салават укыла. Югарыда әйтелгән намаз 12 рәкәгать урынына 100 рәкәгать итеп тә укыла ала.

## БӘРАӘТ КИЧӘСЕ

Шәгъбан аеның унбишенче кичәсе, ягъни унбишенә каршы кичә бәраәт кичәсе дип атала. Бу кичәдә йөз рәкәгать намаз кылган кеше, шул ел эчендә үлсә, шәһит буларак үлер, ягъни шәһитләргә тиң изге булып саналыр.

Бәраәт кичәсе намазына түбәндәгечә ният ителә: “Әй Раббым! Ният иттем бу намазга, күңел тупаслыгыннан һәм дөнья басуыннан котылу өчен, шулай ук илаһи гафуыңа һәм бәхетлеләр дәфтәренә язылуым өчен...”. Бу намазда ике рәкәгать саен сәлам бирелә. Һәр рәкәгатьтә бер тапкыр “Фатиха”, ун тапкыр “Ихлас” сүрәсе укыла. Йөз рәкәгать намаз шулай ук тәмам ителер.

**Намаздан соң укыла торган догалар:**

14 тапкыр “Әстәгъфиру-ллааһәл-газыыймә үә әтүүбү иләйиик”, шулай ук 14 тапкыр “Әллааһүммә салли үә сәллим үә бәәрик галәә Мүхәммәдин үә галәә әәли Мүхәммәд”. 14 тапкыр “Фатиха”, 14 тапкыр “Аятел-көрси”, 14 тапкыр “Ләкад җәә әкүм”, бер тапкыр “Йәсин”, 14 тапкыр “Ихлас”, 14 тапкыр “Фәләкъ”, 14 тапкыр “Нәс” һәм 14 мәртәбә “Сүбхәна-ллааһи үәлхәмдү лилләәһи үә ләә иләәһә илләллааһү үәллааһү әкбәр. Үә ләә хәүлә үә ләә кувәтә илләә билләәһил-галийил-газыыйм”. 14 тапкыр Саләти мөнҗия укыла һәм дога кылына.

## КАДЕР КИЧӘСЕ

Кадер кичәсендә дүрт рәкәгать намаз укыла. Ике рәкәгатьтән соң сәлам бирелә. Беренче рәкәгатьтә бер тапкыр “Фатиха”, өч тапкыр “Иннәә әнзәлнәәһү”, икенче рәкәгатьтә бер тапкыр “Фатиха”, өч тапкыр “Куль һүвә-ллааһү әхәд”, өченче рәкәгатьтә бер тапкыр “Фатиха”, өч тапкыр “Иннәә әнзәлнәәһү”, дүртенче рәкәгатьтә бер тапкыр “Фатиха”, өч тапкыр “Куль һүвә-ллааһү әхәд” укыла. Бу намазга түбәндәгечә ният әйтелә: **“**Әй Раббым**!** Бу кичә хөрмәтенә**,** Пәйгамбәребез хөрмәтенә**,** рәхмәтең хөрмәтенә минем тәүбәләремне

кабул әйлә. Иләһи гафуыңа, фәезеңә һәм иләһи изгелегеңә кушылучылар арасына керт!”

Намаздан соң бер тапкыр: Әллааһү әкбәр, Әллааһү әкбәр. Ләә иләәһә илләллааһү үәллааһү әкбәр. Әллааһү әкбәр үә лилләәһил-хәмд, дип; йөз тапкыр “Иннәә әнзәлнәәһү”, йөз тапкыр “Әләм нәшрах ләкә садрак” һәм йөз тапкыр “Әллааһүммә иннәкә гафуун кәриимүн түхиббүл гафуә фагфү ганнии”, дип әйтелә.

## УРАЗА

Исламның өченче шарты – ураза. Ураза – гыйбәдәт кылу нияте белән имсәктән башлап кояш баеганчыга кадәр ашаудан, эчүдән һәм җенси мөнәсәбәттән тыелу.

**Уразаның фарызлары:**

1 – Ният итү.

2 – Ниятнең әүвәлге һәм ахыргы вакытын белү.

3 – Имсәктән кояш батканчы уразаны боза торган нәрсәләрдән саклану.

Уразаның башланган вакыты “имсәк” дип, тәмамланган вакыты “ифтар” дип атала.

## УРАЗАНЫҢ ТӨРЛӘРЕ

Ураза алты төрле була:

1 – Фарыз;

2 – Ваҗиб;

3 – Сөннәт;

4 – Мәндүб;

5 – Нәфел;

6 – Мәкруһ.

Фарыз ураза — Рамазан ае уразасының вакытында тотылуы һәм казасы, кәффарәт уразасы.

Ваҗиб ураза — **б**озылган нәфел уразасының казасы һәм нәзер уразасы.

Сөннәт ураза — **м**өхәррәм аеның 9 нчы көне белән рәттән гашура (Мөхәррәм аеның 10нчы көне) көнендә тотылган ураза.

Мәндүб ураза — һәр айда өчәр көн тотыла торган ураза. Бу өч көн “әййәмү-бәйд” (ак көннәр), ягъни ай тулганда һиҗри аеның 13, 14, 15 нче көннәре.

Нәфел ураза — шушы әйтелгән ураза төрләреннән тыш мәкруһ булмаган бүтән уразалар нәфел уразасы диелә.

Мәкруһ ураза — **га**шура көнендә генә тотылган ураза (ягъни мөхәррәм аеның рәттән тугызынчы яисә унберенче көнендә тотылмаган ураза). Рамазан бәйрәменең беренче, Корбан бәйрәменең 1,2,3,4нче көннәрендә ураза тоту хәрамга якын мәкруһ санала.

**Ураза тагын ике төргә бүленә:**

**1 –** Кичтән үк ният ителә торганнары**:** Рамазан аенда тотылмаган уразаның казасы, нәфел ураза булып бозылган һәм көненә көн тотылган ураза, кәффарәт уразалары, вакыты билгеле булмаган нәзер уразалары – мондый төр уразаларда кичтән үк ният итү шарт.

**2 –** Кичтән үк аерым ният ителмәгәннәре**:** Рамазан аеның уразасы, вакыты билгеле булган нәзер һәм нәфел уразаларга кичтән ният итү шарт түгел.

Ният итү кичтән генә түгел (әгәр таң беленгәннән башлап ураза шартлары үтәлсә), өйлә намазына 15 минут калганчыга кадәр ниятләнсә дә дөрес.

Рамазан уразасына гадәти ураза дип ният ителсә дә, нәфел яисә башка төр ураза дип ниятләнсә дә, барыбер Рамазан уразасы булыр.

## УРАЗАНЫ БОЗЫП, ГАДИ КАЗА КЫЛЫРГА МӘҖБҮР ИТӘ ТОРГАН НӘРСӘЛӘР

1 – Ураза исендә булып, тамакка бер нәрсәнең керүе;

2 – Авызны чайкаганда, борынына су алганда эчкә су китү;

3 – Уразага өйләдән соң ниятләү (ниятнең вакыты үтүе);

4 – Онытылып берәр нәрсәне йотып җибәргәннән соң, барыбер уразам бозылды дип, нәрсә дә булса ашау;

5 – Авызга кергән яңгыр яисә кар суын йоту;

6 – Укол кадату;

7 – Борынга дару салу;

8 – Колакка май салу;

9 – Ялгышып, таң беленгәч сәхәр ашау;

10 – Ялгышып, инде кояш батты дип авыз ачу;

11 – Косыгыңны йоту;

12 – Дустыңның яки хатыныңан башкасының төкереген йоту;

13 – Үз төкерегеңне тышка чыгарып, кире йоту;

14 – Чыланган яисә майланган бармагыңны оят төшләреңә кертү;

15 – Теш канаганда, кан төкеректән артык яисә тигез булган хәлдә,төкерекне йоту;

16 – Хуш исле нәрсәләрне яндырып, төтенен авызга алу (тәмәке һ.б. белән хушлану).

## УРАЗАНЫ БОЗЫП, КАЗА ҺӘМ КӘФФАРӘТ КЫЛЫРГА МӘҖБҮР ИТКӘН НӘРСӘЛӘР

1 – Белә торып ашау-эчү;

2 – Белә торып җенси мөнәсәбәткә керү;

3 – Белә торып тәмәке һ.б. тарту;

4 – Гайбәт сөйләгәч, “уразам бозылды” дип, белә торып ашау;

5 – Хатынының яки кемнең дә булса (мәсәлән сөйгән кешеңнең, балаңның) төкереген йоту;

Шушы саналган гамәлләрнең берсен кылган кеше бозган уразасын каза кылудан тыш гөнаһысына кәффарәт кылып, арасын бүлмичә ике ай тоташ ураза тотарга тиешле була.

## УРАЗАЛЫ ЧАГЫНДА МӘКРУҺ БУЛГАН НӘРСӘЛӘР

1 – Кирәге булмыйча, нәрсәне дә булса татып карау;

2 – Кирәге булмыйча, нәрсәне дә булса чәйнәү;

3 – Алдан чәйнәлеп тәме калмаган сагызны чәйнәү (тәмле, татлы сагызлар уразаны боза).

4 – Зәүҗәсен (ирен, хатынын) үбү;

5 – Зәүҗәсенә сарылу;

6 – Төкерегеңне авызга җыеп йоту;

7 – Кан алдыру.

## УРАЗАНЫ БОЗМЫЙ ТОРГАН НӘРСӘЛӘР

1 – Онытылып китеп ашау-эчү һәм җенси мөнәсәбәткә керү;

2 – Бер-береңә тию, уйнашу һәм үбешү, үбү нәтиҗәсендә түгел, ә сокланып карау яки хыяллану нәтиҗәсендә мәни (поллюция) чыгу;

3 – Йоклаганда төшләнү (мәни чыгу);

4 – Үбү (әгәр мәни чыкмаса);

5 – Иртәнге йокыдан тилергән хәлдә уяну;

6 – Авызга килгән лайланы йоту;

7 – Борыннан килгән сыекчаны йоту;

8 – Колакка су керү.

9 – Сәхәр ашаганда тешләр арасында калган азыкны, әгәр ул борчактан зур булмаса, йотып җибәрү;

10 – Теләмичә косу (күп булса да зарар бирмәс);

11 – Сөрмә тарту;

12 – Гайбәт сөйләү;

13 – Күзгә дару тамызу.

## ФИТЫР САДАКАСЫ

Фитыр садакасы нисап микъдарына ия булган һәр мөселманга ваҗиб. Фитыр бирүнең ваҗиб буллу шартлары: мөселман булу, азат (кол түгел) булу һәм нисап микъдарынча мал-мөлкәткә ия булу. Әмма зәкяттән аермалы буларак, фитыр бирү өчен мөлкәтенең арта баруы шарт түгел. Хәтта үз хаҗәтләренең бер еллык микъдарыннан артык мөлкәт булырга тиешле дигән шарт та куелмый. Зәкәт бирелә торган җирләргә фитыр садакасын да бирергә була. Фитыр садакасы, Рамазан бәйрәме көненең таңыннан алып, бәйрәм намазы тәмамланганчы бирелә. Алдан бирсәң дә ярый.

## ТӘРАВИХ НАМАЗЫ

Тәравих намазы хатын-кызга һәм ирләргә сөннәти-мөәккәдә булып, егерме рәкәгатьтән тора. Җәмәгать белән дә, ялгыз да башкарыла. Рамазан аеның сөннәте дип санала. Ястү намазыннан соң, витыр намазыннан әүвәлрәк

укыла. Һәр ике яисә дүрт рәкәгатьтән соң сәлам бирелә. Һәр сәламнән соң бераз утыру сөннәт. Бу хәлдә салават, “Саләти-өммия”, аять һәм догалар укылыр. Имам тәравихта, артындагы җәмәгатьнең торышына аеруча игътибар итәр. Әгәр бу намазда шәфигый мәзһәбендәгеләр булса, ике рәкәгать саен сәлам бирер.

## ЗӘКЯТ

Исламның дүртенче шарты – зәкят. Зәкят — мал-мөлкәтнең билгеле бер өлешен, махсус шартларда, билгеле бер кешеләр төркеменә мөлкәт итеп бирү. Шуңа күрә, бер кеше зәкят бирү нияте белән фәкыйрьне туйдырса, бу мөлкәт булмаган өчен зәкят булып саналмый.

Зәкятнең фарыз шартлары**:** балигъ, акыллы һәм азат булган, бурычы булмаган мөселманның үз ихтыяҗларыннан арткан һәм өстеннән бер ел үткән билгеле күләмдәге мал-мөлкәткә (нисапка) хуҗа булуы. Аермалы буларак, мал-мөлкәтнең арта баруы шарт. Әмма алтын һәм көмеш артып бармаса да, алар нисап микъдарында булса, зәкят бирелә.

Нисап**:** Зәкят өчен дин буенча төгәл билгеләмә бар, бурычларыннан тыш кимендә егерме мискал (80 грамм) алтын яки шуңа тиң акча яисә сатулык малы булу.

Нисап микъдарында булган акчаның кырыктан бер өлеше зәкят итеп бирелә. Мал-туардан зәкят терлекнең төренә карап бирелә: кырык сарыктан бер сарык, биш дөядән бер сарык, утыз сыердан бер бозау. Шулай ук рудадан да (җир астындагы тимер һәм минераллар) зәкят бирелә.

## ГОШЕР

Гошер - җир үсемлекләренең зәкяте.Уңыштан уннан берен бирү. Әгәр җир акча түләп сулана торган булса егермедән берсе бирелә. Гошер бирелә торган нәрсәләр: бодай, арпа, дөге, бәрәңге, карбыз, кыяр, баклажан, печән, зәйтүн, көнҗет, бал, шикәр чигендере, җиләк-җимеш кебек ризыклар.

## ЗӘКЯТ БИРЕЛӘ ТОРГАН ТӨРКЕМНӘР

1 – Зәкят бирерлек нисапка ия булмаган фәкыйрьләр.
2 – Бер нәрсәләре дә булмаган мескеннәр.
3 – Зәкят җыючы махсус кешеләр.
4 – Мөәлләфәи-кулюб.
5 – Коллыктан котылачак кешеләр.
6 – Бурычын түли алмаган бурычлылар.
7 – Фи сәбилилләһ (Аллаһ юлында булганнар).
8 – Юлда акчасыз калганнар.

Зякәтне бу сигез төркемнең кайсысына да бирергә мөмкин, ләкин бирелүе иң фазыйләтле булган төркем – бернәрсәсе дә булмаган мескеннәр һәм Аллаһ юлында булучылар.

## ХАҖ

Исламның бишенче шарты – хаҗ. Хаҗ — зөлхиҗҗә аенда ихрамга кереп Гарәфә көне Гарәфәт тавында вакыф кылу (көтеп тору), аннан соң Кәгъбәне

тavaф кылудан гыйбарәт. Мөмкинчелеге булган һәр мөселманга гомерендә бер тапкыр хаҗга бару фарыз санала.

**ХАҖНЫҢ ФАРЫЗ ШАРТЛАРЫ**

1 – Мөселман булу.

2 – Балигъ булу.

3 – Акыллы булу.

4 – Азат булу (кол булмау).

5 – Төп ихтыяҗлары үзенә, өенә әйләнеп кайтканчы һәм гаиләсенә шул дәвердә яшәргә җитәрлек матди хәлдә булу.

6 – Ислам мәмләкәте булмаган җирдә яшәүче мөселманның хаҗның фарыз икәнлеген белүе.

**ХАҖНЫҢ ҮТӘЛҮЕНЕҢ ФАРЫЗ БУЛУ ШАРТЛАРЫ**

1 – Тәннең сәламәт булуы.

2 – Юл иминлеге булу.

3 - Әгәр хаҗга баручы кеше хатын булса, аның янында ире яисә аңа никахланырга ярамый торган берәр якыны (улы, әтисе һ.б.) булу.

4 – Ире үлгән яисә аерылган хатынның гыйддәт дәвере (толлык вакыты) тәмамланган булу.

5 – Зинданда булмау.

**ХАҖНЫҢ ДӨРЕС КЫЛУЧЫ ШАРТЛАРЫ**

1. Ихрам (Хаҗ нияте белән ихрамга керү).
2. Вакыт (Зөлхиҗҗә ае).
3. Мәкән (Кәгъбә һәм Гарәфәт).
4. Ислам (ягъни мөселман булу).

Хаҗ хакында тагын киңрәк белергә теләгәннәр безнең “Кыскача хаҗ белешмәсе” дигән әсәребезне укый алалар.

**КОРБАН**

Корбан – Аллаһы Тәгаләгә мәгънәви якынлык өчен, аның теләге буенча корбан бәйрәме көннәрендә билгеле хайванны чалу. Үзләренә фитыр садакасы йөкләтелгән кешеләргә корбан да йөкләтелә. Ягъни, нисап иясе булган һәр азат һәм мокыйм мөселман кешегә корбан чалу ваҗиб. Аллаһ ризалыгы өчен чын бер ният белән чалына торган корбаннан аккан беренче тамчы кан белән бергә, корбан хуҗасының гөнаһлары юылыр дип ачыкланган.

**КОРБАН ЧАЛУ ВАКЫТЫ**

Корбанлыкның чалыну вакыты - Корбан бәйрәменең 1, 2 һәм 3нче көннәре. Әмма көннәр хисабында хаталанудан һәм бәхәсләрдән котылу өчен, корбан чалуны бәйрәмнең өченче көненә калдырмау хәерле санала. Иң яхшысы – корбанны беренче көндә чалу.

**КОРБАН ЧАЛУ ТӘРТИБЕ**

1 – Терлекне интектермичә, кыйблага каратып яткырырга кирәк;

2 – Ул аягында чакта корбан догасы укыла;

3 - Өч тапкыр “Әллааһү әкбәр, Әллааһү әкбәр, ләә иләәһә илләллааһү үәллааһү әкбәр, Әллааһү әкбәр үә лилләәһил-хәмд” дип тәкбир әйтелә.

**Корбан чалуга ният итү:**

“Әй, Раббым! Бу тәнем сиңа каршы шулкадәр хата, гөнаһ кылды, гафу ителүем өчен бу тәнемне Сиңа корбан итәргә тиеш булам, фәкать Синең әмереңбуенча, кеше үз-үзен корбан итү хәрам булганлыктан, үзем урынына бу хайванны чаламын. Әй, Раббым! Кабул ит. Бисмилләһи, Әллааһү әкбәр!” – дип корбанлык киселә. Корбан хуҗасы корбанын үзе чалса, бу иң яхшысы. Әмма үзе булдыра алмаса, бу эшне бүтән мөселманга тапшырып, үзе ниятен укый һәм карап тору хәерлерәк.

Корбанлыкның ите өчкә бүленә: беренче өлеше үз гаиләсенә, икенче өлеше туганнары һәм дуслары белән кунак мәҗлесенә, өченче өлеше фәкыйрьләргә садака итеп бирелә.

## НӘРСӘ УЛ ГӨНАҺ ҺӘМ ТӨП ГӨНАҺЛАР

Гөнаһ – Аллаһ тарафыннан тыелган һәм хәрам дип игълан иткән бер нәрсәне эшләү.

Гөнаһ ике төрле була:

1 – Зур гөнаһлар.

2 – Кече гөнаһлар.

## Зур гөнаһлар:

1 – Аллаһыга ширек кылу.

2 – Кеше үтерү.

3 – Намуслы бер кешегә яла ягу.

4 – Зина кылу.

5 – (Мөселманнар сафында) сугыштан качу.

6 – Сихер белән шөгыльләнү, сихерләү һәм сихерләтү.

7 – Ятим малын ашау.

8 - Әни һәм әтинең шәригатькә туры килгән теләкләренә каршы килү.

9 – Ихрамда (Хәрам шәрифтә) гөнаһ эшләү.

10 – Риба эшләү.

11 – Урлашу.

12 – Исерткеч эчү.

Югарыда саналган 12 гөнаһларга тиң дәрәҗәдә начар эшләр күп эшләнсә, алар да зур гөнаһ булып санала. Дәвамлы эшләнгән кечкенә гөнаһлар да зур гөнаһка әверелә.

## ГӨНАҺЛАРДАН КОТЫЛУ ЧАРАЛАРЫ

### Тәүбә һәм истигъфар

Матди пычракны сабын һәм су белән чистартып булган кебек, күңелне каралткан, кешене җәһәннәмгә юнәлткән мәгънәви пычрак һәм авыруларны да бетерә торган чаралар бар: тәүбә, гафу сорау, үкенү һәм күздән яшь агызу. Төп

табигате белән кеше гаять гүзәл итеп яратылган. Пәйгамбәр әфәндебез кеше күңеле асылда көзге кебек пакь булуын бәян итә. Кеше бу илаһи күңел пакьлеген каралта, күңелен нурга тутырасы урында гыйсьян (фетнә) һәм тугъян (ярсыну) нәтиҗәсендә күңеленә шөбһә, вәсвәсә, фетнә, бозыклык, ачу тоту, үч алу һәм хөсет кебек бозык хисләр тутырса, куркыныч бер рухи авыруга дучар була. Бу авырудан дәваланмаса, Аллаһ сакласын, бара торган җире җәһәннәм булыр. Бу авырулардан котылу чарасы – тәүбә һәм истигъфар кылып (Аллаһтан гафу сорау), күңеленнән начар ниятләрне һәм хисләрне чыгарып, үкенү, күз яшьләрен түгү.

Каткан күңелләрегезне Аллаһыны уйлап, Аны зикер итеп йомшартыгыз, каралган хисләрегезне тәүбә-истигъфар һәм үкенү яшьләре белән пакълагыз! Бигрәктә төн һәм сәһәр вакытларында намаз укып, салават әйтеп һәм догалар кылып, Аллаһының мәгъфирәтенә һәм ризалыгына ирешүне теләргә тиешлебез.

**ӨМЕТСЕЗЛЕК ДӨРЕС ТҮГЕЛ**

Имин булу да, өметсезләнү дә дөрес түгел – көферлек булып санала. Ягъни, “Мин шулкадәр изгелекләр эшләдем, инде җәннәтле булдым” - дип ышану һәм үзен Аллһының ачуыннан имин дип күрү, яки “Мин шул кадәр гөнаһлар эшләдем инде, миңа җәһәннәмнән котылу юлы юк”, - дип өметсезлеккә төшү көферлек. Пәйгамбәребез: “Мөэмин курку белән өмет арасын өзмәгән хәлдә, үзенең җитешсезлекләрен белеп, курку хисеннән дә азат булмаячак”, — дигән. Әгәр Кыямәттә бер кешенең җәннәтле икәнен әйтсәләр: “Мин шул кеше микән?” — дип гаҗәпләнгән кебек, берәү тәмуглы булса: “Мин микән”, — дип гаҗәпләнер.

**ТӘҮБӘНЕҢ КАБУЛ БУЛУ ШАРТЛАРЫ**

1 – Кеше кылган гөнаһының зарарын таныргa тиеш, чөнки гөнаһ кешене дөнья һәм ахирәт бәхетеннән ераклаштырыр.

2 – Кылган гөнаһлары өчен күңелендә газап һәм үкенү булырга тиеш.

3 – Моннан соң шундый гөнаһларны кылмаска дигән ныклы карарга килергә тиеш.

Эшләгән гөнаһ урынына шул ук вакытта изгелек кылу, явызлыгы тигән кешеләр белән бәхилләшү, ризалашу һәм намаз укып истигъфар кылу тиешле. Иң зур истигъфар — тәсбих намазы.

Күңел игътибарсыз булып, гөнаһ эшләргә теләп торган хәлдә, тел белән генә тәүбә-истигъфар кылуның файдасы юк.

**Зур истигъфар догалары**

Сүбхәна-ллааһи үә бихәмдиһи сүбхәна-ллааһил-газыыйм, әстәгъфиру-ллааһәл-газыыймә үә әтүүбү иләйик.

Бигрәк тә зур гөнаһлар кылган кешеләр түбәндәге доганы кат-кат кабатларга тиешләр: “Әллааһүммә мәгъфиратүкә әүсәг мин зүнүүбии үә рахмәтүкә әрҗәә гыйндии мин гамәли”.

**ҖИҺАД**

Җиһад – Аллаһының динен тарату өчен эшләнгән актив эшләр. Мөселманнар көндәлек гыйбадәтләрен һәм дини вазифаларын үтәү белән бергә җиһадта да катнашырга тиешләр.

Бидгать (дингә яңалык кертү) һәм дингә яла-ягучылар белән көрәшү, иманны һәм әхлакны корыта торган иҗтимагый күренешләрне бетерергә тырышу һәм малыңны да, бөтен барлыгыңны да кызганмыйча бу юлга сарыф итү һәр мөселманга йөкләтелгән вазифа.

Җиһад Аллаһ сүзен тарату өчен эшләнә. Ягъни Аллаһы Тәгаләнең нурын һәр җиргә җиткерү, бу нур белән нурланганнарның иманын көфердән саклау, бу нур

ирешмәгән күңелләргә шул нурны ирештерү – җиһадның максаты шул. Чын белән ялган төрле шәкел һәм сурәтләрдә, төрле рәвештә һәрвакыт үзара көрәштә булганлыктан, җиһад та Кыяматкә кадәр барыр. Бу көрәштә һәр мөселман хаклык ягында булып, хаклыкның җиңүе, көфернең һәм кяферләрнең җиңелүе өчен бөтен көче белән омтылырга һәм тырышырга, өлеш кертергә тиеш. Чын мөселман кеше, бер әхлаксызлык күрсә, аны эшләмәс өчен тырышырга тиеш. Бу җиһадның заһири (күренә торган) ягы.

Шулай ук җиһадның батыни (күренмәгән) ягы бар, бу — үз күңелеңдәге нәфескә каршы көрәшү. Бу җиһадларның иң олысы. Пәйгамбәребез җиһадның әһәмиятен кайбер мөбарәк хәдисләре белән белдергән: “Бер кеше Аллаһ юлында җиһад кылмыйча һәм күңеленнән булса да җиһад хисләрен кичермичә үлеп китсә, ул Бер монафикъ бәндәдән саналып үлгән була”. “Җиһад хатыннарга да һәм ирләргә дә фарыз”. “Җиһадтан качкан үзен мөселман димәсен”. “Арагыздан берәү бер тискәре нәрсә күрсә, аны куллары белән төзәтсен. Кулыннан килмәсә, теле белән төзәтергә омтылсын. Теленнән дә килмәсә, күңеле белән каршы булсын”.

## МӨСЕЛМАННАРНЫҢ ҖӘМГЫЯТЬТӘГЕ ВАЗИФАЛАРЫ

### 1-Күрше хакы

Гаиләбездән һәм туганнарыбыздан соң безгә иң якын булган кешеләр — күршеләребез. Күрше хакын бик ныклы рәвештә саклап, кулыбыз,телебез һәм башка хәрәкәтләребез белән аларны рәнҗетмәскә тиешлебез.Чөнки Пәйгамбәр Әфәндебез: “Миңа Җәбраил фәрештә күрше хакы турында шундый нәрсәләр әйтте, мин күрше күршенең малына варис булыр инде дигән фикергә килдем”, – дигән.

2-Мосафир хакы

Пәйгамбәр Әфәндебез бер хәдисендә: “Кем дә кем Аллаһыга һәм Ахирәт көненә иман китерсә, мосафирны да хөрмәт итсен”, - дип боерган. Бигрәк тә мосафир килгән җирендә юклыкка һәм тарлыкка сәбәп булмыйча, киресенчә, бәракәт һәм муллыкка сәбәп булачагын ачыклап: “Мосафир килгән өйгә ун өлеш белән килер, берсен ашаса тугызны калдырыр” - дип әйткән.

### 3-Башка иҗтимагый вазифаларыбыз

Башкаларның хакларын тану һәм берәүгә дә зарар китермәү. Намус һәм мал-мөлкәт хакларына игътибар бирү. Яхшылык эшләү, берәүгә дә көнчелек кылмау. Башкаларны кимсетмәү, алардан көлмәү. Башкаларның гаепләрен уртага чыгармау.

**КАЙБЕР ДОГАЛАР**

**Иртән, өйдән чыкканда укыла:**

Бисмилләәһи, тәүәккәлтү галә-ллааһи ләә хәүлә үә ләә куввәтә илләә билләәһил-галийил-газыыйм.

**Иртән, бигрәк тә урамда һәм базарда укыла:**

Ләә иләәһә иллә-ллааһү үәхдәһүү ләә шәриикә ләһ. Ләһүл-мүлкү үә ләһүл-хәмдү йүхйии үә йүмиит. Үә һүә хәййүл-ләә йәмүүт. Бийәдиһил-хайир, үә һүә галәә күлли шәй ин кадиир.

Мәгънәсе**:** “Аллаһыдан башка һичбер илаһ юк. Ул гына бар. Аның тиңдәше, уртагы юк. Ул үтерер һәм терелтер. Ул тере һәм үлмәс. Һәр хәерлелек Аның кодрәтендә. Аның һәрнәрсәгә көче җитәр”.

Шушы доганы һәр иртәдә унбер тапкыр, хәтта йөргән вакытларда да – юлларда, урамнарда, һәр җирдә укырга кирәк. Пәйгамбәр Әфәндебез: “Бу доганы укыганнарга Аллаһы Тәгалә миллионлаган савап бирер, миллионлаган гөнаһын юар, миллионлаган дәрәҗәләргә күтәрер”,— дип боерган. Укыган мөэминнең иманы чистарыр. Бу дога Рәсүлебезнең шәфәгате, ярдәме өчен иң бөек сәбәп.

Сүбхәна-ллааһи мил-әл миизәәни үә мүнтәһәл-гыйльми үә мәбләгар-ризаа үә зинәтәл-гарш.

Мәгънәсе**:** “Аллаһының мизаны (үлчәве) тулганчы, гыйлемнең чиксезлеге кадәр, ризалыгына ирешкәнче һәм Гарешенең авырлыгы кадәр тәсбих итәргә әзермен”.

Бу доганы һәр иртән, һәр кичен өч мәртәбә укырга кирәк. Бу дога гомернең озын һәм бәхетле булуына, иман белән вафат булуга, кабер газабыннан котылуга, сират күпереннән үтүгә һәм җәннәткә лаек булуга бер чара.

**Бәдрәфкә кергәндә укыла торган дога:**

Әгуузү билләәһи минәл-хүбси үәл-хәбәәис.

**Бәдрәфтән чыккач укыла торган дога:**

Әлхәмдү лилләәһил-ләзии әзһәбә ганнил-әзәә үә гаафәәни мин зәәлик.

Мәгънәсе**:** “Җәфа биргән нәрсәләрдән мине коткарып пакьләүче Аллаһы Тәгаләгә мактау булсын”.

Бәдрәфтән чыкканда укыла торган бу доганы даими укучылар бәвел һәм тәһарәт юлларында авырлык күрмәсләр. Бәдрәфкә һәм мунчага сул аяк белән керәләр, уң аяк белән чыгалар. Өйгә һәм мәчеткә исә уң аяк белән кереп, сул аяк белән чыгарга кирәк.

**Куркыныч төш күргәч укыла торган дога:**

Куркыныч төш күргән кеше ул төшнең тормышка ашмавы өчен, “Һүәллааһүл-ләзии ...” не укыр һәм бер тапкыр “Фатиха”, унбер тапкыр “Ихлас” сүрәсен укып, Пәйгамбәребезнең рухына багышлап: “Әй Раббым! Әгәр шушы күргән төшем хәерле булса, хәерлеген дәвамлы кыл, әгәр яман төш булса, хәерлегә әвереледер. Хәерлесе безгә, яманы дошманнарга булсын”, - дип дога кылыр.

Күңелле төш булса да, ул тиз эшләнсен өчен, бер тапкыр “Фатиха”, 11 тапкыр “Ихлас” сүрәсен укып, Рәсүлулла әфәндебезгә багышларга кирәк.

**Аллаһының ярдәме һәм рөхсәте белән бай булу өчен иртә-кич түбәндәге доганы өчәр тапкыр укырга кирәк:**

Йәә хәмиидәл-фигали зәлмәнни галәә җәмииги халкыййһи билүтфиһ.

Мәгънәсе: “Әй барча әйтелгән мактауларга лаек булган һәм игелеге белән барча мәхлукларга ризык биреп торучы (Раббым!)”.

**Кичен яткканда укыла торган дога:**

Әллааһүммә бисмикә әмүүтү үә әхйәә.

Мәгънәсе: “Әй Аллаһым! Исемең белән үлеп, исемең белән терелергә язсын!”

**Иртән торганда укыла торган дога:**

Әлхәмдү лилләәһи-лләзии әхйәәнә бәгдә мәә әмәтәнәә үә иләйһил-бәгсү үән-нүшүүр.

Мәгънәсе: “Мактау булсын ул Аллаһы Тәгаләгә. Үлгәннән соң да безне терелтер. Үлгәннән соң Мәхшәргә терелеп бару Аңа”.

**Һәрвакыт зур файда китерә торган догалар:**

**Әллааһүммә әринәл-хакка хаккаү-үәрзукнәл-иттибәга иләйһи үә әринәл-бәәтыйлә бәәтыйлән үәрзукнәл-иҗтинәәбә ганһ.**

Мәгънәсе: “Әй Аллаһым! Безгә хакны хак итеп күрсәт һәм безне хакка буйсынулы кыл. Ялгышны ялгыш итеп күрсәт һәм безне аннан өстенрәк, читтәрәк кыл!”

**Әллааһүммә йәә мүкаллибәл-кулүүб, сәббит калбии галәә диииникә үә таагатикәл-исләәм.**

Мәгънәсе: “Әй күңелләрне төрлечә бора алучы Раббым! Минем күңелемне дингә һәм Исламга итәгать рухында карарлаштыр!”

**Бәлагә очраган берәүне күргәндә (ул бәланең үзеңә килмәвен теләп) укыла торган дога:**

Әлхәмдү лилләәһил-ләзии гаафәәнии мим-мәбтәләәкә биһии үә фәззаләнии галәә кәсиирим миммән халәка тәфзыйләә.

Мәгънәсе: “Син дучар булган бу хәлдән миңа ерак торырга мөмкинлек биргән өчен һәм мине үзе яраткан бик күп кешеләрдән изгерәк кылып, өстенлек биргән өчен Аллаһыга хәмед (мактау) булсын”.

Бу дөньяда башка кешеләрдән көлеп, аларны гаепләргә ашыгырга ярамый. Чөнки көлке үзеңә иярә килер диләр.

## Иртәнге намазның сөннәте белән фарызы арасында укылачак дога

Йәә хаййү, йәә каййүүм, йәә зәл-җәләәли үәл-икраам. Әс-әлүкә эн түхйийә калбии бинуури мәгърифәтикә әбәдәә. Йәә Әллааһү, йәә Әллааһү, йәә Әллааһ, йәә бәдиигас-сәмәәүәәти үәл-ард.

Мәгънәсе**:** "Әй һәрвакыт бар һәм уяу булучы Аллаһым! Әй Җәләл һәм Кәрам иясе булган Раббым! Әй, җирне-күкне тиңсез гүзәллек белән яратучы (бар итүче) Аллаһым! Әй Аллаһым, әй Аллаһым, әй Аллаһым! Күңелемне мәңгелек мәгърифәт нуры белән яктыртсаң иде".

Бу доганы даими укыган кешеләрнең иман белән вафат булулары өмет ителер.

**Иртән иртүк торуның гүзәллекләре хакында**

Барча ризык иртән өләшелгән булганга, бу вакытны йокыда булганнарның ризыклары да ким булыр, өйдәге бар кешене – олысын-кечесен иртән иртүк уятырга кирәк. Бик теләсәләр, кояш күтәрелгәч, йоклап алырлар. Догаларны мөмкин булса, өчәр тапкыр укырга кирәк, чөнки өчәр тапкыр уку доганың кабул булуына сәбәп була.

# САЛАВАТ ШӘРИФӘЛӘР

## САЛӘТҮ-МӨНҖИЯ

Әллааһүмә салли галәә сәйидинәә Мүхәммәдин үә галәә әәли сәйидинәә Мүхәммәд саләәтән түнҗиинәә биһәә мин җәмигыйл-әһүәәли үәл-әәфәәт. Үә тәкзый ләнәә биһәә җәмиигал-хааҗәәт. Үә түтаһһирунәә биһәә мин җәмигыйс-сәйиәәт үә тәрфәгунәә биһәә гыйндәкә эглəд-дәраҗәәт. Үә түбәллигунәә биһәә эксал-гаайәәт. Мин җәмигыйл-хайрати фил-хайәти үә бәгдәл-мәмәәт. Иннәкә галәә күлли шәй иң кадиир.

Мәгънәсе**:** "Әй Раббым! Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһис-сәламгә һәм аның нәселенә, токымнарына шундый мәрхәмәтләр бүләк ит, шуның белән безне барча курку, дәһшәт һәм афәтләрдән коткар. Барча ихтыяҗларыбызны канәгатьләндер. Барча гөнаһлардан арындыр. Үз яныңдагы иң югары дәрәҗәгә күтәр. Яшәвебездә дә, үлемебездә дә бөтен игелекләрнең иң зур тәңгәлләренә ирештер. Синең чыннан да һәр нәрсәгә көчең, кодрәтең җитә".

## САЛӘТҮ-ФӘТХЫЙӘ

Әллааһүммә салли үә сәллим үә бәәрик галәә сәйидинәә Мүхәмәдинил-фәәтихи лимәә үгълика үәл-хаатими лимәә сәбәкъ. Нәәсирил-хакки бил-хаккый үәл-һәәдии иләә сыйраатикәл-мүстәкыйм үә галәә әәлиһии хакка кадриһии вә микъдәәриһил-газыйм.

Мәгънәсе**:** Әй Раббым! Игелек ишекләрен ачу өчен килеп-киткән пәйгамбәрләрнең иң соңгысы, тугрылыкта һәм гаделлектә Аллаһы Тәгаләнең ярдәмчесе булган һәм тугрылык юлына өндәгән Мөхәммәд галәйһис-сәламнең

үзенә һәм гаиләсенә, аның югары дәрәҗәсе һәм мәртәбәсе хөрмәтенә, безгә мәрхәмәт ит, сәламәтлек һәм бәракәт бүләк ит".

**САЛӘТҮ –НӘРИЯ**

Әллааһүммә салли салəәтән кәәмиләтән үә сәллим сәләәмән тәәммән, галәә сәййидинәә Мүхәммәдинил-ләзии тәнхаллү биһил-гукаду үә тәнфәрижү биһил-күрабү үә түкзаа биһил-хаүәәижү үә түнәәлү биһир-рагааибү үә хүснүл-хаүәәтими үә хүснүл-хаүәәтим, үә йүстәскал-гамәәмү биүәҗһиһил-кәриим үә галәә әәлиһии үә сахбиһии фии күлли ләмхатин үә нәфәсин бигадәди күлли мәглүүмил-ләк.

Мәгънәсе**:** "Әй, Аллаһым! Аның үзе хөрмәтенә төеннәр чишелгән, кайгы-хәсрәтләр бетерелгән, ихтыяҗ һәм теләкләр бетерелгән, яхшы нәтиҗәләргә ирештерә торган киң юллар ачылган, иксез-чиксез юмартлык иясе, абруе хөрмәтенә, болытлар елаган Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа галәйһис-сәлам һәм аның затына, токымына һәм сәхабәләренә, дөньядагы һәр караштa һәм һәр сулышта камил мәрхәмәт һәм тулы сәламәтлек бүләк ит".

Мөхәммәд салләллаһү галәйһи үә сәлләмгә һәркөнне салават әйтергә кирәк. Бигрәк тә Саләтү-мөнҗия, Саләтү-нәрия һәм Саләтү-фәтхияләрне күп тапкырлар уку бик саваплы. Һәрнинди кыенлыклар һәм тарлыклар вакытында, шуларны хәтем итеп дога кылынса, теләкләр Аллаһы Тәгаләгә ирешер һәм кабул булыр. Саләтү-мөнҗиянең тулы хәтеме 1000, Саләтү-нәриянең тулы хәтеме исә 4444 тапкыр.

**ХӘТЕМ ДОГАСЫ**

**УТЫЗ ИКЕ ФАРЫЗ**

Намаз фарызлары - унике
Иман шартлары - алты
Ислам шартлары - биш
Тәһарәт фарызлары - дүрт
Госел фарызлары - өч
Тәяммум фарызлары - ике
Барлыгы утыз ике

**НАМАЗ ФАРЫЗЛАРЫ**

**Тышкы фарызлар:**

1 – Бүлендекләрдән арыну (тәһарәт яки госел алу);
2 – Кер-пычрактан арыну;
3 – Гаурәт әгъзаларын, гаурәт төшләрне каплау;
4 – Кыйбла тарафына юнәлү;
5 – Намазны вакытында уку;
6 – Ният итү.

**Эчке фарызлар (әркәннәр):**

1 – Ифтитәх тәкбирен әйтү;

2 – Кыям;
3 – Кыйраәт;
4 – Рөкугъ;
5 – Сәҗдә;
6 – Кәгъдәи-ахирә.

**Иман шартлары:**

1 – Аллаһының барлыгына һәм берлегенә инану;
2 – Аллаһының фәрештәләренә инану;
3 – Аллаһының китапларына инану;
4 – Аллаһының пәйгамбәрләренә инану;
5 – Ахирәт (Кыямәт) көненә инану;
6 – Тәкъдиргә ягъни, яхшылыкның һәм начарлыкның бер Аллаһы Тәгаләдән булуына инану.

**ИСЛАМНЫҢ ШАРТЛАРЫ**

1 – Шәһадәт китерү;
2 – Намаз уку;
3 – Ураза тоту;
4 – Зәкят бирү;
5 – Хаҗга бару.

**ТӘҺАРӘТНЕҢ ФАРЫЗЛАРЫ**

1 – Йөзне юу;
2 – Кулларны терсәкләр белән бергә юу;
3 – Башның дүрттән Бер өлешен мәсех кылу (сулатып сөртү);
4 – Аякларны юу.

**ГОСЕЛНЕҢ ФАРЫЗЛАРЫ**

1 – Авызны чайкау;
2 – Борынны чайкау;
3 – Бөтен тәнне юу.

**ТӘЯММУМ ФАРЫЗЛАРЫ**

1 – Ният;
2 – Ике тапкыр сугу һәм мәсех кылу;

**ИЛЛЕ ДҮРТ ФАРЫЗ**

1 – Аллаһыны һәрвакыт зикер итү (истә тоту). Зикер: телдән яки күңелдән эшләнә. Күңелдән булса зикри-хафи (яшерен зикер) диелә. Коръән Кәрим, кәлимәи-тәүхид, тәһлил, салават шәрифә һәм догалар уку исә тел белән кылынган зикерләрдән саналалар;
2 – Хәләлдән килгән кием кию;
3 – Тәһарәт алу;
4 – Биш вакыт намаз уку;
5 – Пычрактан арыну; җөнүб булганнан соң госел алу;
6 - Ризык өчен Аллаһыга тәвәккүл итү;

7 – Хәләлдән ашап-эчү;
8 – Аллаһ биргән ризыкка канәгать булу;
9 – Тәвәккәл кылу;
10 – Аллаһының язганына риза булу;
11 – Нигмәтенә шөкер итү;
12 – Бәла-казага сабыр итү;
13 – Гөнаһлардан тәүбә итү;
14 – Гыйбадәтләрне ихласлык белән үтәү;
15 – Шайтанны дошман дип белү;
16 – Коръән сүзен дәлил дип тану;
17 – Үлемгә хәзерләнеп тору;
18 – Яхшылыкка өндәү, начарлыктан тыю;
19 – Гайбәттән качу һәм ямьсез сүзләрне тыңламау;
20 - Әти-әнигә игелекле һәм итәгатьле булу;
21 – Туган-тумачалар белән аралашу;
22 - Әманәткә хыянәт итмәү;
23 – Дингә каршы мәзәкләрне кире кагу;
24 – Аллаһ һәм Аның илчесенә ышану;
25 – Гөнаһтан качып Аллаһыга сыену;
26 – Аллаһ өчен сөю һәм Аллаһ өчен сөймәү;
27 – Һәр нәрсәдән гыйбрәт алу (һәр нәрсә турында тирән уйлау);
28 – Аллаһы Тәгаләнең кодрәтен, бөеклеге һәм кешенең яратылуы, яшәү мәгънәсе турында уйлау;
29 – Гыйлемгә омтылып, гыйлем өйрәнү;
30 – Башкалар хакында начар уйлаудан саклану;
31 – Кешедән көлмәү, башкаларны мыскылламау;
32 – Хәрамнан ерак тору;
33 – Һәрвакыт тугры булу;
34 – Тыйнаксызлыктан һәм азгынлыктан саклану;
35 – Сихердән һәм сихерчелектән саклану;
36 – Үлчәүне төзек тоту (сәүдәдә алдашмау);
37 – Аллаһының газабыннан курку;
38 – Бер көнлек ашамлыгы булмаган кешегә садака бирү;
39 – Аллаһының рәхмәтеннән өмет өзмәү;
40 – Нәфес котыртуыннан саклану;
41 – Исерткеч эчүдән саклану;
42 – Аллаһ һәм мөэминнәр хакында начар уй йөртүдән саклану;
43 – Зәкят бирү һәм мал белән җиһадка катнашу;
44 – Хәез һәм нифас вакытында хатыны белән якынлык кылудан саклану;
45 – Гөнаһлардан һәм явызлыктан күңелеңне ерак тоту;
46 – Ятим малын хаксыз ашаудан саклану;

47 – Тәкәбберлектән саклану;
48 – Гомосексуализм һәм зинадан саклану;
49 – Биш вакыт намазны калдырмаска омтылу;
50 – Золым кылып халык малын ашаудан саклану;
51 – Аллаһыга ширек кушудан саклану;
52 – Риядан (үзен күрсәтүдән) саклану;
53 – Ялган сөйләүдән һәм ялган ант бирүдән ерак тору;
54 – Биргән садаканы битенә какмау.

## КАЙБЕР ЕВРОПА ФӘЛСӘФӘЧЕЛӘРЕНЕҢ ИСЛАМ ДИНЕ ТУРЫНДАГЫ ФИКЕРЛӘРЕ

“Исламият тар мәгънәдә бер дин, ягъни кешеләрнең нормаль вөжданына нигез булган хосусый ышану һәм гыйбадәтләрдән торган бер метафизик система гына түгел, ә шулар өстенә, бөтен бер дөньяга караш системасы һәм кешенең (шәхеснең) һәм җәмгыятьнең тормышын тәртиптә тота торган яшәеш ысулы”.

**“Way of Life”** журналы.

“Исламият тормышның барлык очракларына кагыйдәләр әзерләгән. Ул һәр яктан җитеш кануннар җыентыгы. Һәртөрле чисталыктан, пакьлектән алып, сәүдәдә намуслыкка кадәр хөкем йөртеп, хәтта сакал-мыекны ничек кисү мәсъәләсенә кадәр мәслихәтләр һәм нәсихәтләр бирә. Исламның барлык кануннары рациональ һәм әһәмиятьле.

**Everyman`s enyclopaedia**
**“**Ислам матдәсе**”.**

Мәшһүр немец шагыйре Гёте Коръән Кәрим турында болай әйтә: “Коръәннең әзәлдән булу-булмавы турында минем шөбһәм юк. Мөселман буларак, миңа фарыз булган кебек китапларның китабы булуына иман китерәм”.

**БИСМАРК ӘЙТӘ:** “...Бөтен күктән индрелгән китапларны тикшереп берсендә дә хикмәтле эш тапмадым. Бу кануннар бер җәмгыятнең түгел, бер өй халкының да бәхетен җиренә җиткерүдән бик ерак тора. Ләкин мөхәммәдиләрнең Коръәне бу яктан иркен... Мин Коръәннең һәр сүзендә хикмәтләр күрдем... Әй Мөхәммәд, синең белән бер вакытта яшәмәгәнемә үкенәм. Мөгаллиме һәм таратучысы син булсаң да, бу китап синеке түгел. Ул Аллаһныкы. Аның илаһи булуын инкарь итү, барлык гыйлемнәрнең нигезсез икәнен алга сөрү кадәр көлкеле эш булыр. Кешелек синең төсле чиксез бер кодрәтне бер күргән, моннан соң күрмәс. Мин сиңа мәхәббәт итеп, хөрмәт белән баш иям”.

## МӨСЕЛМАН БАЛАЛАРЫ ӨЧЕН КАЙБЕР ДИНИ СОРАУЛАР ҺӘМ ҖАВАПЛАР

СОРАУ: Син мөселманмы?

ҖАВАП: Әлхәмдүлилләһ, мөселманмын.

СОРАУ: Мөселман нәрсәне аңлата?

ҖАВАП: Аллаһыны бар һәм бер дип белү. Коръән Кәримне һәм Мөхәммәд галәйһис-сәламне тану.

СОРАУ: Син кайчаннан бирле мөселман?

ҖАВАП: “Бәла” дигән заманнан бирле мөселманмын.

СОРАУ: Нәрсә ул бәла заманы?

ҖАВАП: Бәла – ул мисак заманы. Ягъни Аллаһы Тәгалә рухларыбызны яратканда, аларга “Әләстү бирабббикүм”, ягъни: “Мин сезнең Раббыгыз түгелме? ” – дип сораган һәм рухларыбыз: “Бәла” (әйе, Син безнең Раббыбыз), - дип җавап биргәннәр.

СОРАУ: Раббың кем?

ҖАВАП: Аллаһы Тәгалә.

СОРАУ: Сине кем яратты, бар итте?

ҖАВАП: Аллаһы Тәгалә.

СОРАУ: Син кемнең колы?

ҖАВАП: Аллаһының колымын.

СОРАУ: Аллаһ ничә дип әйтүчеләргә нәрсә әйтерсең?

ҖАВАП: Аллаһ бер дип әйтермен.

СОРАУ: Аллаһының берлегенә дәлилең ни?

ҖАВАП: “Ихлас” сүрәсенең беренче аяте.

СОРАУ: Аның мәгънәсе ни?

ҖАВАП: “Син әйт өммәтеңә, әй яратканым, Аллаһ бер генә” дигән мәгънәдә.

СОРАУ: Аллаһының барлыгына акыллы дәлилең ни?

ҖАВАП: Бу галәмнең барлыгы һәм галәмдәге төзеклекнең, тәртипнең дәвам итүе.

СОРАУ: Аллаһының кемлеге, ниндилеге хакында уйларга ярыймы?

ҖАВАП: Бу турыда уйларга ярамый. Чөнки акыл Аллаһының затын аңлата алмый. Әммә Аллаһының сыйфатлары хакында уйланырга ярый һәм кирәк.

СОРАУ: Нәрсә ул йәис иманы?

ҖАВАП: Фиргавен шикелле үлгән чакта иман китерү.

СОРАУ: Бу игътибарга лаеклы иманмы?

ҖАВАП: Түгел.

СОРАУ: Нәрсә ул йәис тәүбәсе?

ҖАВАП: Иманы һәм гамәле булган кешенең үлгән чактагы тәүбәсе.

СОРАУ: Мондый тәүбә игътибарга лаекмы?

ҖАВАП: Лаеклы.

СОРАУ: Динең кайсы дин?

ҖАВАП: Ислам дине.
СОРАУ: Китабың кайсы китап?
ҖАВАП: Коръән Кәрим.
СОРАУ: Кыйблаң кайсы як?
ҖАВАП: Кәгъбәи-Мөгаззәмә.
СОРАУ: Син кемнең нәселеннән?
ҖАВАП: Адәм галәйһиссәләм нәселеннән.
СОРАУ: Син кемнең өммәтеннән?
ҖАВАП: Мөхәммәд галәйһис-сәлам өмәтеннән.
СОРАУ: Пәйгамбәребез кайда туган һәм хәзер кайда?
ҖАВАП: Мәккәдә туган. Илле яшьләрендә Мәдинәгә һиҗрәт кылган. Бүгенге көндә шундагы “Раузаи-Мөтаһһәра”да.
СОРАУ: Пәйгамбәребезнең ничә исеме бар?
ҖАВАП: Гүзәл исемнәре бик күп. Әмма дүртесен белү һәркемгә лязем: Мөхәммәд, Мостафа, Әхмәд, Мәхмүд.
СОРАУ: Пәйгамбәребезнең иң еш кулланылган исеме кайсы?
ҖАВАП: Хәзрәти Мөхәммәд Мостафа салләллаһү галәйһи вә сәлләм.
СОРАУ: Пәйгамбәребезнең әтисенең исеме ничек?
ҖАВАП: Габдулла.
СОРАУ: Әнисенең исеме ничек?
ҖАВАП: Әминә.
СОРАУ: Сөт әнисенең исеме ничек?
ҖАВАП: Хәлимә хатын.
СОРАУ: Кендек әбисенең исеме ничек?
ҖАВАП: Шифа-хатын.
СОРАУ: Дәү әтисенең исеме ничек?
ҖАВАП: Габделмотталиб.
СОРАУ: Пәйгамбәребез ничә яшендә чакта аңа пәйгамбәрлек әмере килә?
ҖАВАП: Кырык яшендә чакта пәйгамбәрлек әмере килгән.
СОРАУ: Ул ничә ел пәйгамбәрлек итте?
ҖАВАП: Егерме өч ел пәйгамбәрлек итте.
СОРАУ: Фани дөньядан ул ничә яшендә китте?
ҖАВАП: Алтмыш өч яшендә китте.
СОРАУ: Пәйгамбәребезнең ничә кызы бар иде?
ҖАВАП: Дүрт кызы бар иде: 1 – Зәйнәб, 2 – Рокыя, 3 - Өмме Күлсүм, 4 – Фатыйма (разыяллаһү ганһүннә).
СОРАУ: Хәзрәти Пәйгамбәребезнең ничә углы бар иде?
ҖАВАП: Өч углы бар иде: 1 – Ибраһим, 2 – Касим, 3 – Габдулла.
СОРАУ: Хатыннарын санап-әйтеп күрсәтә аласыңмы?
ҖАВАП: Күрсәтә алам: 1 - Хәзрәти Хәдичә, 2 – Хәзрәти Сәүдә, 3 - Хәзрәти Гайшә, 4 - Хәзрәти Хафса, 5 - Хәзрәти Зәйнәб бинтү Хөзәймә, 6 -

Хәзрәти Өмме Сәләмә, 7 - Хәзрәти Зәйнәб бинтү Җәхеш, 8 - Хәзрәти Җөвәйрия, 9 - Әбү Суфьянның кызы Хәзрәти Өмме Хәбибә, 10 - Хәзрәти Сафийә, 11 - Хәзрәти Мәймүнә, 12 - Хәзрәти Мәрия (разыяллаһү ганһүннә) исемле аналарыбыз. Болардан Хәзрәти Хәдичә (разыяллаһү ганһә) Пәйгамбәребезнең тәүге хатыны булып, үзеннән унбиш яшькә олырак иде. Ул Пәйгамбәребез белән егерме биш ел гомер кичерде.

СОРАУ: Пәйгамбәребезнең илле өч яшеннән соң да өйләнүләренең нинди сәбәп һәм хикмәтләре бар?

ҖАВАП: Пәйгамбәребезнең гарәп кабиләләрен Исламияткә багламак һәм бигрәк тә хатын-кызга бәйләнышлы хөкемнәрне хатын-кызлар аркылы җәю, шулай ук кайберләрен ярлылыктан коткару, кайберләренең гыйффәт һәм намусларын саклау нияте белән өйләнгән. Иң төп максаты – мөселманлыкны хатыннар аркылы тарату һәм ныгыту.

СОРАУ: Пәйгамбәребезнең иң соңгы вафат булган хатыны кем?

ҖАВАП: Хәзрәти Гайшә разыяллаһү ганһә.

СОРАУ: Килгән һәм киләчәк кешеләрнең иң бөеге кем?

ҖАВАП: Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһү галәйһи вә сәлләм.

СОРАУ: Пәйгамбәребезнең ничә оныгы бар?

ҖАВАП: Ике оныгы бар: 1- Хәсән, 2 – Хөсәен.

СОРАУ: Болар кемнең балалары?

ҖАВАП: Хәзрәти Гали һәм Хәзрәти Фатыйма (р.а.) балалары.

СОРАУ: Пәйгамбәр дип кемне атыйлар?

ҖАВАП: Илаһи хөкемнәрне кешеләргә җиткерү һәм аңлату өчен Аллаһ тарафыннан йөкләтелгән затны пәйгамбәр дип атыйлар.

СОРАУ: Аллаһ тарафыннан барлык мәхлукларга җибәрелгән пәйгамбәрләрнең саны күпме?

ҖАВАП: Пәйгамбәребездән килгән бер риваять буенча, йөз егерме дүрт мең, шундый ук икенче бер риватъ буенча, ике йөз егерме дүрт мең.

СОРАУ: Коръән Кәримдә ничә пәйгамбәр искә алына?

ҖАВАП: Егерме сигез.

СОРАУ: Исемнәре белән әйтеп бирә аласыңмы?

ҖАВАП: Әйтеп бирә алам: Адәм, Идрис, Нух, Һуд, Салих, Ибраһим, Лут, Исмәгыйль, Исхак, Якуб, Йосыф, Әюб, Шөгаеб, Муса, Һарун, Давыт, Сөләйман, Юныс, Ильяс, Әльяса, Зөлкифел, Зәкәрия, Яхъя, Гайсә, Гозәер, Локман, Зөлкарнәен һәм хәзрәти Мөхәммәд (салаватүллаһи галәә нәбийинә үә галәйһим әҗмәгыйн). Гозәер, Локман һәм Зөлкарнәен (галәйһимүс-сәлам) кайберләре исә вәли (әүлия) дип саныйлар.

СОРАУ: Хәзрәти Мөхәммәд Мостафа галәйһис-сәлам ничәнче елда туып, ничәнче елда вафат булган?

ҖАВАП: 571 нче елда рабигел-әүвәл аеның уникенче көне – дүшәмбе көн туып, 632 нче елда рабигел-әүвәл аеның уникесендә вафат булды.

СОРАУ: Пәйгамбәребез галәйһис-сәлам Мәккә Мөкәррәмәдән Мәдинә Мөнәүвәрәгә ничәнче елда һиҗрәт итте?

ҖАВАП: Милади буенча 622 нче елда һиҗрәт итте. Һиҗрәт кылу вакыты мөселманнарның яңа тарих исәбенең төп ноктасы (һиҗри еллар исәбе шуннан башлана).

СОРАУ: Фәрештә нәрсә ул?

ҖАВАП: Аллаһының нурдан яраткан һәм үзләре теләсә нинди рәвешкә-шәкелгә керә ала торган һәм һәрвакыт гыйбадәттә булучы гөнаһсыз затлар.

СОРАУ: Дүрт бөек фәрештә кайсылары?

ҖАВАП: Җәбраил, Микаил, Исрафил һәм Газраил (галәйһимүс-сәлам).

СОРАУ: Дүрт бөек китап кайсылардыр һәм кайсы пәйгамбәргә иңгән?

ҖАВАП: Тәүрат – Муса аләйһиссәләмгә, Зәбүр – Давыт галәйһиссәләмгә, Инҗил – Гайсә галәйһиссәләмгә, Коръән Кәрим – Мөхәммәд Мостафа салләллаһү галйһи вә сәлләмгә индерелгән.

СОРАУ: Сүхүф ни дигән сүз, ничә данә һәм кемнәргә бирелгән?

ҖАВАП: Аллаһы Тәаләнең дүрт китаптан башка Җәбраил (а.с.) арадашлыгы белән кайбер пәйгамбәрләргә иңдерелгән әмер-күрсәтмәләрен сүхүф дип атыйлар. Алар йөз данә. Адәм галәйһиссәләмгә - 10, Шис галәйһиссәләмгә - 50, Идрис галәйһиссәләмгә - 30, Ибраһим галәйһиссәләмгә - 10 сүхүф җибәрелгән.

СОРАУ: Мәзһәбләр ничә төрле?

ҖАВАП: Ике төрле?

СОРАУ: Ниндиләр?

ҖАВАП: Игътикадтагы мәзһәб һәм гамәлдәге мәзһәб.

СОРАУ: Игътикадтагы мәзһәб имамнары ничә?

ҖАВАП: Икәү.

СОРАУ: Алар кемнәр?

ҖАВАП: Имам Әбү Мөхәммәд Матуриди һәм Имам Әбү Хәсән Әшгари хәзрәтләре.

СОРАУ: Гамәлдә ничә мәзһәб?

ҖАВАП: Дүрт.

СОРАУ: Алар нинди?

ҖАВАП: Хәнәфи, Шәфигый, Мәлики, Хәнбәли мәзһәбләре.

СОРАУ: Игътикадта синең мәзһәбең нинди?

ҖАВАП: Әһле сөннәт вәл-җәмәгать мәзһәбе.

СОРАУ: Гамәлдә мәзһәбең нинди?

ҖАВАП: Хәнәфи мәзһәбе.

СОРАУ: Безнең игътикад мәзһәбенең имамы кем?

ҖАВАП: Имам Мансур Мөхәммәд Матуриди хәзрәтләре.

СОРАУ: Шәфигый, Мәлики һәм Хәнбәли мәзһәбен тотучыларның игътикадтагы имамнары кем?

ҖАВАП: Әбү Хәсән Әшгари (рәхимәһүллаһ) хәзрәтләре.

СОРАУ: Имам Әбү Мансур Мөхәммәд Матуриди кайсы якныкы?

ҖАВАП: Сәмәрканд тирәсендәге Матурид авылыннан.

СОРАУ: Матуриди кайчан вафат булган.

ҖАВАП: Һиҗри буенча 333 нче елда вафат булган.

СОРАУ: Әбү Хәсән Әшгари хәзрәтләре кайсы якныкы һәм кайчан вафат булган?

ҖАВАП: Ул Басрада туып-үскән һәм һиҗри буенча 324 нче елда вафат булган.

СОРАУ: Намазның казага калдыру сәбәпләре ничә?

ҖАВАП: Өч.

СОРАУ: Санап күрсәтә аласыңмы?

ҖАВАП: а) Йокы; б) сугыш мәйданында булып, форсат юклыгы; в) Оныту.

СОРАУ: Утыз ике фарызны санап күрсәтә аласыңмы?

ҖАВАП: Алтысы иман шарты; бишесе Ислам шарты; уникесе намаз фарызлары; дүртесе тәһарәт фарызлары; өчесе госел фарызлары; икесе тәяммум фарызы. Барысы – 32.

СОРАУ: Иманның шартлары ниләр?

ҖАВАП: Аллаһының барлыгына, берлегенә, фәрештәләренә, китапларына, пәйгамбәрләренә, Ахирәт көненә, тәкъдиренә, игелекнең һәм явызлыкның Аллаһыдан булуына ышану.

СОРАУ: Исламның шартлары ничә?

ҖАВАП: Биш:

1. Шәһадәт китерү.
2. Намаз уку.
3. Зәкят бирү.
4. Ураза тоту.
5. Хаҗ кылу.

СОРАУ: Тәһарәтнең фарызы ничә?

ҖАВАП: Дүрт:

1. Чәч кырыеннан һәм колак йомшагыннан ияк астына кадәр битне юу.
2. Кулларны терсәкләре белән юу.
3. Башның дүрттән бер өлешенә мәсех кылу.
4. Аякларны тубыклары белән юу.

СОРАУ: Госелнең фарызы ничә?

ҖАВАП: Өч:

1. Мул су илә авызны чайкау;
2. Мул су белән борынны чистарту;

3. Һичбер коры төшне калдырмыйча коену.

СОРАУ: Госел тәһарәтен тасвирлап бирә аласыңмы?

ҖАВАП: Бирә алам. Ул болай: башта бисмилләһ әйтеп ниятләнәбез. Аннары гаурәт җирләрне юабыз. Намаз тәһарәте кебек тәһарәт алабыз. Шул чакта өч тапкыр күп-күп су алып авыз чайкыйбыз. Өч тапкыр сөртеп борыныбызны пакьлибез. Шуннан соң өч тапкыр башыбызга су коябыз, өч тапкыр уң, өч тапкыр сул иңебезгә су коябыз һәм һәрберсендә ышкыйбыз. Бәдәндә һичбер коры төш калдырмыйбыз: йөзек аслары һәм кендек чокырына да игътибар итәбез. Суның тирегә тиюенә каршы киләчәк бер нәрсә булса, аның чарасын табып пакьлибез. Хатыннар колакларындагы алка тишекләрен дә игътибарсыз калдырмыйлар.

СОРАУ: Тәяммумның фарызы ничә?

ҖАВАП: Ике.

1. Ният итү.

2. Кулларны ике тапкыр туфракка сугу, беренчесеннән соң битне, икенчесеннән соң кулларыңны мәсех кылу.

СОРАУ: Тәяммум ничек башкарыла?

ҖАВАП: Тәяммумга ният әйтелә. Кулларны чиста җирлеккә сугып һәм бармак араларын ышкып, битне мәсех кыласың. Тагын кулларны чиста җирлеккә сугасың да сул кул белән уң кулны, уң кул белән сул кулны сөртәсең.

СОРАУ: Намазның фарызы ничә?

ҖАВАП: Алтысы - эчке, алтысы – тышкы санала, барлыгы – 12 фарыз.

СОРАУ: Тышкылары нинди?

ҖАВАП: Хәдәстән тәһарәтләнү, нәҗестән тәһарәтләнү, гаурәтләрне ябу, кыйблага карау, вакыт, ният.

СОРАУ: Эчкеләре нинди?

ҖАВАП: Ифтитәх тәкбире, кыям, кыйраәт, рөкуг, сәҗдә, кәгъдәи-ахирәдә тәшәһһүд микъдары утыру.

СОРАУ: Бер көндә ничә тапкыр намаз укыла һәм нинди намазлар?

ҖАВАП: Иртәнге, өйлә, икенде, ахшам, ястү намазлары булып, барлыгы биш намаз.

СОРАУ: Бу намазларның һәркайсы ничә рәкәгать?

ҖАВАП: Иртәнге намаз 4 рәкәгать – икесе сөннәт, икесе фарыз. Башта сөннәте, аннары фарызы укыла. Өйлә намазы 10 рәкәгать – тәүге дүртесе сөннәт, аннары дүрт фарыз, соңыннан ике сөннәт. Икенде намазы 8 рәкәгать - тәүге дүртесе сөннәт, аннары дүрт фарыз. Ахшам намазы 5 рәкәгать – тәүге өчесе фарыз, аннары ике сөннәт укыла. Ястү намазы 13 рәкәгать - тәүге дүртесе сөннәт, аннары дүрт фарыз, соңра ике сөннәт һәм иң ахырдан өч рәкәгать витыр намазы башкарыла. Барысы көненә 40 рәкәгать була.

СОРАУ: Намазда өстәмә сүрәләрне онытып, укымыйча калдырсаң нишләргә?

ҖАВАП: Сәһү сәҗдәсен кылырга кирәк.

СОРАУ: Сәһү сәҗдәсе нинди очракларда кылына?

ҖАВАП: Намазда бер ваҗибны оныту яки соңга калдыру очракларында, ә фарызлардан бары тик соңга калдыру очракларында гына кылына.

СОРАУ: Сәһү сәҗдәсе кылынмаса ни булыр?

ҖАВАП: Намаз җитешсез булыр.

СОРАУ: Сәһү сәҗдәсе ничек кылыныр?

ҖАВАП: Намазның ахырында утырып "Әттәхият" укып, сәлам биргәч, ике тапкыр сәҗдәгә кителә, икенче сәҗдәдән соң утырыла һәм "Әттәхият", салават укылып сәлам бирелә.

СОРАУ: Сәһү сәҗдәсе тиеш булган кайбер очракларны санап күрсәтә аласыңмы?

ҖАВАП: 1. Өстәмә сүрәне онытканда;

2. витыр намазының көнүт тәкбирен, көнүт догаларын яисә икесен дә онытканда;

3. дүрт рәкәгатьле намазларда тәүге утыруда "Әттәхият" укыгач, торып басырга онытып, салаваттан бераз укып өченче рәкәгатькә күчкәндә сәһү сәҗдәсе укыла.

СОРАУ: Гыйбадәт белән уздыру аеруча саваплы һәм тантаналы булган төннәрне ничек атыйлар?

ҖАВАП: Кәндил кичәләре дип атыйлар.

СОРАУ: Ничә кәндил кичәсе бар?

ҖАВАП: Биш кәндил кичәсе бар:

1. Мәүлед кичәсе.
2. Рәгаиб кичәсе.
3. Мигъраҗ кичәсе.
4. Бәраәт кичәсе.
5. Кадер кичәсе.

СОРАУ: Нәрсә ул мәүлед кичәсе?

ҖАВАП: Пәйгамбәребезнең дөньяга килгән – туган көне.

СОРАУ: Нәрсә ул рәгаиб кичәсе?

ҖАВАП: Хәзрәти Әминәнең бөек Пәйгамбәребез белән йөкле булуын белгән кичә.

СОРАУ: Нәрсә ул мигъраҗ кичәсе?

ҖАВАП: Сөекле Пәйгамбәребезнең илаһи солтанлыкны күрү өчен Аллаһы Тәгаләнең чакыртуы буенча тиңсез бер могъҗиза белән күкләргә һәм ничәмә-ничә галәмнәргә сәяхәт иткән кичәсе.

СОРАУ: Нәрсә ул бәраәт кичәсе?

ҖАВАП: Коръән Кәримнең Ләүхел-Мәхфуздан дөньяга индерелгән, кешеләрнең бер еллык тормышы һәм ризыклары күздән кичерелеп, мөселманнарны гафу итү кичәсе.

СОРАУ: Нәрсә ул кадер кичәсе?
ҖАВАП: Коръән Кәримнең Пәйгамбәребезгә индерелә башлаган кичә.

## ЭЧТӘЛЕК

Дин
Шәригать
ИМАН
ИМАН ШАРТЛАРЫ
Аллаһы Тәгаләгә инану
Сыйфатү-зәтия
Сыйфатү-сүбүтия
Фәрештәләргә инану
Китапларга инану
Пәйгамбәрләргә инану
Пәйгамбәребез
Сәхабәләр
АХИРӘТКӘ ИНАНУ
ӘҖӘЛ
ТӘКЪДИР ҺӘМ КАЗАГА ИНАНУ
Ирадәи җүзьийә (сайлау иреге)
ТӘКЪДИР
РИЗЫК
ТӘВӘККӘЛ
ИМАННЫҢ ДӘВАМЛЫЛЫК ШАРТЛАРЫ
ИМАННЫ САКЛАУЧЫ КАЛЬГӘЛӘР
МӨСЕЛМАН КЕШЕГӘ САКЛАНЫРГА ТИЕШЛЕ БУЛГАН ХӘЛЛӘР
ӘДИЛЛӘИ-ШӘРГЫЯ (ШӘРИГАТЬ ДӘЛИЛЛӘРЕ)
Китап
Сөннәт
Иҗмаг-үммәт
Кыясы-фокаһа
Иҗтиһад
Мөҗтәһид
ГЫЙЛЕМНЕҢ ЮЛЛАРЫ ҺӘМ БЕЛЕМ ЧАРАЛАРЫ
Хавассы сәлимә
Хәбәри саадык
Акыл
МӘЗҺӘБЛӘР
ГАМӘЛДӘГЕ (ГАМӘЛИ) ХАК МӘЗҺӘБЛӘР
ИСЛАМНЫҢ ШАРТЛАРЫ
ФГАЛИ МҮКӘЛЛӘФИН

НАМАЗ
Намазның шартлары
Намазның рукүннәре
ХӘДӘСТӘН ТӘҺАРӘТ
ТӘҺАРӘТ
ТӘҺАРӘТНЕҢ ФАРЫЗЛАРЫ
ТӘҺАРӘТНЕҢ СӨННӘТЛӘРЕ
ТӘҺАРӘТНЕҢ МӘКРУҺЛАРЫ
ТӘҺАРӘТНЕ БОЗА ТОРГАН НӘРСӘЛӘР
ТӘҺАРӘТ НИЧЕК АЛЫНА?
Каплама мәсех шулай эшләнер
ГОСЕЛ
ГОСЕЛНЕҢ ФАРЫЗЛАРЫ
ГОСЕЛНЕҢ СӨННӘТЛӘРЕ
ГОСЕЛ ТӘҺАРӘТЕ НИЧЕК АЛЫНА?
ГОСЕЛ ТӘҺАРӘТЕ ҺӘМ ЯСАЛМА ТЕШ МӘСЬӘЛӘСЕ
ТУТЫРМАЛЫ ТЕШ МӘСЬӘЛӘСЕ
ТӘЯММУМ
ТӘЯММУМ НИЧЕК АЛЫНА?
ЧИТЕК ӨСТЕНӘ МӘСЕХ ИТҮ
МӘСЕХНЕҢ МИКЪДАРЫ
МӘСЕХНЕ БОЗГАН НӘРСӘЛӘР
БӘЙЛӘГЕЧ ҺӘМ ЯРА ӨСТЕННӘН МӘСЕХ ИТҮ
ХАТЫН-КЫЗНЫҢ МАХСУС ХӘЛЛӘРЕ
Хәез
Нифас
Истиһаза
ХӘЕЗ ҺӘМ НИФАС ХӘЛЛӘРЕНДӘ ХӘРАМ БУЛГАН НӘРСӘЛӘР
НӘҖЕСТӘН ТӘҺАРӘТ
ИСТИНҖӘ, ИСТИНКА, ИСТИБРА
СӘТРИ-ГАУРӘТ
ИСТИКЪБӘЛИ КЫЙБЛА
ВАКЫТ
КӘРАҺӘТ ВАКЫТЛАРЫ
НИЯТ
АЗАН ҺӘМ КАМӘТ
НАМАЗНЫҢ ӘРКӘННӘРЕ
ИФТИТӘХ ТӘКБИРЕ
КЫЯМ
КЫЙРАӘТ
НАМАЗДА УКЫЛА ТОРГАН КАЙБЕР СҮРӘ ҺӘМ АЯТЬЛӘР

НҮТ ДОГАСЫ
РӨКУГ
СӘҖДӘ
КӘГЪДӘИ-АХИРӘ (соңгы утырыш)
НАМАЗНЫҢ ВАҖИБЛӘРЕ
НАМАЗНЫҢ СӨННӘТЛӘРЕ
НАМАЗНЫҢ МӨСТӘХӘБЛӘРЕ
НАМАЗНЫҢ МӘКРУҺЛАРЫ
НАМАЗНЫ БӨТЕНЛӘЙ БОЗА ТОРГАН НӘРСӘЛӘР
НАМАЗ НИЧЕК УКЫЛА?
БИШ ВАКЫТ НАМАЗ
ИРТӘНГЕ НАМАЗ
ӨЙЛӘ НАМАЗЫ
ИКЕНДЕ НАМАЗЫ
АХШАМ НАМАЗЫ
ЯСТҮ НАМАЗЫ
ВИТЫР НАМАЗЫ
СӘҺҮ СӘҖДӘСЕ
СӘҺҮ СӘҖДӘСЕН ВАҖИБ КЫЛГАН СӘБӘПЛӘР
СӘҺҮ СӘҖДӘСЕНЕҢ ҮТӘЛҮЕ
ҖОМГА НАМАЗЫ
Җомга намазының ваҗиб шартлары җиде
Җомга намазының дөреслек
Шартлары алты
Җомга намазына ният
БӘЙРӘМ НАМАЗЛАРЫ
КАЗА НАМАЗЛАРЫ
КАЙБЕР НӘФЕЛ НАМАЗЛАР
ӘҮВӘБИН НАМАЗЫ
ДУХА НАМАЗЫ
ТӘҺӘҖҖҮД НАМАЗЫ
ТӘСБИХ НАМАЗЫ
ҖЕНАЗА ТУРЫНДА
КӘФЕН
ҖЕНАЗА НАМАЗЫ
Җеназа догасы
КАБЕР ҺӘМ ДӘФЕН
КАБЕР СОРАВЫ
КАБЕР СОРАУЛАРЫ ҺӘМ ҖАВАПЛАРЫ
КАБЕРЛӘРНЕ ЗИЯРАТ ИТҮ
СӘФӘР ТУРЫНДА

Ватани-асыл
Ватани-икамәт
Ватани-сөкнә
КОРЪӘНДӘГЕ ТИЛӘВӘТ СӘҖДӘЛӘРЕ
МӨБАРӘК КИЧӘЛӘРДӘ КЫЛЫНА ТОРГАН ГЫЙБАДӘТЛӘР
МӘҮЛЕД КИЧӘСЕ
РӘГАИБ КИЧӘСЕ
МИГРАҖ КИЧӘСЕ
БӘРАӘТ КИЧӘСЕ
КАДЕР КИЧӘСЕ
УРАЗА
УРАЗАНЫҢ ТӨРЛӘРЕ
УРАЗАНЫ БОЗЫП, ГАДИ КАЗА КЫЛЫРГА МӘҖБҮР ИТӘ ТОРГАН НӘРСӘЛӘР
УРАЗАНЫ БОЗЫП, КАЗА ҺӘМ КӘФФАРӘТ КЫЛЫРГА МӘҖБҮР ИТКӘН НӘРСӘЛӘР
УРАЗА ТОТКАНДА МӘКРУҺ БУЛГАН НӘРСӘЛӘР
УРАЗАНЫ БОЗМЫЙ ТОРГАН НӘРСӘЛӘР
ФИТЫР СӘДАКАСЫ
ТӘРАВИХ НАМАЗЫ
ЗӘКЯТ
ГОШЕР
ЗӘКЯТ БИРЕЛӘ ТОРГАН ТӨРКЕМНӘР
ХАҖ
ХАҖНЫҢ ФАРЫЗ ШАРТЛАРЫ
ХАҖНЫҢ ҮТӘЛҮЕНЕҢ ФАРЫЗ БУЛУ ШАРТЛАРЫ
ХАҖНЫҢ ДӨРЕСЛЕК ШАРТЛАРЫ
КОРБАН
КОРБАН ЧАЛУ ВАКЫТЫ
КОРБАН ЧАЛУ ТӘРТИБЕ
Корбан чалуга ният итү
НӘРСӘ УЛ ГӨНАҺ ҺӘМ ТӨП ГӨНАҺЛАР
Зур гөнаһлар
ГӨНАҺЛАРДАН КОТЫЛУ ЧАРАЛАРЫ
Тәүбә һәм истигъфар
ӨМЕТСЕЗЛЕК ДӨРЕС ТҮГЕЛ
ТӘҮБӘНЕҢ КАБУЛ БУЛУ ШАРТЛАРЫ
Зур истигъфар догалары
ҖИҺАД
МӨСЕЛМАННАРНЫҢ ҖӘМГЫЯТЬТӘГЕ ВАЗИФАЛАРЫ
Күрше хакы

Мосафир хакы

Башка иҗтимагый вазифаларыбыз

БӘГЪЗЕ ДОГАЛАР

Бәдрәфкә кергәндә укыла торган дога

Бәдрәфтән чыккач укыла торган дога

Куркыныч төш күргәч укыла торган дога

Аллаһының ярдәме һәм рөхсәте белән бай булу өчен иртә-кич түбәндәге доганы өчәр тапкыр укырга кирәк

Кичен ятканда укыла торган дога

Иртән торганда укыла торган дога

Һәрвакыт зур файда китерә торган догалар

Бәлагә очраган берәүне күргәндә **(**ул бәланең үзеңә килмәвен теләп**)** укыла торган дога

Иртәнге намазның сөннәте белән фарыз арасында укылачак дога

Иртән иртүк торуның гүзәллекләре хакында

САЛАВАТЫ-ШӘРИФӘЛӘР

САЛӘТИ-МҮНҖИЯ

САЛӘТИ-ФӘТХЫЙӘ

САЛӘТИ –НӘРИЯ

ХӘТЕМ ДОГАСЫ

УТЫЗ ИКЕ ФАРЫЗ

ИЛЛЕ ДҮРТ ФАРЫЗ

КАЙБЕР ЕВРОПА ФӘЛСӘФӘЧЕЛӘРЕНЕҢ ИСЛАМ ДИНЕ ТУРЫНДАГЫ ФИКЕРЛӘРЕ

МӨСЕЛМАН БАЛАЛАРЫ ӨЧЕН КАЙБЕР ДИНИ СОРАУЛАР ҺӘМ ҖАВАПЛАР